ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№05 (388)
МАЙ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

KAZANFORUM-2024

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

ЭМИЗ
HALAL
2022
ЛУЧШИЕ
ТОВАРЫ
И УСЛУГИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ЛАУРЕАТ
100 ЛУЧШИХ ТОВАРОВ РОССИИ
2022
PROD EXPO
2022
8 800 444 09 37
emiz.ru
ЛИМОНАД
BAZR
Реклама

«ЭМИЗ»: ЭЧЕМЛЕК КЕНӘ ТҮГЕЛ, СӘЛАМӘТЛЕК ФӘЛСӘФӘСЕ ДӘ

Виноград үстерү, шәраб ясау буенча фәнни-тикшеренү институтлары булдыра алмаганны Татарстан төзүчесе ничек итеп башкарып чыккан?

«ЭМИЗ» компанияләр төркемен гамәлгә куючы, аның хуҗасы Раил Фазылҗанов белән сөйләшүебез гап-гади сораудан башланып китте кебек, әмма җавап шактый кызыклы булды.

– Раил Наилевич, «ЭМИЗ» эчемлеге, базарда күптән түгел генә тәкъдим ителүенә карамастан, шактый танылып өлгерде. Бу проект ничек башланды?

– Сез, ихтимал, үзегез дә сизмәстән, төп сорауны бирдегез кебек. Сөйләшү күбрәк дәвалау үзлекләре, җитештерү технологиясе тирәсендә бара... Әлбәттә, болары да кирәк, әмма максатка илтүче юл үзе дә мөһим. Чөнки сүз «Таптым!» сериясенә караган ачыш турында бармый, ничек кенә купшы яңгырамасын, язмышка язылган гамәл хакында барадыр.

ФОРД МЕТОДЫ БУЕНЧА РЕЦЕПТ

Төзелеш компаниябез шактый танылган иде, эшләр дә уңышлы гына барды. 2018 елда Кырымда эш алдык. Әмма партнёр сүзендә тора алмады: вәгъдә ителгән күләмнәр әләкмәде, зыян күрдек. Түләү бәрабәренә уникаль йөзем эчемлеге рецептын тәкъдим иттеләр.

Эш шунда ки, ул вакытта минем кан тамырларына кагылышлы проблемаларым бар иде, һәм табиблар йөзем төшеннән алына торган экстракт эчәргә киңәш иттеләр. Кырымда шундыйрак нәрсә эзли башладым. Нәтиҗәдә шуны ачыкладым: СССР заманында ук мондый продуктны уйлап табу буенча Ялтада виноград үстерү һәм шәраб ясау фәнни-тикшеренү институты эшләгән. Ләкин алар уйлап тапкан эчемлек эчерәк килеп чыккан, җитмәсә җимешнең кайбер файдалы үзлекләре дә югалган. Мин йөземнең файдасын тулысынча саклап калырга һәм тәмле продукт ясарга хыялландым.

– Димәк, теләк генә кирәк булган һәм...

– Теләгәнне таптыммы? Юк. Күп кешегә бәйле вакыйгаларның бөтен нечкәлекләренә тукталып тормыйм. Шуны гына әйтәм: нәтиҗәдә без 9 миллион сумга концентрацияләнгән йөзем согы җитештерү технологиясен сатып алдык, анда шикәр дә, консервант та бар иде.

– Шуннан соң күңелегез төштеме?

– Без, татарлар, бик үҗәт бит. Иң мөһим эшләр гомумән шул мизгелдән башланды гына әле. Генри Фордның V-рәвешле двигателен ничек уйлап тапканын беләсезме? Ул үзенең инженерларын җыя да, кирәкле нәрсәне уйлап тапкынчы, алар белән ангарда бикләнә. Без дә шулай эшләдек дияргә була.

Мин үз командамны җыеп болай дидем: «Егетләр, үзебезнең уникаль эчемлек рецептурасын эшләүдән башка юлыбыз юк». Без бит инде продуктны рекламалый башладык, шуңа күрә абруебыз шик астына куелырга мөмкин иде. Һәм без өч ай дәвамында көне-төне производствода ятып, җитмәгән җиһазларны сатып ала-ала, яңа продукт җитештердек. Бу 2019 елның сентябре иде. Шул рәвешле тегесенә-монысына бер ел вакыт китте.

– Әйдәгез, «ЭМИЗ»ны уникаль иткән төп плюсларны атыйк.

– Ул теләсә кайсы йөзем эчемлегенә караганда алты тапкырга файдалырак, чөнки без җимешнең кабыгында, төшендә булган файдалы үзлекләрне алабыз, ә бер шешәгә 3-4 килограмм чимал китә. Нәтиҗәдә, без бик күп полифеноллар алабыз, алар көчле антиоксидант санала. Шул ук вакытта эчемлектә шикәр һәм консервантлар юк, өстәвенә ул тәмле. Кыскасы, витаминлы һәм бик тәмле. Шуңа күрә атамасы русчадан «ЭМИЗ» – «элексир молодости и здоровья».

ХӘЛӘЛ БЕЛӘН АССОЦИАЦИЯ

– Татарстан төзүчесе тулы бер фәнни-тикшеренү институты булдыра алмаганны булдырдымы?

– Күпмедер дәрәҗәдә шулайдыр да. Аларда, мөгаен, мотивация азрак булгандыр.

– «ЭМИЗ» – хәләл продукт. Сез моңа махсус басым ясадыгызмы?

– Башта шулай булды да. Әмма соңрак шуны аңладык: ислам дине белән бәйле булмаган күп кешеләр товардан читкә борылырга мөмкин. Хәзер «хәләл продукт» дип күрсәтмибез, әмма сертификатыбыз бар.

Чынлыкта ныклы ассоциация булдырырга тырышабыз: «ЭМИЗ» яки «BAZR» (шәкәрсез һәм консервантсыз сок һәм су нигезендә лимонадлар линиясе) – хәләл, башкача була алмый. Мин мөмкин кадәр күбрәк кешегә файда китерергә телим, аларның диненә һәм гомумән дингә мөнәсәбәтенә карамастан, барлык кешеләргә. Бүген без Согуд Гарәбстанына эчемлекләр җибәрәбез, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре белән эшли башлыйбыз. Белоруссиядә товар федераль даруханә челтәрендә яхшы сатыла...

Беләсезме, эшли башлаганда ук безгә очраган төрле хәлләр кебек үк, «ЭМИЗ» белән дә кызыклы вакыйгалар булып тора. Бервакыт миңа бер миллиардер шалтыратты: «Таныш булмасак та, мин сезнең яшерен дистрибьюторыгыз», – ди бу. Яңа танышым шәраб урынына гел «ЭМИЗ» эчә башлаган икән, аннары аның җиңел кулы белән дуслары да эчүдән туктаган. Бу минем өчен ачыш булды, һәм мин безнең продукт тәкъдим ителгән урыннарны киңәйтергә кирәклеген аңладым....

– Тиздән Казанда зур гастрономия үзәге ачылачак. Кайбер нечкәлекләре белән таныштырыгыз әле.

– Бу 1500 квадрат метрлы зур мәйдан – өч кат, берьюлы 500дән артык кешене сыйдыра ала. Адресы: Юлиус Фучик урамы, 29. Бинада хәмерсез тантаналар үткәрү өчен 350 кешегә исәпләнгән банкет залы, 70 урынга исәпләнгән кафе-ресторан һәм 30 урынлык VIP-зал, җәйге терраса, кондитер цехы урнашкан. Анда үз эше буенча дөньяның иң яхшы 15 белгече арасына кергән кеше идарә итәчәк. Һәм бу сәламәт яшәү һәм файдалы туклану территориясе булачак, чөнки болар барысы да «ЭМИЗ» фәлсәфәсенә тулысынча туры килә дип әйтергә мөмкин. Килегез һәм үзегез бәя бирерсез. Т

№05 (388)
МАЙ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Алиса Бочкина, Михаил Рябинин, Ульяна Макарчикова, Әхмәт Шакиров, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Лилиана Вәлитова, Александр Ефремов, Алсу Шакирова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Үзбәкстаннан Шәйхенуровлар гаиләсе.
Фото гаилә архивыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-0936
Басарга кул куелды: 17.05.2024
Чыгу көне: 23.05.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

KAZANFORUM–2024
ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ БЕЗДӘ КУНАКТА!

Май ае тылсымчыдыр! Яшеллеккә төренгән агач-куаклары, бөтен тирә-якка хуш ис таратып утырган ландыш, сирень, алмагач, шомырт чәчәкләре белән бергә ул безгә кызыклы вакыйгалар да бүләк итә. Ел саен уздырыла торган KazanForum – шуларның берсе. Ямьле май аенда ислам дөньясы илләре Казанга ашыга. Биредә аларны форумның кызыклы һәм файдалы вакыйгаларыннан тыш, шәп мәдәни, спорт тамашалары һәм туристик программа да көтә.

Кунакчыл Татарстан халкы килгән кешеләрне республикабызның төрле төбәкләрендә каршы ала. Биредә кунаклар җирле истәлекле урыннар белән таныша, тәм-томнарны авыз итеп карый, язгы табигать гүзәллегенә соклана ала. Һәр май тылсымга бай ай бит!

Сезнең сокланучан редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 103 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре
бары тик ТАТАРСТАНДА



МӘҢГЕЛЛЕК ТРАДИЦИЯЛӘР

Борынгы Болгар стилендәге бинаны алтын гөмбәз белән ярымай бизи… 922 елда Идел буе болгарлары тарафыннан ислам динен рәсми рәвештә кабул итү хөрмәтенә Истәлек билгесе ул. Асылда музей комплексы булган бинада чын хәзинәләр саклана. Монда дөньядагы иң зур Коръәнне күрергә мөмкин: ярымкыйммәтле ташлар һәм алтын йөгертелгән көмеш бизәкләр белән бизәлгән Изге китапның иңе – 1,5 метр, буе – 2 метр, авырлыгы – 500 кг. Болгар ханы Алмышның Багдад хәлифе делегациясен каршы алу тантанасы сурәтләнгән мозаик панно да сокландыра. Биредә Идел буенда ислам диненең таралу тарихына караган башка ядкарьләрне күрергә була. «Ислам безгә көчле булырга мөмкинлек бирде, барыбызны да берләштерде, – диде 2012 елның маенда Болгарда Истәлек билгесен ачу тантанасында ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов. – Бүген Болгарга килгән ислам традицияләрен саклап калу бик мөһим».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Партнёрлык финанслары
Табыш һәм зыянны гадел килешү аша бүлеп, банкларга ничек акча эшләргә

10. KAZAN–HALAL MARKET 2024
Башкалада оештырылган хәләл продукция ярминкәсенең үзенчәлеге нәрсәдә

20. Кояшлы Үзбәкстаннан
Шәйхенуровлар гаиләсе нинди «шәрык төсләрен» алып килгән

26. Түбән старттагы югары технологияләр
Татарстанлыларның дөнья дәрәҗәсенә чыгарлык проектлары

игелекле эшләр

44. Ярдәм янәшәдә генә
«Кеше приюты» – язмышлармы, ялгышлармы?

50. Гамьле әңгәмә
Тинчурин театры: юбилейны каршылап

56. Зарланмыйча эшләгән буын
Язмыш бормалары: Иделдән Енисейга кадәр

60. Ветераннарыбыз
«Сугышта тамагым туяр, дидем…»

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

мәңгелек кыйммәтләр

64. Тарихи сәхифә
Большевик Галимҗан Сәйфетдинов кем ул

68. Сугышка кадәр 56 көн
Минзәләдә Муса Җәлил эзләре буйлап…

72. Онытылмас исемнәр
Шәехгаттар Иманаевның хәяте һәм хокукы

76. Китап киштәсе
Хәтер дәҗҗалы, яки без онытсак, нәрсә үзгәрәчәк?

80. Татар авыллары
Олы Салтык: халык мал асрап көн күрә

Фото: Игорь Глушков

Акыллы гамәлләр

Марат Хөснуллин, РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Мәскәүдә, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисадый форумына әзерлек буенча оештыру комитеты утырышында:

– Россия мөселман илләрен ышанычлы партнерлар итеп күрә. Бүгенге көндә Россия Федерациясе белән Ислам дөньясы илләре арасындагы товар әйләнеше 37 процентка артты һәм 156 миллиард долларны тәшкил итте. Узган форум югары дәрәҗәдә узды. Татарстан җитәкчелегенә һәм Рөстәм Миңнехановка рәхмәт белдерәм. Быел да форум чаралары шундый ук югары дәрәҗәдә узар, дип ышанам.

Игелекле эшләр



Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Рәисе, – «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисадый форумында катнашучыларга аталган котлау сүзендә:

– Хәзерге чынбарлыкта Ислам дөньясы илләре белән үзара элемтәләр яңа дәрәҗәгә күтәрелде. Россия, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне уртаклашып, динара, мәдәниятара диалогка һәм үзара аңлашуга ярдәм итеп, Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасына кергән дәүләтләр белән киң колачлы хезмәттәшлеккә юнәлеш ала.

Мәңгелек кыйммәтләр

Мөхәммәд Әхмәд Әл-Җабер, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе:

– «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» форумы үзенең өзлексез үсеше нәтиҗәсендә бик күп мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен уникаль мәйданчыкка әйләнде. Форум сәүдә өлкәсендә зур вакыйга һәм Россия белән Ислам дөньясы хезмәттәшлеген үстерүнең төп факторлары турында фикер алышу өчен әйдәп баручы мәйданчык санала. Бу яктан Татарстанның дөньяның төрле кыйтгаларындагы илләр белән үзара мөнәсәбәтләр төзергә омтылуын билгеләп үтәргә кирәк. Мондый чараларны үткәрү Россия Федерациясе белән Ислам дөньясы илләре арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуда Татарстанның мөһим роль уйнарга әзерлеген күрсәтә.

Фото: rais.tatarstan.ru, tatar-inform.ru, interaffairs.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Табыш һәм зыянны гадел килешү аша бүлеп, банкларга **ничек** акча эшләргә

Kazan Halal Market 2024 ярминкәсенең үзенчәлеге **нәрсәдә**

Югары технологияләр **ни өчен** түбән стартта

Шәйхенуровлар гаиләсе **нинди** «шәрык төсләрен» алып килгән



ПАРТНЁРЛЫК ФИНАНСЛАРЫ: ЭШЧӘНЛЕК НИГЕЗЛӘРЕ

Әхмәт Шакиров

Нигезенә табышны да, зыянны да инвестор белән клиент арасында партнерлык принцибына таянып бүлү салынган финанс эшчәнлеге – Россия Үзәк банкы партнерлык финансларының мәгънәсен шулай дип аңлата. Асылына гаделлек салынган бу принципка Россия Федерациясендә ихтыяҗ бармы һәм ул ничек тормышка ашырыла ала? Бу партнёрлык (ислам) финанслары буенча башланып киткән эксперимент җавап бирергә тиешле сорауларның берсе генә. Әлеге эксперимент инде бер елга якын Россиянең дүрт төбәгендә – Башкортстанда, Дагыстанда, Татарстанда һәм Чечняда бара.



Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге директоры, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы гыйльми секретаре Рөстәм хәзрәт Нургалиев экспериментның уңышлы узачагына һич шикләнмәүчеләрнең берсе. Аның фикеренчә, шәригать принципларын үтәүне күздә тоткан ислам финанс моделенең асылы үзе үк аның тормышчанлыгын һәм тарафдарларының күбәюен тәэмин итә, чөнки ул гадел акча эшләү мөмкинлеге бирә.

ГАДЕЛ КИЛЕШҮ ҺӘМ ЗЫЯННЫ БҮЛЕШҮ

– Гадәти банкингта акча биреп торган өчен алдан билгеләнгән процент алуны ислам риба дип аңлата, ислам хокукы аны 1400 ел элек үк законсыз табыш алу юлына керткән, – дип искәртә Рөстәм хәзрәт. – Ислам исә банкларга табышны һәм ихтимал булган зыянны үзара гадел бүлү күздә тотылган килешү нигезендә акча эшләү теләгән тормышка ашырырга тәкъдим итә. Банкир бу очракта акча өчен акча гына бирми, ә теге яки бу проектта партнер да була.

Киләчәк, «пычрак» өлкәләрдәге (хәмер җитештерү һәм сату, комарлы уеннар һ.б.) риба һәм хәрәм акчалардан башка, чиста һәм гадел финансларны үстерүдә диган ышануын әңгәмәдәшебез Татарстандагы экспериментның конкрет нәтиҗәләре белән дә ныгыта. Аның сүзләренә караганда, республикада төрле финанс структуралары тарафыннан партнёрлык финанслары өлкәсендә берничә ысул гамәлгә ашырылган инде. Бу, аерым алганда, күчемсез милек сатып алганда хәләл бүлеп түләү; хәләл инвестицияләү мөмкинлеге; мобиль кушымта – хәләл кыйммәтле кәгазьләр идентификаторы; автотранспорт, төзелеш материаллары һәм вак көнкүреш техникасы сатып алуга хәләл бүлеп түләү; хәләл дебет банк карталары…

Фото: Александр Ефремов, tatar-inform.ru, president.tatarstan.ru

Дөрес, әлегә физик затлар өчен продуктлар гадәти банкларга караганда кыйммәтрәк булуын да таный Рөстәм хәзрәт. Ләкин бу, аның фикеренчә, башлыча партнерлык финанслары базарында уенчыларның күп булмавына бәйле. Әмма монда да хәл үзгәрә: РФ Үзәк банкы реестрында экспериментта катнашучылар саны әкренләп арта.

ЭКСПЕРИМЕНТ БАРА, ӘММА ЭШЛӘП БЕТЕРЕРГӘ КИРӘК

Партнерлык экспериментында рәсми катнашучылар саны арта, ләкин, ихтимал, көтелгәнчә актив түгел. Бүген Үзәк банк реестрында алар унсигез. Ләкин эш санда гына түгел. Документны җентекләп тикшерү шуны күрсәтә: ислам банкингы Татарстанда эзлекле рәвештә үзенә юл ача. Реестрда теркәлгән юридик затларның 11 е Татарстаннан, өстәвенә, алар арасында банклар да, инвестиция һәм лизинг компанияләре дә бар. Тагын дүрт юридик зат адресында Мәскәү күрсәтелгән. Башкортстан, Дагыстан һәм Чечнядан берәр компания катнаша, араларында бер генә банк та юк. Әгәр берәр генә катнашучы икән, төбәкнең партнёрлык финанслары экспериментында җитди катнашуы турында сөйләп торырга кирәкме – монысын укучы үзе хәл итсен.

– Эксперимент эшли, бәлки, күпләр көткәнчә актив бармыйдыр, – дип аңлата РФ Дәүләт Думасы комитетлары вәкилләре белән апрель аенда узган очрашуда Үзәк банк җитәкчесе Эльвира Нәбиуллина. «Мондый зур булмаган активлыкның» сәбәпләренә бәя биреп, Үзәк банк башлыгы ашыгыч нәтиҗәләр ясамады, әмма үз фаразын җиткерде:

– Минемчә, эш безнең партнёрлык финанслары буенча эшләнгән механизмда түгел. Ул халыкара тәҗрибәгә таяна. Бәлки, нәрсәнедер эшләп бетерергә кирәктер.

МИЛЛИАРДЛАР САЛСАЛАР ДА, БАЗАР ЙОТЫП БАРАЧАК

РФ Мөселман эшкуарлары ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрдәнов фикеренчә, беренче чиратта потенциаль клиентлар – партнерлык продуктын кулланучыларга мәгълүмат бирү системасын «эшләп бетерергә кирәктер». Әгәр берәр компания ислам финанс продуктын тәкъдим итә икән, мөселманнар шунда ук аны сатып алырга ашыкмаячак. Алар тәкъдимне саклык белән кабул итә. Башта карарлар, өйрәнерләр, чынлыгын тикшерергә тырышырлар. Гаҗәп түгел – монда бит үз үзенчәлеге бар. Теге яисә бу продуктны кем хәләл дип әйткән? Кем бәяләгән? Кем аудит үткәргән? Ниһаять, бәягә кем үз имзасын куйган? Ислам продуктын тәкъдим итүчегә кулланучының барлык сорауларына ышандырырлык җавап бирергә кирәк булачак.

– Шик юк: эшмәкәрләргә ислам акчасы бик кирәк, алар ислам банкларында исәп-хисап счетлары ачачак. Һәм, әлбәттә, шәригать нигезендәге партнёрлык финанслары, ислам инвестицияләре кирәк, – ди Айдар Шаһимәрдәнов. – Әгәр бераздан миллиардлар, дистәләгән миллиардлар кертелсә дә, минемчә, базар бу акчаларны йотачак. Ләкин халык үз итсен өчен, теләсә кайсы иң яхшы идеяне дә популярлаштырырга кирәк. Әгәр ислам банкингы нормага әйләнсә, минемчә, мөселманнар гына түгел, гомумән ил бик зур файда күрәчәк. Ислам икътисады һәм банкингының тәмен белеп алгач, аның тарафдарлары арасында төрле конфессия вәкилләре дә булачак. Партнёрлык финанслары нигезендә гаделлек ята, ә һәр кеше дөреслек яклы.

ТИКШЕРҮЛӘР КЫЗЫКСЫНУ АРТУЫН КҮРСӘТӘ

Аңлашыла ки, партнёрлык финанслары реестрында теркәлгән экспериментта катнашучылар саны иң мөһим күрсәткеч түгел. Теорик яктан караганда, банк яки инвестиция компаниясе документта теркәлгән булып та, базарга бер генә ислам продукты да тәкъдим итмәскә мөмкин. Кызганычка, банкларның гадел партнёрлык принциплары нигезендә күпме проектны финанслаганы турындагы мәгълүмат әлегә киң җәмәгатьчелеккә хәбәр ителми, башка макрокүрсәткечләр белән дә шул ук хәл. Ихтимал, эксперимент йомгаклары буенча без ниндидер гомуми саннарны алырбыз. Әмма турыдан-туры булмаган күрсәткечләр бүген үк бар.

Рөстәм хәзрәт Нургалиев ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы гыйльми секретаре сыйфатында базарга хәләл продуктлар чыгара торган компанияләргә сертификатлар бирүдә турыдан-туры катнаша.

– Безнең исәпләүләр шуны төгәл күрсәтә: ислам финанс продуктларына карата кызыксыну үсә. Чын маякларның берсе – тәкъдим ителгән ислам продуктлары буенча Голәмәләр шурасы тапшырган карар һәм сертификатлар санының арта баруы, – ди Рөстәм хәзрәт. – Уйлап карагыз: узган ел без ике генә сертификат биргән идек. Быелның беренче ике аенда өч сертификат тапшырылды инде, бу өч продукт буенча Голәмәләр шурасының өч карары дигән сүз. Финанс продуктының ислам кануннарына туры килүенә сертификат сорап, тагын 5–6 гариза безнең карарны көтә.

Рөстәм хәзрәт фикеренчә, яңа партнёрлык продуктлары арасында кимендә икесен уңышлы дип атарга мөмкин. Бу ислам факторингы һәм Татарстанның танылган банкларының берсендә исәп-хисап-касса хезмәте күрсәтү. Банкның тагын ике продукты каралу этабында.

– Ә узган ел Татарстанда хәләл пенсия продукты старт алды, – дип хәбәр итә Рөстәм хәзрәт. – Белгәнегезчә, бездә мәҗбүри пенсия иминияте генә түгел, ирекле иминиятләштерү дә бар. Хәләл продуктлар системасы буенча без ТР Милли пенсия фонды белән бергә шундый хезмәттәшлек үрнәге булдырдык.

ТР Икътисад министрлыгында партнёрлык финанслары бүлеге җитәкчесе Руслан Хәлиуллин да экспериментның уңышлы булуына ышана. Шул ук вакытта Татарстан экспериментта катнашучылар саны буенча гына түгел, ислам (партнёрлык) продуктлары буенча да Россиядә иң алда бара, дип саный. Шуны да онытмаска кирәк: экспериментта рәсми рәвештә катнашу турында уйланган бизнес-структуралар, финанс, банк структуралары да бар. Тагын әле күп еллар базарда ислам продуктларын тәкъдим итә, законнарны бозмыйча эшли торган, әмма реестрга керү турында уйламаган структураларны да истән чыгармыйк.

ӘГӘР ХӘЛӘЛ БУЛМАСА?

Тагын бер проблема хәл итүне көтә. Бүгенге көндә, теоретик яктан караганда, банк яисә оешма Үзәк банк реестрында теркәлсә дә, аның продукты партнёрлык буенча Диния нәзарәте сертификатын алмаган булырга мөмкин.

– Үзәк банк конституцион норма, закон, карарларга таяна. Ә ислам продуктын сертификацияләү белән төрле төбәкләрдәге мөселман дини идарәләре шөгыльләнә, – дип аңлата Рөстәм хәзрәт Нургалиев. – Шуңа күрә дә аңлашылмаучанлыклар туа: формаль кагыйдәләр буенча экспериментта катнашучы реестрга кертелгән, тик аның продукты реаль дини кануннарга туры килми.

Проблема экспериментта катнашучы барлык дүрт төбәк экспертлары тарафыннан тикшерелгән, бу турыда барлык хакимият органнарына да, Үзәк банкка да җиткерелгән, диалог алып барыла һәм чишелеш табылыр, дип уйларга кирәк. Гәрчә хәл ителергә тиешле мәсьәлә җиңел булмаса да. Шулай да ислам финанслары, кагыйдә буларак, гарәп-мөселман илләрендә сатыла һәм гамәлгә ашырыла. Анда көйләү мәсьәләләре Конституция дәрәҗәсендә беркетелгән һәм шәригать эксперты хакимиятнең рәсми вәкиле булып тора. Россиядәге кебек модель әлегә кадәр беркайда да тормышка ашырылмаган.

СОҢГА КАЛГАНЧЫ, ИРТӘРӘК ЭШЛӘҮ ЯХШЫРАК

Ислам банкингы базарында Татарстанның алдынгы позицияләрен ничек аңлатырга? Бәлки, монда республикада партнёрлык (ислам) продуктларын үзләштерү һәм кертүнең экспериментка кадәр үк башланганы үз ролен уйнагандыр. Әлеге финанс кырында беренчеләрдән булып «Амаль» Финанс Йорты эшкә керешә – ул үз эшчәнлеген ундүрт ел элек башлый. Директоры Рөстәм Сәгъдиев аңлатуынча, үз вакытында нәкъ менә әлеге юнәлештә бушлык булуы компания оештыру идеясенә китерә: халык тарафыннан ислам финанс продуктларына билгеле бер күләмдәге ихтыяҗ һәрвакыт була.

– Башта без Татарстанда гына эшләдек, бүген ил күләмендә инвестицияләр кертәбез, финанслау ягыннан да төрле төбәкләр белән эшлибез. Казанда, Мәскәүдә офисларыбыз бар, – ди Рөстәм. – Без үзебездә ислам банкингының кайбер принципларын тормышка ашырырга тырыштык. Ягъни, бер яктан, без теләсә кайсы банк кебек инвестицияләр җәлеп итәбез, икенче яктан – финанслыйбыз. Нигездә кече һәм урта бизнеска акча бирәбез. Безнең төп клиент – акча кирәк булган эшмәкәр, гадәттә, бер миллион сумнан 40–60 миллион сумга кадәр. Авто-

мобильләр, махсус техника, җиһазлар, торак яки коммерцияле күчемсез милек – кыскасы, күреп, үлчәп, санап чыгарырга мөмкин булган теләсә кайсы матди активны сатып алырга. Ә безгә инвестицияләр кертүче клиентлар, кагыйдә буларак, физик затлар. Алар – акчаларын сакларга, арттырырга һәм төрле өлкәләргә инвестицияләргә омтылучы кешеләр. Һәм алар өчен «Амаль» үз продукция линейкасын эшләде. Инвестициядән ай саен яисә, туплый барып, сөйләшенгән вакыт ахырында керем алырга мөмкинлек бирүче продуктлар бар. Хәйрия эшенә юнәлтелгән максатчан продуктлар эшләнгән. Мәсәлән, «Яхшылык кайта» кебек. Бу очракта инвестор алган табышның бер өлеше автомат рәвештә хәйриячелеккә китә. Аерым алганда, «Амаль» инде берничә ел дәвамында Казандагы «Ярдәм» фонды белән эшли. Табышның бер өлеше әлеге хәйрия оешмасына китә. Хаҗга барырга теләүчеләргә исәпләнгән тариф та бар – бу очракта кеше табышның бер өлешен шул максатка туплый ала.

Продукция линиясе киң, әмма ислам финансларына ихтыяҗ тагын да зуррак. «Амаль»гә барысын да финанслау өчен элементар ликвидлык, акча җитми. Бу елларда портфель күп тапкырга киңәйсә дә, ихтыяҗ тик тормый, ул тагын да тизрәк үсә, дип нәтиҗә ясый Рөстәм Сәгъдиев.

ХӘЛӘЛ АКЧАГА ЙОРТ ТӨЗЕП БУЛАМЫ? НИШЛӘП БУЛМАСЫН!

Татарстанның танылган банкы өчен ислам продуктлары белән базарга чыгу яңалык түгел. Монда уникe ел элек биредә пилот режимында ислам ипотекасы эшләп киткән.

– Бүгенге көнгә кадәр бу уникаль продукт саналды – бары тик күптән түгел генә шундый продуктны базарга тагын бер зур банк чыгарды, – дип сөйли банкта ислам банкингы юнәлешен җитәкләүче Марат Садриев. – Сүз уңаеннан, узган ел бездә ислам ипотекасын, аннан алдагы ел белән чагыштырганда, өч тапкыр күбрәк алдылар – бу партнёрлык финансларына карата кызыксынуның булу-булмавына мисал.

Бу банкның ислам дебет картасына да ихтыяҗ бар, ул да партнёрлык финанслары буенча эксперимент башланганчы ук эшләп киткән – картаны инде ун меңнән артык кеше алган. Киләсе адым – партнёрлар проекты, ул дебет карталары буенча хәләл кешбәк алырга мөмкинлек бирә. Эш шунда ки, традицион кешбәк, экспертлар фикеренчә, ислам кануннарына туры килми. Шуңа күрә нәкъ менә хәләл продукт эшләнгән. Аерма шунда ки, банк үз кесәсеннән түләгәне – рөхсәт ителмәгән кешбәк. Хәләл кешбәкта исә клиент хәләл продукция өчен предприятиегә түләгән акча кулланылачак. Бу предприятиеләр үз акчаларыннан кешбәк бирәчәк.

Банкның башка яңа продуктларыннан проект финанславы продуктын аерып күрсәтергә мөмкин – ул төзелеш компанияләренә хәләл акча кулланып йортлар төзергә мөмкинлек бирәчәк. Бу продукт ничек эшләячәк соң?

– Без акчаны төзүчегә бирәбез, ул йорт төзи, фатирларны сата, табыш ала һәм аннары бу табышны безнең белән бүлешә. Бу, аңлавыгызча, кредит түгел, ә классик партнёрлык финанслары, – дип аңлата Марат Садриев. – Кредит күпмедер вакытка, түләү һәм кире кайтарылу шартларында бирелә. Монда да вакыт исәбе бар, сроклар билгеләнгән, ә түләү – көтелгән генә, гарантияләнмәгән. Кайтарылу кебек. Ягъни теоретик яктан караганда, берәр нәрсә ниятләнгәнчә барып чыкмаса, банк та югалтачак. Партнёрлар акча югалту куркынычын да үзара бүлешә. Ислам инвестицияләренең мондый формасын, ягъни мударабаны, сүз уңаеннан, без лизинг компанияләренә финанслар биргәндә кулланабыз.

Ә гыйнварда банк клиентларга әйләнештәге акчаларны тулыландыру өчен партнёрлык финанслары алырга мөмкинлек бирә торган беренче продуктны уйлап тапкан һәм сертификатлаган. Банкның цифрлы факторинг идарәсе җитәкчесе Алексей Дробот, беренче чиратта, аны хәләл продукция җитештерүчеләргә исәпләнгән, дип аңлата. Соңгылары еш кына көндәшләре белән тигез шартларга әләгә алмый, чөнки гадәти акчаларны куллану исламда хәрәм (рөхсәт ителмәгән) дип санала. Банк эшләгән әлеге продукт шунда ук кирәкле булып чыга, өстәвенә мөселман эшмәкәрләренә генә түгел. Бу хәтта банклар тирәсендә бәхәс тә тудырган, диләр: потенциаль клиентның бизнесы хәләл булу-булмавына карамастан, бөтенесенә хезмәт күрсәтү никадәр дөрес?

Бу эпизод, бәлки, илдә партнёрлык (ислам) банкингын үстерү буенча экспериментның уңышына шикләнгән скептикларга иң яхшы җаваптыр: хәләл (ислам) продуктларга ихтыяҗ да, шулай ук аларны тәкъдим итү дә булачак. Шул рәвешле, әкренләп, партнёрлык финанслары базарда үз урынын яулаячак.

Ислам банкингы тарафдарлары, җәмгыятьтә гадел бизнеска, тигез хокуклы финанс мөнәсәбәтләренә ихтыяҗ күптән өлгергән, дип саный. Гадел партнёрлык принципларына нигезләнгән, риба алу һәм «пычрак» килешүләр ят булган ислам финанслары – әлеге ихтыяҗга бик вакытлы җавап.

KAZAN HALAL MARKET 2024: БӘРӘКӘТЛЕ РИЗЫК ЯРМИНКӘСЕ

Халыкара Kazan Halal Market 2024 ярминкәсе татарстанлылар һәм килгән кунаклар өчен чын бәйрәм булырга охшап тора. «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2024» Халыкара форумы кысаларында аны ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы оештыра. Илдә иң зур хәләл продукция ярминкәсе турында ТР Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Азат улы Җәббаров сөйли.

Фотолар ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

Михаил Рябинин әңгәмәсе

– Марат Азатович, узган елгы Russia Halal Market 2023 ярминкәсе чын хәләл ризык сөючеләрне дөньяның төрле илләреннән кайтартылган ашамлыкларның төрлелеге һәм сыйфаты белән таң калдырган иде. Ә быел сатып алучыларны нәрсә көтә?

– Сез хаклы, Russia Halal Market 2023 ярминкәсе хәләл ризыкка өстенлек бирүчеләрнең барысы өчен дә бәйрәм булды. Анда Иран, Сенегал, Төркия, Әфганстаннан һәм РФ төбәкләреннән 400 дән артык компания катнашты. Алар 4500 исемдәге продукция тәкъдим итте, барлыгы 20 миллион сумлык товар сатылды. Ә инде KazanForum-2024 кысаларында үтәчәк ярминкәгә килгәндә, оештыручылар быелтыргыдан да яхшырак итеп әзерләнергә тырышты. Узган елдагы кебек үк, быел да мәйданчык «Хәләл» стандартлары таләпләре буенча әзерләнде, шунлыктан биредә хәрәм продукция бөтенләй юк. Ярминкә хәзер Kazan Halal Market 2024 дип атала, әмма аның асылы шул ук калды. Адресы да шул ук: Аграр урамындагы «Казан» агросәнәгать паркы мәйданчыгы. Ярминкә 14-19 майда узачак. Килегез – үкенмәссез.

– Катнашучылар арасында чит ил компанияләре дә булачакмы?

– Kazan Halal Market 2024 ярминкәсенә әзерләнгәндә, без дустанә илләрнең илчелек һәм консуллыклары, авыл хуҗалыгы министрлыкларына, компанияләренә 250 дән артык чакыру җибәрдек. Ярминкәдә 72 компания катнашырга теләк белдерде, шулардан 15 е – чит илнеке.

– Сер булмаса әйтегез әле, бу компанияләр Казан хәләл ярминкәсенә нәрсә алып киләчәк?

– Сер түгел. Мәсәлән, Әфганстан компанияләре кипкән җиләк-җимеш һәм дини сувенир продукция, Пакыстан – дөге һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, Азәрбайҗан – җиләк-җимеш компотлары, Төркия – атаклы тәм-томнар, Казахстан – кондитер эшләнмәләре тәкъдим итәчәк. Иран һәм Кыргызстаннан кипкән җиләк-җимеш алып киләчәкләр. Малайзия һәм Индонезия компанияләре ассортименты әлегә билгеле түгел...

– Ә Россия төбәкләре Казанда нәрсә сатачак?

– Биредә, минемчә, безне иң алдынгы супермаркетлар да көнләшерлек ассортимент көтә. Хәләл продукция алты юнәлештә тәкъдим ителәчәк:

– ат итеннән әзерләнгән продукция, деликатеслар, казылык, консервалар; умартачылык продукциясе;

– бакча культуралары (җир җиләге, җиләкләр, как һ.б.);

– сихәтле үләннәр, чәйләр, кайнатмалар (сәламәт милләт);

– милли кием-салым (милли баш киемнәре, Оренбург мамык шәле һ.б.);

– һөнәрчелек эшләнмәләре (мәчетләрнең 3D-модельләре, намазлык, табигый ташлардан дисбе, басма һәм башка сувенир продукциясе).

Россия Федерациясе төбәкләреннән 57 компания катнаша, шулардан Россиянең 10 төбәгеннән 36 компания үз товарларын бердәм «Татар базары» бренды астында тәкъдим итәчәк (Бөтендөнья татар конгрессы ярдәмендә). Бу Татарстан, Башкортстан, Мордовия, Чувашстан республикалары, Киров, Омск, Пенза, Түбән Новгород, Оренбург өлкәләре, Пермь крае.

Ә төп басым Татарстан агросәнәгать комплексы продукциясенә ясалачак, чөнки республика 2020 елдан бирле хәләл продукцияне дустанә илләргә экспортка чыгару белән шөгыльләнә.

– Чит илләрдә безнең хәләл продукциягә ихтыяҗ бармы?

– Бар, һәм ул һаман арта бара. 2023 елда «Хәләл» стандартлы Татарстан продукциясен экспортка сатудан 11,5 миллион АКШ доллары күләмендә акча керде. 2022 ел белән чагыштырганда, үсеш 177 процент тәшкил итте. Бүген Татарстан Республикасында 100 дән артык компания хәләл продукция җитештерә, шулардан егермегә якыны экспортка тәгаенләп эшли. Быелның дүрт аенда Татарстаннан 4 миллион АКШ долларлык хәләл продукция экспортка чыгарылды, ел азагына кадәр аны чит илләргә сатудан керем 16 миллион доллардан артыграк булыр, дип планлаштырабыз.

– Бүген Татарстанның хәләл продукциясен нигездә нинди илләр сатып ала?

– Бу БДБ илләре, Монголия, Бразилия, Гыйрак, Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Алжир. Бигрәк тә сөт, ит һәм кондитер продукциясе сатыла. «Хәләл» юнәлешендә Татарстанның төп экспортчылары: «Акульчев» (кондитер эшләнмәләре), «Эссен-Продакшн» (кондитер эшләнмәләре, соуслар), «Агросила» холдингы (ит продукциясе), «Арабик групп» (кондитер эшләнмәләре), «Кәүсәр» АХКК (ит продукциясеүрдәк ите һәм деликатеслар), «Вамин-Татарстан» (атланмай, сыр), «MLK-GROUP (COM)» ҖЧҖ.

– Сезнең фаразыгыз нинди: ярминкә белән форум Татарстанда һәм тулаем Россия Федерациясендә киләчәктә хәләл индустрияне үстерүгә этәргеч була аламы?

– Һичшиксез. Ярминкә генә түгел, «Россия - Ислам дөньясы: KazanForum 2024» Халыкара форумының бөтен программасы бәйләнеш нокталарын табу, булган проблемаларны хәл итү, каршылыклардан котылу һәм ахыр чиктә потенциаль партнерлар арасында ике якка да файда китерерлек яңа эшлекле элемтәләр урнаштырырлык итеп төзелгән. «Хәләл индустрия» тематикасы буенча гына да биш түгәрәк өстәл үткәрү планлаштырыла. Төп темалар арасында РФ һәм гарәп-мөселман дөньясы илләре арасында товар әйләнешен арттыру; Россиядә җитештерелгән хәләл продукцияне экспортка чыгару; уңыш стратегиясе һ.б. бар. Сүз дә юк, форум дустанә илләр белән хезмәттәшлекне ныгытырга ярдәм итәчәк, агросәнәгать комплексы продукциясен экспортка чыгаруны үстерергә, Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итүдә яңа юллар табарга булышачак. Т

ЦИФРЛЫ ЭКОСИСТЕМА хочуHALAL

РОССИЯНЕҢ БӨТЕН ХӘЛӘЛ-ИНДУСТРИЯСЕН БЕРЛӘШТЕРҮГӘ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН ПЛАТФОРМА

Бүген Россиядә **20 МИЛЛИОН МӨСЕЛМАН** яши.

Шуларның 15 миллионы – ХӘЛӘЛ ИНДУСТРИЯНЕ АКТИВ КУЛЛАНУЧЫ.

Россиядә һәм БДБ илләрендә БҮГЕНГЕ КӨНГӘ КАДӘР ХӘЛӘЛ ИНДУСТРИЯ БАЗАРЫНДА ГАМӘЛДӘ БУЛГАН БАРЛЫК ХЕЗМӘТЛӘРНЕ КОЛАЧЛЫЙ ТОРГАН УҢАЙЛЫ СЕРВИС ЮК ИДЕ.

хочу HALAL ЭКОСИСТЕМАСЫНА ТҮБӘНДӘГЕ ХЕЗМӘТЛӘР КЕРӘ:

МӘЧЕТЛӘР ЯНӘШӘДӘ* (барлык мәчетләр – картада, дин әһелләренең фотолары, аларга сорау бирү мөмкинлеге бар)

КАФЕ ҺӘМ КАПКАЛАП АЛУ* (биредә кулланучылар «Хәләл» сертификатына ия җәмәгать туклану нокталарын тиз генә таба ала)

ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ* (Ислам кануннарында рөхсәт ителгән төрле хезмәтләр һәм бүлекләр буенча навигация эшли)

КУНАКХАНӘ ҺӘМ ТУРЛАР (биредә мөселманнарның туклану һәм көнкүрештәге ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган кунакханә һәм турлар тупланган)

B2B СЕРВИСЫ (монда эшкуарлар бер-берсен таба һәм хәләл продукцияне күмәртәләп сату белән шөгыльләнә ала)

«ХӘЛӘЛ» КРИТЕРИЕ БУЕНЧА МАРКЕТПЛЕЙС («Азык-төлек» һәм «Йорт һәм көнкүреш товарлары» юнәлешләре буенча)

ПАРТНЕРЛЫК ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫ

РЕКРУТИНГ (биредә эш бирүчеләр ислам нигезләрен белүче хезмәткәрләр таба ала)

* Әлеге сервислар эшли башлаган, хәзер бизнес һәм дини оешмалар вәкилләре актив теркәләләр. Башка сервислар проектның юл картасына туры китереп гамәлгә ашырылачак.

СОЦИОЛОГИК ЯКТАН ТИКШЕРҮ

85% хәләл индустрия хезмәтләреннән һәм навигаторларыннан файдалана

87% башка шәһәрләргә барганда хәләл сервисларны һәм туклану урыннарын эзләүдә кыенлык кичерә

63% шул ук вакытта үз шәһәрләрендә хәләл индустрия товар һәм хезмәтләрен эзләүдә кыенлык кичерә

96% әлеге проблемаларны хәл итәргә тиешле яңа онлайн-сервисның җитмәвен күрсәтә

Россия венчур форумы - 2024 кысаларында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов каршында проектны презентацияләү.

РЕКЛАМА

скандинавия
ИГЪТИБАРЛЫ МЕДИЦИНА КЛИНИКАСЫ

(843) 200-10-65

«Скандинавия» клиникасының бала тудыру йортында ислам кануннарына туры китереп бәби табарга була

Клиникабыз Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты тарафыннан бирелгән таныклыкка ия, ул ислам кануннары нигезендә бәби таптыру мөмкинлеген раслый.

- Палатада кеше һәм хайван сурәтләре, шулай ук исламның әхлакый-этик нормаларына каршы килгән предметлар һәм рәсемнәр юк.
- Намаз уку өчен кирәкле атрибутлар (Коръән, намазлык, тәсбихләр) бар. Изге Кәгъбә юнәлеше билгеләнгән.
- Туалет бүлмәләрендә тәһарәт алу өчен кирәкле һәрнәрсә бар.
- Хатын-кыз табиблардан гыйбарәт махсус бригада оештырылган.
- Хәләл ризык бирелә.
- Дарулар һәм дәвалау максатларында кулланыла торган әйберләрнең ислам кануннары буенча медицина хезмәтләре күрсәткәндә файдалануга рөхсәте һәм шуны раслаган документлары бар.
- Хатын-кыз бала табу бүлегендә йөргән чакта, махсус кагыйдәләр үтәлә: аны чит кешеләр һәм клиника хезмәткәрләре күрми.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты продукция сыйфатын контрольдә тоту шәхси учреждениесе.

Бала тудыру йорты сайтына күчү өчен, QR-кодны сканерлагыз.

ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ ТАЛӘП ИТЕЛӘ

ЛИЦЕНЗИЯ БЕЛӘН КЛИНИКА САЙТЫНДА ТАНЫШЫРГА БУЛА. РЕКЛАМА

МИНСК, БАКУ, ТАГЫН ӘЛЛӘ КАЙЛАРГА...

«ВАМИН» ХӘЛӘЛ ЭКСПОРТ ЛИДЕРЫНА ӘЙЛӘНӘ

«Вамин» компаниясенең девизы: «Һәр йортка – тәмле, файдалы, табигый продуктлар». Табыннарында «Вамин»ның тәмле һәм сыйфатлы сөт ашамлыклары булган йортлар географиясе һаман киңәя бара: бүген компания Татарстанда җитештерелгән хәләл продукцияне чит илләргә чыгаручылар арасында иң алдынгылардан санала.

Хәер, компания Татарстандагы рейтинглар лидеры гына түгел. Мәсәлән, 2022 елда Россия сыр җитештерүчеләре рейтингында «Вамин» 7 нче урында булган. Әмма кабат хәләл экспортка әйләнеп кайтыйк әле (сүз уңаеннан, бүген предприятиенең бөтен продукциясе дә хәләл сертификатына ия). Әлеге тармакта әйдәп баручы экспортчылар сафына компания шактый тиз арада килеп кергән, чөнки «Вамин» чит илгә беренче хәләл продукциясен 2020 елның ноябрендә генә чыгара башлаган. Ул елны бөтен экспорт нибары 10 тонна тәшкил иткән. 2023 елда исә әлеге күрсәткеч 2 мең тоннага җиткән!

«Продукциябезнең югары сыйфаты, барлык хәләл һәм халыкара стандартларны төгәл үтәү, шулай ук дөнья базарларында актив тәкъдим ителү безне республикадагы хәләл экспорт лидерына әйләндерде», – ди «Вамин» компанияләр төркеме җитәкчесе Минтимер Минһаҗев.

Бүген «Вамин» үз продукциясен Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм Азәрбайҗанга озата. Мәсәлән, Татарстанда җитештерелгән коры эремчек порошогы былтыр Казахстанда җирле базарның 22 процентын тәшкил иткән.

Сүз уңаеннан, нәкъ менә коры эремчек порошогы предприятиенең экспортка иң күп чыгарыла торган продукциясе булып тора. Чөнки гадәти сөт ризыкларын саклау өчен билгеле бер температура таләп ителә, аларның яраклылык вакыты чикләнгән. Минтимер Минһаҗев әйтүенчә, коры эремчек порошогы температура үзгәрешләренә чыдам һәм озак саклана ала. Шунлык-

Фотолар «Вамин» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

тан аны шактый еракта урнашкан партнерларга җибәрү – бик яхшы стратегик карар. Шул ук вакытта «Вамин» киләчәктә ерак илләргә экспортка чыгару өчен яңа формадагы һәм типтагы продуктлар җитештерү мөмкинлеген дә кире какмый.

Ә якын чит илләрдәге кибет киштәләрендә кулланучылар бүген компаниянең «Вамин», «Мой милок», «Арчиз» брендлары белән чыгарыла торган продукциясенең тулы ассортиментын таба ала. Бу җәһәттән, мәсәлән, Беларусь кейсы бик кызыклы. Әлеге илнең үз сөт ризыклары да бик шәп бит... Әмма, Минтимер Минһаҗев әйтүенчә, тугандаш илнең сәүдә челтәрләре Татарстан продукциясен дә бик теләп сата, хәтта хезмәттәшлекне тагын да арттыру яклы. Бу, сүз дә юк, безнең продукциянең сыйфаты турында сөйли – чөнки белоруслар бик сыйфатлы ризыкка күнеккән. Ә «Вамин»ның югарыда аталган коры эремчек порошогы, җирле җитештерүчеләр үз продукциясен Кытайга җибәрә башлагач, белорус базарында әлеге продуктка кытлыкны бетерергә ярдәм иткән.

Сүз уңаеннан, хәзер «Вамин» да Кытай базарына чыгарга ниятли, әлеге илдә үз продукциясенә аудит әзерли. Якын арада компания Кытайдагы халыкара күргәзмәдә катнашырга җыена. Шулай ук Вьетнам, Филиппинда һәм компания өчен инде традицион булган якын чит илләрдә, аерым алганда, Таможня берлеге илләрендәге күргәзмәләрдә катнашу планлаштырыла.

Минтимер Минһаҗев әйтүенчә, мондый халыкара күргәзмәләрдә катнашу чит илләрдә яңа сатып алучылар җәлеп итүгә бик булыша. Бу үз продукцияңне бөтен дөньядагы потенциаль клиентлар аудиториясенә тәкъдим итү, булачак партнерлар һәм дистрибьюторлар белән элемтәләр урнаштыру, башка илләрдәге коллегалар белән тәҗрибә уртаклашу, шулай ук сөт тармагындагы заманча тенденцияләр һәм инновацияләр белән танышу мөмкинлеген бирә. Болар барысы да сату географиясен киңәйтүгә һәм чит илләрдә яңа сатып алучылар санын ишәйтүгә булыша.

«Мисалга, Таможня берлеге күргәзмәләрендә катнашу безгә тиз арада клиентлар базасын тупларга мөмкинлек бирде, ә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге күргәзмәдән соң ярты ел үткәч, без Азәрбайҗан белән хезмәттәшлек итә башладык», – дип аңлатты «Вамин» җитәкчесе.

Чит илләрдәге яңа партнерлар турында сөйләгәндә, Минтимер Минһаҗев предприятиенең, инде алда санап кителгән илләрдән тыш, тагын Әрмәнстан, Грузия, Төрекмәнстан, Вьетнам, Филиппин һәм Монголиягә дә экспортка рөхсәт алуын әйтте. Димәк, тиздән анда да Татарстан продукциясенең сыйфатын бәяли алачаклар.

Гомумән алганда, «Вамин» компаниясенең глобаль максаты – экспорт юнәлешеннән барлык керемнең өчтән берен алуга ирешү. Продукциянең чит илләрдә нинди тизлектә танылуын күргәч, компания әлеге максатка һичшиксез ирешәчәк дип, бер дә шикләнми әйтергә була.

«ИДЖАРА-ЛИЗИНГ»: ПРОЦЕНТ АЛУ ТЫЕЛА

Татарстан компаниясе финанс арендасы – шәригать нормалары буенча лизинг хезмәтләре күрсәтә.

ИДЖАРА ЛИЗИНГ

Мәгълүм булганча, 2023 елның көзендә илнең дүрт төбәге – Дагыстан, Чечня, Башкортстан һәм Татарстанда партнерлык финанслары буенча эксперименталь хокук режимы эшли башлады. Әлеге экспериментның асылы шунда ки, ул ислам банкингын – шәригать нормалары буенча финанс хезмәтләре күрсәтү системасын – дәүләт дәрәҗәсендә сынау мөмкинлеген бирә.

Моңа бәйле рәвештә, хәзер инде замана кешесе үз тормышын аннан башка күз алдына да китерә алмаган гадәти банкинг яңа үзенчәлеккә ия була. Бу шул исәптән лизингка да кагыла: әлеге финанс хезмәте бизнеска мөлкәттән файдалану, аның белән акча эшләү, нәтиҗәдә исә соңрак аны бөтенләйгә үзенә сатып алу мөмкинлеген бирә.

ӨЧ ТӨП АЕРМАСЫ

Ислам лизингының асылын безгә «Иджара-Лизинг» ҖЧҖндә аңлаттылар, ул – партнерлык финанславы буенча экспериментта катнаша торган Татарстан компанияләреннән берсе. «Иджара-Лизинг» ҖЧҖ беренче чиратта үзе тәкъдим иткән финанс продуктының өч төп аермасына игътибар бирә.

Беренчесе. Иджара (хәләл) – аренданың үзгә бер төре, ислам лизингы – бу вакытта лизинг предметы аренда хакы хисабына арендачыга вакытлыча файдалануга тапшырыла, соңрак аны сатып алырга мөмкин булачак. «Иджара-Лизинг» ҖЧҖ килешүләрендә, традицион лизингтан аермалы буларак, активтан файдаланган өчен Коръәндә тыелган процент ставкасы юк.

Икенчесе. Классик лизингтан аермалы буларак, аренда түләүләре аренданың буеннан-буена үзгәрешсез кала.

Өченчесе. Лизинг предметын бары тик шәригать нормаларына яраклы эштә генә файдаланырга ярый.

ӨЧ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Беренчесе. Ислам лизингында лизинг компаниясе актив (күчемсез милек, җиһазлар, транспорт һ.б.) сатып ала һәм аны клиентка билгеле бер вакытка арендага бирә. Клиент, үз чиратында, аренда хакын түли.

Икенчесе. Эшкуарларга һәм компанияләргә хәвефсез һәм рибасыз финанс ярдәме күрсәтү.

Өченчесе. Лизинг компаниясе тарафыннан махсус мөлкәт килешүенә лизинг предметын кертү – ул бөтен килешү срогы дәвамында лизинг предметының хуҗасы булып кала һәм лизинг алучыга вакытлыча файдалануга гына тапшыра.

– Партнерлык – ислам финанслары буенча экспериментта катнашучы статусы безнең өчен зур әһәмияткә ия, чөнки компаниябезнең үсеше һәм уңышлы килачәге өчен өстәмә этәргеч бирә. Шунысы бигрәк тә мөһим: әлеге ысул үзләренең финанс эшчәнлегендә ислам нормаларыннан тайпылмаска ниятләгән мөселманнарның ихтыяҗларын исәпкә ала, – ди «Иджара-Лизинг» ҖЧҖ директоры Илнур Садретдинов.

Тагын шунысын да әйтергә кирәктер: «Иджара-Лизинг» ҖЧҖ ТР Инвестиция-венчур фондының бүлендек компаниясе булып тора, аның белгечләре гаять зур тәҗрибәгә ия һәм клиентларның барлык сорауларына да төгәл җавап бирергә сәләтле.

Фото «Иджара-Лизинг» ЖЧҖнән алынды. РЕКЛАМА

ХӘВЕФСЕЗ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР: ЫШАНЫЧЛЫ ИСЛАМ БАНКИНГЫ

Хәвефсез инвестицияләр була аламы? Әйе, бары тик шикле эшкә керешмәскә һәм зур табыш артыннан кумаска туры киләчәк. Ә инде бу «тын диңгез култыгын» ликвидлы залог һәм диверсификация белән ныгытсаң? Барысын да бер кәрзингә тутырмыйча, төрле проектлар буенча таратсаң? Аннары исә РФ Үзәк банкы гарантиясенә ия булсаң? Килешәсездер, кызыктырырлык тәкъдимнәр. Ихтимал хәвефләрне киметү максатында стартапларга алынмыйлар – инвестицияләрне куркыныч астына куймас өчен проектның кимендә бер ел табышлы эшләве таләп ителә. Һәм инде күрсәткечләрнең иң мөһиме – 2010 елдан бирле барлык инвесторлар да плюста!

Югарыда саналганнарның барысы да «Амаль» Финанс Йортына (ФЙ) кагыла – биредә җәлеп ителгән инвестицияләргә активлар сатып алалар һәм шуларны өлешләп түләү мөмкинлеге белән партнерлык шартларында клиентларга саталар.

Мәсәлән, Казандагы «ITLE» рестораны үз эшчәнлеген башлаганда җиһазларның бер өлешен «Амаль» ФЙ аша сатып ала. Финанс Йорты инвесторлары ышанычлы акчалар эшли, чөнки кертемнәр матди активларга ия аңлаешлы проектка тотыла. Бу инде криптовалюта, биржа кебек буш һавага акча кертү түгел. Аннары ITLE тулы куәтенә эшли торганга әйләнә, тик һава чистарту белән проблемалар килеп чыга – ресторанны йә ябарга, йә камилләштерергә кирәк була. Моның өчен үз акчасы җитеп бетмәгәнгә, ITLE кабат ярдәм сорый – кыйбатлы һава суырту һәм чистарту системасы кую өчен хәләл бурыч ала. Проблема хәл ителә, ресторан кабат эшли башлый. «2016 елдан бирле «Амаль» белән эшләп, без Аллаһы Тәгаләнең рибалы кредитлардан баш тартучыларга хәерхаһлы булуына инандык», – ди үзенең видеобәяләмәсендә «ITLE» компанияләр төркемен оештыручы **Руслан Хәйретдинов.** Һәм чыннан да компаниянең үсеше күз алдында: бүген инде бу ресторан гына түгел, тагын бистро, стейк-кафе, кулинария, китереп бирү хезмәте һәм 3,5 мең кв. метр мәйдандагы әзер ризык фабрикасы да.

«Күзләр» офтальмология клиникалары челтәре дә – Финанс Йортының даими клиентларыннан берсе. Мединанның динамик үсеше заманча һәм югары технологияле җиһаз – лазерлы офтальмология фемтосекунд системасы урнаштыруны таләп итә. Ә тиз арада гына рибасыз кредитны кайдан алып була? Моңа җавапны хәзер инде сез дә беләсез. Клиникалар челтәрен оештыручылардан берсе **Ренат Рәхимов**: «Клиентларның уңышлы операция өчен рәхмәте «Амаль» Финанс Йортына да юллана. Без аларның нинди югары стандартлар буенча эшләвен беләбез һәм ярдәм сорап гел аларга мөрәҗәгать итәбез», – ди.

Үзләренең көндәшлеккә сәләтен арттырып һәм үсеш өчен мөмкинлекләрен киңәйтеп, өлешләп түләү хисабына клиентлар үз бизнесларын тиз арада яңа активлар белән тулыландыра ала, ә инвесторлар аңлаешлы проектларда акча эшли. Бер инвесторның акчасы өлешләп түләү буенча берничә килешүгә бүленә. Әгәр дә клиент берәр айда бурычын түли алмаса, инвесторның портфелен башка клиент коткарып кала.

Башта кеше «Амаль» ФЙ аша товарлар алып, процессны күзәтеп, өйрәнеп, аннары инде үзе инвесторга әйләнгән һәм капиталын ышанып тапшырган кейслар да бар. Мондый симбиозның гәүдәләнеше – «СушиШок» компаниясен оештыручылардан берсе **Эли Кагарбеков** әйтүенчә, ул ике очракта да – клиент буларак та, инвестор сыйфатында да файда гына күргән.

«Амаль» ФЙ белән хезмәттәшлек итүчеләрнең һәркайсы диярлек моның гел уңышлы булуына басым ясый. Ни өченме? Компания комплекслы финанслар экосистемасын төзергә омтыла – ул исә, үз чиратында, клиентларга финанс хезмәтләрен һәм инвестиция инструментларын намуслылык, гаделлек һәм иминлек барыннан да өстенрәк саналган ислам нормалары буенча алу мөмкинлеген бирә.

Компаниянең рәсми сайтында һәм социаль челтәрләрендә эшләнгән эш, нәтиҗәләр турында тәфсилле хисаплар, чын бәяләмәләр куела. Бу инвесторларга дөрес карар кабул итәргә һәм инде ундүрт ел буе компаниягә үз финансларын ышанып тапшырырга булыша. Т

* *Юридик атамасы – «Амаль» Кулланучылар җәмгыяте.*

Фотолар «Амаль» КЖнән алынды. РЕКЛАМА. «Амаль» КЖ

Партнерлык (ислам) финанслары

- **Ислам исәп-хисап счеты**
- **Ислам картасы**

Шәригать принципларына нигезләнгән

Өстенлекләре:

- акчаларны ислам нормалары буенча барлау һәм саклау
- шәригать принципларына тулысынча туры китереп эшләү
- карталарны түләүсез чыгару һәм хезмәт күрсәтү

8-800-2005-245
avtogradbank.ru

АвтоградБанк

РЕКЛАМА. АО «АВТОГРАДБАНК»

«Автоградбанк» АҖ, РФ Үзәк банкы тапшырган 1455 нче лицензия

AGROMASTER
ЖИТЕШТЕРҮ КОМПАНИЯСЕ
TILLERMASTER
УРТАЧА ТИЗЛЕКЛЕ КУЛЬТИВАТОР
CLASSICMASTER
ЧӘЧҮ АЛДЫ КУЛЬТИВАТОРЫ
MEGADISK
КИҢ ЙӨРЕШЛЕ ДИСКЛЫ АГРЕГАТ
TILLERDISK
КОМБИНАЦИЯЛЕ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGRATOR ANCER
АНКЕРЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
AGRATOR DISK
ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЫ
тел.: 8(85556) 2-39-08
тел.: 8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru
Реклама
Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай урамы, 33 а
AGROMASTER
Европа сыйфаты – Россия бәясе!

Фотолар Шәйхенуровларның гаилә архивыннан. РЕКЛАМА

ШӘЙХЕНУРОВЛАР ГАИЛӘСЕНЕҢ «ШӘРЫК ТӨСЛӘРЕ»

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисадый форумына бөтен дөньядан эшкуарлар җыелды. Алар арасында Үзбәкстаннан Рената һәм Таһир Шәйхенуровлар гаиләсе дә бар иде. Алар, бик рәхәтләнеп, кояшлы Үзбәкстан, һәр нәрсәне җете «шәрык төсләре»нә буярга сәләтле компанияләренең оешу тарихы турында сөйләделәр.

ЭШНЕҢ НИЧЕК БАШЛАНГАНЫН ХӘТЕРЛИМ...

Таһир Шәйхенуровның Ташкентта East Color дип аталган гаилә предприятиесе эшли, татарчага тәрҗемәдә бу атама «Шәрык төсләре» дигәнне аңлата.

Таһир Рафаил улы әйтүенчә, бүген аның гомерлек эшенә әйләнгән бизнеска юл озын һәм сикәлтәле булган.

– 1994 елда мин Ташкент автомобиль һәм юл төзелеше институтын «Автомобиль хуҗалыгы» белгечлеге буенча тәмамладым, – дип искә ала ул. – 1988 елда, әле студент чагында ук, автослесарь өйрәнчеге вазыйфасында эшли башладым. Баш механик дәрәҗәсенә кадәр күтәрелдем!

Ләкин институтны тәмамлагач, белгечлегем буенча эш табу омтылышларым уңышсыз тәмамланды. Ул вакытта Үзбәкстанда нәкъ менә бәйсез дәүләт төзелеше чоры бара, предприятиеләр ябыла, эшчеләр кыскартыла иде. Башкалар кебек мин дә үземне киләчәктә нәрсә көткәнен белми йөрдем. Нәрсә эшләргә? Үз урыныңны табу, профессиональ уңышка ирешү өчен, нинди чаралар күрергә?

КОЙГАН ДА КУЙГАН БАБАСЫ

– Сүз уңаеннан, бу урында Таһирның бабасын искә төшерер вакыт, – дип сүзгә кушыла Рената. – Революциядән соң Идел буенда коточкыч ачлык башлангач, ул Татарстаннан Ташкентка китә. Юлда көчкә исән кала, ләкин шулай да барып җитә. Ул эйдәп баручы тракторчы-механик булуга ирешә. Шулкадәр кыйммәтле кадр була ки, аны хәтта фронтка да җибәрмиләр, чөнки ил ул вакытта тракторчыларга һәм бигрәк тә механикларга шулкадәр зур мохтаҗлык кичерә. Ул тракторда тәүлек әйләнәсе эшли, хәтта балаларын да айлар буе күрми. Мамык, бодай – барысы да фронтка, барысы да җиңү өчен... Хезмәт батырлыклары өчен ул орденнар белән бүләкләнә, аларның берсе тракторчыга Мәскәүдә, ВДНХда тапшырыла. Ә бит ул барысын да үзлегеннән өйрәнгән, бернинди белеме булмаган. Гарәп хәрефләре белән яза, татарча сөйләшә... Татар теле үзбәк теленә охшаган, бу исә трактор иярләү серләрен үзләштерүне җиңеләйтә.

Таһир да нәкъ шундый – укый, өйрәнә, ирешелгән белән канәгатьләнеп, беркайчан да туктап калмый. Ул Үзбәкстанда лак-буяу җитештерү эшен үстерүдә пионер булып тора. Европа технологияләрен алып кайтып, гамәлгә кертте, йөздән артык төрдәге төзелеш материалы чыгара. Безнең компанияне юктан бар итте! – дип, горурланып сөйли ире турында Рената.

– Болары, әлбәттә, соңрак булды, – дип елмая лак-буяу җитештерү тармагы пионеры. – Башта мин нәрсә эшләргә кирәклеген аңларга тырыштым. Танышларымның күбесе эшмәкәрлек белән шөгыльләнә башлады – кемдер җитештерү, ә кемдер сату-алу эшенә керешә, – дип, болгавыр 90 нчы елларны искә төшерүен дәвам итә Таһир. – Коммерсантларның эшләре бара иде.

САГЫЗГА ЙӨЗ ДОЛЛАР

– Мин үземне сәүдәдә сынап карарга булдым, – ди Таһир. – Дусларымнан 100 доллар бурыч алып, Ташкенттагы күмәртәләп сату фирмасыннан бөтен акчага сагыз һәм шоколад сатып алдым да, бу байлыкны сатарга дип, рейс автобусында Сәмәркандка киттем. Әлеге сәфәрдә мин беренче 100 долларымны эшләдем. Шул рәвешле бизнесыма старт бирелде.

ИХТЫЯҖ ҺӘМ СЫЙФАТ

Берничә ел үземне бизнесның төрле өлкәләрендә сынап карадым һәм төзелеш материаллары белән сәүдә итүгә тукталдым. Әнә шул чакта башта беренче акыллы фикер туды да. Эш шунда: миңа гел лак-буяу ише товарлар кытлыгы белән очрашырга туры килде. Чөнки лак-буяу материаллары җитештерә торган эре оеш-

маларга зур чиратлар аркасында эләгү бик кыен иде. Даими клиентларымның ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, миңа лак-буяу продукциясен вак җитештерүчеләрдән сатып алырга туры килде, ул вакытта аларны «цеховиклар» дип йөртәләр. Лакларга һәм буяуларга ихтыяҗ зур булу һәм көндәшләрнең азлыгы аркасында «цеховиклар» җитештерелгән продукциянең сыйфатын кайгыртып тормый. Бу исә, әлбәттә, сатып алучыда канәгатьсезлек уята. Шикаятьләрне ачыклау-тикшерү күп вакыт, көч һәм чыгымнар таләп итә.

Лак-буяу продукциясенә зур ихтыяҗ барлыгын һәм сыйфатның түбәнлегенә бәйле кыенлыкларның туып торуын истә тотып, мин җитештерү предприятиесе ачарга карар кылдым. Һәм аңа East Color (Шәрык төсләре) дип исем бирдем. Бу 2003 елның 20 маенда булды!

ИҢ БАШТА

Шулай итеп, 2003 елның маенда East Color предприятиесе эшенә башлангыч бирелә.

Без мәйданы 300 кв. метр тирәсе булган административ бина, 600 кв. метрлы цех белән склад урнашкан кечкенә территорияне арендага алдык. Административ бинада кабинетлар, киенү-чишенү бүлмәләре, лаборатория һәм техник бүлмәләр ясадык. Цех бинасында эмальләр җитештерә торган бер линия һәм сулы буяулар җитештерә торган тагын бер линия көйләдек. Чимал һәм әзер продукцияне анализлау өчен кирәкле минималь лаборатория җиһазлары җыелмасын сатып алдык.

Зур максатларга омтылган егетләрдән команда туплап, җитештерү эшенә керештек.

Беренче еллар, әлбәттә, авыр булды. Тәҗрибә юк, без күп хаталар җибәрдек һәм шулардан сабак алып өйрәндек. Ләкин егетләрнең омтылышы, үҗәтлеге, максатчанлыгы һәм булдыклылыгы кул селтәргә юл куймады.

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ БҮЛӘГЕ

Өстәвенә, кадерле кешем – хатынымның ярдәме дә биниһая зур булды. Аннан башка нәрсә эшләр идем икән?! Рената белән без һәрвакыт хәрәкәттә: аның идеяләре күп, ул мине алга этәрә, мин шул идеяләрне үстерәм һәм тормышка ашырам. Менә шундый бик шәп

гаилә – җитештерү тандемы килеп чыга. Ул – муен, мин – баш. Дөресен әйткәндә, муеным бик яхшы.

– Мондый «муен»ны каян таптыгыз?

– Мин аны Ташкентта таптым. Һәм моны Аллаһы Тәгаләнең бүләге дип саныйм, – дип сокланып карый Таһир хатынына. – Акыллым, уңганым ул. Бу яктан мин бик бәхетле һәм аның урынында башканы кемнедер күз алдына да китермим.

ТУГРЫ КОМАНДАБЫЗ

Мин тормыш иптәшемнән дә, командамнан да бик уңдым, дип уйлыйм, чөнки алар җаваплы һәм үз эшенә тугры кешеләр.

Без көненә 12–14 әр сәгать эшләдек, берьюлы төрле вазыйфаларны башкардык, барысын да менә хәзер, бүген эшләргә теләдек, иртәгәгә калдырмадык. Якынча 6–9 ай алны-ялны белми эшләгәннән соң, зур ширкәтләр, көндәшкә санап, безнең турыда сөйли башладылар. Ул мизгелдә безне горурлык хисе биләп алды, хезмәтебезнең шундый нәтиҗәсе өчен куандык. Бу да коллективка алга бару өчен көч өстәде һәм этәргеч бирде.

КАДЕРЛЕ ҖИҢҮЛӘРЕБЕЗ

– Профессиональ бәйгеләрдә катнашканыгыз булдымы?

– Даими рәвештә! – бармакларын бөгә-бөгә санап, Таһир үзләренең җиңүләрен искә төшерә башлый. – 2005 елда безнең предприятие «Ташаббус–2005»* район конкурсының «Районның иң яхшы эшкуары» номинациясендә катнашу өчен чакыру алды. Анда без жюри тарафыннан иң югары бәягә лаек булып, беренче урынны яуладык. Ә «Ташаббус–2005» шәһәр конкурсында «Башкаланың иң яхшы эшкуары» номинациясендә икенче урын алдык.

* *Ташаббус – инициатива. Үзбәкчәдән тәрҗемә.*

«Ташаббус–2006» бәйгесендә дә сынатмадык, янә беренче урын алып, янә «Районның иң яхшы эшкуары» дип танылдык.

2007 елда «Үзбәкстанда җитештерелгән–2007» күргәзмәсендә «Иң яхшы стенд өчен» номинациясендә өченче урын алдык...

Җиңүләребезнең кыйммәте шунда ки, алар дәрт-рухыбызны, энергиябезне искиткеч ныгытты, коллективны яңа идеяләр белән баетты.

«ФУТБОЛ КЫРЫ»НА КҮЧҮЕБЕЗ ТАРИХЫ

2007 елга җитештерү күләме һәм предприятиедә эшләүчеләр саны шулкадәр артты ки, без инде арендага алынган территориядә сыймый башладык. Шуңа күрә предприятие лизингка Сергели сәнәгать зонасында җитештерү өчен тәгаенләнгән территория сатып алды. Гомуми мәйданы 4 гектар булган бу территориягә 10 000 кв. метр чамасы сәнәгать биналары һәм 900 кв. метрлы административ бина да керә.

Шунда мин балачагымны искә төшердем. Миңа 9 яшь булганда, гаиләбез яңа фатирга күченде: 45 кв. метрлы фатирдан – 100 кв. метрлыга. Ул вакытта мин үземне футбол кырына күченгән кебек хис иттем, бөтен аермасы – стеналары гына бар. Яңа территориягә күченгәндә дә, шундый ук хисләр тойдым.

Яңа җирдә җитештерү эшен җайга салып җибәрү өчен, кыска гына вакыт эчендә без 3 километрдан артык үз электр линиябезне үткәрдек, газ белән тәэмин итү өчен торба суздык, җиһазларны көйләдек һәм ике айдан старт төймәсенә бастык. Шул вакыттан предприятиедә масштаблы үсешнең яңа этабы башланды.

БУЯУЛАР ӨЧЕН ҮЗ САВЫТЫБЫЗ

Җитештергән продукциябезне тутыру өчен савытларның вакытында китерелмәве белән проблемалар предприятие үсешендә даими рәвештә тоткарлыклар чыгара иде. Андый савытлар белән тәэмин итүчеләрдә өзеклекләр еш күзәтелде.

Шуңа күрә үзебезнең пластик һәм калай савытларыбызны җитештерү турында карар кабул иттек. Банк кредиты хисабына җиһазлар сатып алдык һәм 2008 елда – полимер савыт-саба, ә 2009 елда калай савыт-саба җитештерү цехын эшләтеп җибәрдек.

АЛДЫНГЫЛАР БИШЛЕГЕНДӘ

Хәзер без 35 төрдән артык лак-буяу материалы чыгарабыз һәм ирешкәннәрдә туктап калырга җыенмыйбыз. Предприятие хезмәткәрләре кулланучыларның ихтыяҗын канәгатьләндерү максатыннан яңа продукция төрләрен җитештерү юнәлешендә даими эш алып бара.

Предприятиебез лак-буяу һәм бизәү материаллары җитештерә торган алдынгы компанияләр исемлегендә беренче бишлеккә керә. East Color бренды бик яхшы абруйга ия, базарда аның продукциясенә ихтыяҗ зур.

Тарихыбыз дәвамында без бик күп нәрсә эшләдек, мин тагын да күбрәккә ирешә алуыбызга ышанам! East Color командасын алда киң колачлы планнар һәм яңадан-яңа җиңүләр көтә.

БУЯУЛАР ГЫНА ТҮГЕЛ

– Һөнәри тормышыгызны лак һәм буяуларга багышлагач, башка нәрсәгә вакыт һәм көч табасызмы соң?

– БДБ илләре арасында иң зур татар диаспорасы безнең Үзбәкстанда, – ди Рената. – Этник татар буларак, Таһир татарлар Советында тора. Казанга барлык мөһим вакыйгаларга килеп йөрибез. Ташкентта яшәүче икенче буын вәкиле булсак та, без Казанга гашыйк. Монда без Үзбәкстан һәм Россия эшкуарлары арасында үзара бәйләнеш моделен формалаштырабыз.

– Үзбәкстанда татар эшкуарларының коммерциячел булмаган ассоциациясе бар, – дип дәвам итә Таһир. – Бу берләшмә озак кына эшләми торды. Максатым – ассоциация аша Үзбәкстан белән Россия төбәкләре арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне җайга салу өчен, аны тергезеп, эшләтеп җибәрү. Сөйләшүләр алып барабыз, ике якка да файдалы булырлык итеп товарлар төяп җибәрү планлаштырыла, өметле фикерләр күрәбез...

– Безне Үзбәкстан илчеләре дип атарга мөмкин, – дип өсти Рената. – Безнең татар җаныбыз Татарстанда, йөрәгебез – Үзбәкстанда. Яшь һәм энергияле президентыбыз Шәүкәт Мирзиёев илебездә дус, тыныч һәм имин мохит булдырды – Үзбәкстанда һәр халык үзен уңайлы хис итә. Европа мәктәпләрендәме, милли мәктәпләрдәме, гомуми белем бирү мәктәпләрендә булсынмы – һәркемнең үзе теләгән белемне алу мөмкинлеге бар, кеше бизнеста, фәндә үсә һәм үзе сайлаган юнәлештә теләсә нинди үрне яулый ала. Безнең миссиябез – элемтәләр булдыру. Россия эшкуарлары Үзбәкстанга курыкмыйча инвестицияләр кертә, уртак проектларны үстерә ала. Ике яклы мөнәсәбәтләрне үстерү өчен икътисадый климат бездә бер дигән. Тел белән бәйле киртәләр тумый, чөнки рус телен һәркем бик яхшы белә, менталитет аерымлыгы аркасында кыенлыклар юк, бергә эшләү уңайлы булсын өчен, барлык шартлар тудырылган.

Гомумән, Үзбәкстан бик матур! Мәдәни һәм тарихи истәлекле урыннар бихисап, ә Шәрыкка хас тәм-томнарның төрлелеген сүз белән әйтеп бетерерлек түгел, татып-ашап карарга кирәк! Пылау үзе генә дә ни тора – фыстыклы пылау, чәйханә пылавы... Пылауларның 100 ләп төре бар – барысын да санап бетерә алмыйсың! Сүз уңаеннан, ирем пылауны бик тәмле пешерә! Ишегалдында, зур казанда. Пылау пешерү ирләр кулында гына.

Таһир да бурычлы булып калмый – хатынын мактап куя:

– Ә хатыным дүрт төрле иттән шундый шәп зур бәлеш пешерә! Мичтә пешергән казы да искиткеч! Күптән түгел безнең Ташкентта татар милли ризыклары бәйрәме булды. Бөтен диаспора белән татар ризыклары әзерләдек – ашап туймаслык иде!

***

Эш дип ашау турында онытырга ярамый. Форумнан соң ук төшке ашка – ипи-тозлы, пылаулы һәм зур бәлешле Ташкентка юл тотабыз!

КИЛӘЧӘКНЕ КАЙГЫРТЫП

Ульяна Макарчикова

«Югары икътисад мәктәбе» илкүләм тикшеренү университетының Статистика тикшеренүләре һәм белем икътисады институты төзегән РФ субъектларының инновацияле үсеше рейтингында Татарстан икенче урында. Хәер, төбәкнең шундый югары урын биләве бу рейтинг өчен генә түгел, башкалары өчен дә традициягә әйләнде. ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов 2024 елны Фәнни-технологик үсеш елы, дип игълан итте. Бүген республика инновацияле нинди юнәлешләрне үстерә соң?

ПИЛОТСЫЗ КАМАЗЛАРДАН КАЗАННЫҢ 3D-МОДЕЛЕНӘ КАДӘР

Инноваторларның иң яраткан мәйданчыкларыннан берсе – Россиядә иң яшь Иннополис шәһәре. Мәсәлән, биредә инде берничә елдан бирле пилотсыз такси сынала, әлеге хезмәттән кала халкы да файдалана. Шулай ук биредә Россиядә беренче тапкыр шәһәр шартларында телефон буенча сатып алынган әйберләрне өйгә китереп бирә торган пилотсыз роботлар да сынала башлаган.

– Яшь компания һәм стартап-инноваторларга үз продуктларының тормышта ничек файдаланыласын һәм нинди кыенлыклар белән очрашырга туры киләчәген белеп тору мөһим, – дип сөйли Иннополис мэры Руслан Шаһалиев. – Аларның хезмәте яки технологияләре шәһәр шартларында ничек файдаланылачак? Безнең экспериментал хокукый карарлар кабул итүдә тәҗрибәбез бар, шунлыктан теләсә нинди яңалыкны без нәкъ менә Иннополиста сынап карарга әзер, гәрчә алар РФнең башка территорияләрендәге норматив-хокукый нормаларга тәңгәл килмәсә дә. Шәһәрнең башка

Фотолар: Анастасия Хатыйпова, tatar-inform.ru, agni-rt.ru

көндәшләреннән гаять зур өстенлеге нәкъ менә шунда, ул шуның хисабына үсә дә.

Татарстанда пилотсыз йөк машиналарын җитештерүне җайлау да актив бара. Былтыр июнь аенда «Нева» М-11 трассасының 679 нчы километрында бишенче буын линейкасыннан коммерция йөкләре ташый торган КАМАЗ-54901 машинасы базасында җыелган пилотсыз өч автомобиль эшенә старт бирелде. Июльдә тагын өч пилотсыз КАМАЗ эшли башлады, 2024 елда исә аларның саны 18 гә җитәргә мөмкин. Беренче машиналар эшли башлаганнан бирле алар катнашында бер генә юл-транспорт һәлакәте дә теркәлмәгән. Бүген Яр Чаллы автогиганты пилотсыз йөк машинасының тагын бер моделен сынарга әзерләнә.

Татарстанда шулай ук «Аврора» операцион системасын эшләү, 2023 елда җитештерелә башлаган ICL материнская платаларын бастыру белән дә шөгыльләнәләр, «Тонкор» пилотсыз очу аппаратларын җитештерәләр.

Хәзер Казанда шәһәрнең 3D-моделе ясала. Мәгълүмат системасы торак йортлар һәм социаль объектлар төзүне планлаштырырга, шәһәр программаларын гамәлгә ашыруны контрольдә тотарга, төрле карарлар кабул итәргә булышачак. Асылда, барлык катнашучылар бер үк мәгълүмат белән эшләячәк, ведомстволар бер-берсенең эшен кабатламаячак, һәм болар барысы бергә күп процессларны гадиләштерәчәк һәм тизләтәчәк.

– Бу Казанга инвестицияләр кертергә ниятләүчеләргә зур ярдәм, – ди Татарстан башкаласы мэры Илсур Метшин. – Эшкуар үз объектын урнаштырырга җыенган җир кишәрлеген алдан ук күреп торачак. Бу безнең киләчәк стратегиясе.

НЕФТЬ ҺӘМ АВИАЦИЯ

Россиянең хәзерге тарихында беренче тапкыр буларак Татарстан Республикасында галимнәр саны 14 меңнән арткан, ә яшь тикшеренүчеләр өлеше илдәге уртача күрсәткечтән шактыйга зур. Тикшеренү һәм уйлап табулар өчен эчке чыгымнарның еллык күләме 30 миллиард сумга якынлашкан.

Моннан тыш, Татарстанда 2030 елга кадәр исәпләнгән фәнни-технологик үсеш программасы эшләнгән. Ул бүген республика бюджетына кертелгән. Якындагы өч елда аның күләме 4 миллиард 754,6 миллион сум тәшкил итәчәк. Кирәк булганда базар һәм дәүләт ихтыяҗларына бәйле рәвештә программа үзгәртелә дә ала.

Казан авиация һәм Әлмәт нефть институтында ике алдынгы инженерлык мәктәбе булдырылган. Аларда авиатөзелеш һәм нефть табу тармаклары өчен белгечләр әзерләнәчәк.

КИТТУ-КАИ каршына җитештерүгә заманча материалларны (биш композит, ике аддитив һәм бер гибрид) кертү һәм 15 суверен технология һәм продукт эшләү бурычы куелган.

Әлмәт дәүләт нефть институтындагы алдынгы инженерлык мәктәбе авыр чыгарыла торган нефть запаслары ятмаларында эшләү өчен инженерлар әзерләү белән шөгыльләнәчәк.

ФӘН ҺӘМ ХАКИМИЯТ

Хәзер Татарстанда предприятиеләр белән реаль базар секторы арасындагы үзара хезмәттәшлекнең күпбаскычлы системасы төзелә, бу яңалыкны уйлап табудан алып тормышка ашырганчы киткән вакытны кыскарту мөмкинлеген бирәчәк.

– Республикадагы фән учреждениеләрендә җиһазлар базасы һәм кадрлар потенциалы интенсив яңартыла, яшьләр өчен фәнни лабораторияләр челтәре формалаштырылды, предприятиеләрнең югары уку йортлары һәм фәнни учреждениеләр белән кооперация мөнәсәбәтләре тирәнәйтелә, – дип билгеләп үтте Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов. Тик аны бер сорау борчый.

– Ни өчен зур сәнәгать предприятиеләре инновацион уйлап табуларга заказ бирми? Чөнки әле бу технология сыналмаган. Теләсә кайсы җитди технологиянең сәнәгатьтә нинди дә булса сынау җайланмасы булырга тиеш, ә моңа акча кирәк. Сәнәгать предприятиесе, заказчы моның өчен түләми. Безнең дәүләт фән өчен чыгымнарның үзен аклавына күнегергә тиеш. Шулай эшләмәгән очракта бернинди сәнәгать бәйсезлеге дә булмаячак.

ТҮБӘН СТАРТТАГЫ ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Алиса Бочкина

Стартапер булырга телисеңме? Бул гына! Әлеге принципка, һөнәри тәҗрибәгә таянып, татарстанлылар федераль дәрәҗәгә генә түгел, дөнья дәрәҗәсенә чыга алырлык проектлар уйлап таба.

Күз алдына китерик: 50-60 яшьлек тракторчы шәһәрдән 70 километр ераклыктагы авылда эшли. Эш җиңел түгел, саулыкны карап торырга вакыт юк, җитмәсә механизаторыбыз табибларга йөрүне дә өнәп бетерми. Хәер, хастаханәгә кадәр ерак та: район үзәгенә кадәр – 25 чакрым тирәсе, ә авылда ФАП кына бар. Һәм менә кызу эш өстендә тракторчының күкрәге кыса башлый. Ә көзен – инфаркт. Ашыгыч ярдәм машинасы көчкә өлгерә, бәхеткә, район үзәге хастаханәсендә ярдәм күрсәтеп, коткарып калалар. Ятып, дәваланып чыкканнан соң, элеккечә көнне төнгә ялгап эшли башлый – асылда, сәламәтлеген генә түгел, хәтта гомерен дә куркыныч астына куеп.

Әлеге тракторчының һәм авылда яшәүче башка күп кенә кешенең йөрәге сәламәт булсын өчен, Төбәкара консультация-диагностика үзәгенең (МКДЦ) реабилитация буенча баш белгече, иртә медицина реабилитациясе бүлеге мөдире Идел Табиев, хезмәттәшләре белән бергә, ишемия авыруын иртә диагностикалау максатында ConHearts («Йөрәкләрне тоташтырып») программа-аппарат комплексын эшли. Бу система ярдәмендә ФАП фельдшеры да кирәкле тикшеренүне үткәрә алачак. Мәгълүматны өйрәтелгән нейрочелтәр эшкәртәчәк. Чир билгеләре ачыкланган очракта пациентны тиз арада берәр хастаханәгә салырга кирәклеге турында автомат рәвештә хәбәр итеЛә, әйтик, МКДЦ, РКХ, Казанның 7 нче хастаханәсе, Чаллыдагы БСМП һәм башкаларга. Хастахнәдән пациентны алырга машина җибәреләчәк.

Фото: автордан алынды, tatar-inform.ru

200 ДӘН АРТЫК ГОМЕРНЕ САКЛАП КАЛУ

– Йөрәк ишемиясе – Татарстанда да, Россиядә дә авыруга һәм үлемгә китерүче сәбәпләрнең иң еш очрый торганы. Алай гына да түгел, әлеге сәбәп аркасындагы үлем күрсәткечләре бездә Европага караганда берничә тапкырга югарырак. 100 мең кешегә исәпләгәндә Франциядә ел саен 65 яшьтән өлкәнрәк 17 ир-ат үлә, ә Россиядә – 242, РФ бюджетына йөрәк ишемиясе авыруыннан килгән гомуми зыян 1 триллион сумнан артып китә, – ди Идел Табиев. – Безнең проектның максаты – авыруны иртәрәк ачыклау һәм тернәкләндерү процессын контрольдә тоту аша әлеге күрсәткечләрне киметү.

Һөнәре буенча Идел Табиев табиб-невролог, физик һәм тернәкләндерү медицинасы табибы. Ул уйлап тапкан ConHearts проектының нигезе – цифрлы продукт, программистлар тарафыннан булдырылган код. Тармак эше һәм югары технологияле карарларның шул рәвешле кушылуы бүген сәламәтлек саклау өлкәсендә генә түгел, башка бик күп өлкәләрдә дә мөмкин хәл - авыл хуҗалыгыннан алып психологиягә кадәр. Җәмгыятькә кирәкле һәм файдалы Россия стартапларына хәзер дүрт төп фактор ярдәм итә: авторларының һөнәрмәндлеге, ясалма интеллектны үстерү, инвесторлар ярдәме һәм... санкцияләр. Чит ил җитештерүчеләренең Россия базарыннан китүе, шулай ук дәүләт дәрәҗәсендә кабул ителгән импортны алыштыру курсы күп кенә эре компанияләрнең үз эшчәнлекләре өчен илебездә җитештерелә торган продуктларны эзләргә мәҗбүр итә. Стартаплар, ягъни әле киң базарга чыкмаган һәм күп яктан уникаль эшләнмәләр, корпорацияләрдә зур кызыксыну уята һәм уйлап табучыларны миллионер итә ала.

Төп приз һәм «Автошәһәрнең яшь эшкуары – 2020» исеме Сергей Сарапуловка һәм аның инновацияле Epit 5.1 3D-принтерын җитештерү проектына бирелә.

ИМПОРТ УРЫНЫНА

– Стартапны эшләтеп җибәрү турында соңгы карарны базарны тикшергәннән соң кабул иттек. Безнең юнәлеш – аддитив технологияләр буенча базарның сыйдырышлылыгы 8 млрд доллардан артыкны тәшкил итә. Ә безнең продукт керә торган өч үлчәмле басма өчен югары сыйфатлы принтерлар сату арта гына бара, – ди биш куәрле EPIT 3D-принтерлар җитештерү буенча Татарстан стартабына нигез салучы Сергей Сарапулов. Принтерның төп мөмкинлеге – анда кайбер, шул исәптән чит ил станоклары өчен детальләр бастыра алу. Шулай ук, формасын ясап тормыйча, тиз арада булачак металл эшләнмәнең прототибын бастырып чыгара алу да. Бу исә акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта EPIT Кытайдан кертелә торган аналоглар белән конкуренциягә сәләтле, 5 куәрле 3D-принтерның бюджет һәм профессиональ версияләрен җитештерүне үзләштерә, Чаллыда аларның сәнәгатьтә кулланылачак төрен чыгару максатында җитештерүне киңәйтергә әзерләнә.

Барысы да бик кызык кебек, әмма бүген Россиядә стартаперның роле авырлыклар һәм сынаулар белән бәйле. 2024 елда Россия венчур базары узган елгы сазлыктан чыга гына башлады. Чит ил фондларының китүе венчур кырын ярлыландырды, ә тотрыксыз тышкы икътисадый вазгыять инвесторларны бик уйлап сайларга мәҗбүр итә. Мондый хәлдә яңа югары технологияле инициативалар булдыручылардан беренче чиратта базарны җентекләп белү һәм көндәшлеккә сәләтле өстенлекләр уйлап табу таләп ителә.

2023 елда Идел Табиевның ConHearts проекты Россия венчур форумы күргәзмәсендә күрсәтелә.



ИТ-белгечләр өчен LearnMore белем бирү платформасын тәкъдим иткән Татарстан стартабына нигез салучы һәм идея авторы Анастасия Майорова.

МӘГЪЛҮМАТЛЫ БУЛУ – ИНВЕСТИЦИЯЛЕ БУЛУ

– Мин берничә ел дәвамында төрле онлайн-программаларга, шул исәптән уку курсларына продюсерлык иткән платформаларда экспертлар белән эшләдем. Эшнең көчле һәм җитешсез якларын өйрәндем. Әкренләп үземнең продуктны булдыру идеясе өлгерде, – дип сөйли ИТ-белгечләр өчен LearnMore белем бирү платформасын тәкъдим иткән Татарстан стартабына нигез салучы һәм идея авторы Анастасия Майорова. Россиядә мондый тәкъдимнәр базары бик бай, әмма шулай да LearnMoreда 2 меңгә якын кулланучы теркәлгән инде. Уңышның сере, дип саный Анастасия, 12 елдан артык ясалма интеллект һәм персоналаштыру алгоритмнары белән эшләүче команда белән хезмәттәшлектә, шул исәптән белем бирү платформаларын булдыру өлкәсендә дә. Проектның максаты – тиз арада ярымбуш ИТ-кадрлар базарын әзер белгечләр белән тулыландыру.

– Безнең алгоритм студентның шәхси траекториясен күзәтә һәм, тагын да әйбәтрәк уку өчен, өлгерешне яхшыртуның төрле вариантларын, өстәмә материаллар һәм башка индивидуаль биремнәр тәкъдим итә. Бу – безнең төп өстенлекләребезнең берсе, – ди Анастасия.

EPIT компаниясеннән Сергей Сарапулов, сыйфатлы старт өчен күпмедер вакыт индустрия эчендә эшләү тәҗрибәсе кирәк, дип саный.

– Безнең үсеш юлы да сикәлтәләрсез булмады. Без берничә авыр чор аша үттек: безгә кирәк булган кешеләрнең компетенцияләрен җентекләп анализлау һәм белгечләрне табу, проектка соңгы акчаларыбызны салып, прототип стадиясендә финанслар эзләү, эшчәнлегебезне коммерцияләштерү, аннан соң уңышлы тәкъдим итү. Боларның барысында да миңа элеккеге эштә эшләнмәләр бүлеге җитәкчесе булабрак алган күнекмә һәм белемнәрем ярдәм итте, – ди Сергей Сарапулов. – Продуктны уңышлы эшләтеп җибәрү өчен, индустриядә эшләп тупланган тәҗрибә кирәк. Шуңа күрә барлык эш башлаучы эшкуарларга да үз юнәлешләренә караган берәр зур компаниядә эшләп алырга киңәш итәм.

ЯРДӘМ БУЛГАН СТАРТ

Кирәкле продукт булдыру һәм аны үстерүгә зур инвестицияләр алу җиңел түгел –

шәхси фондлар соңгы елда активлыкларын киметте, ә бизнеска ярдәм кулы сузучы Россия инвесторлары илебез стартаплары белән әле күптән түгел генә җитди кызыксына башлады. Бу шартларда технологик эшкуарлык инициативасын үстерүдә һәм Россия венчурын саклап калуда дәүләт һәм корпоратив фондлар зур роль уйный. Дәүләт үсеш институтлары мәктәп укучыларыннан алып өлкәнрәк уйлап табучыларга кадәр – барлык яшьтәге яңа эш ачучыларга актив ярдәм итә. Татарстанның инвестиция-венчур фонды, мәсәлән, Евразия инновацияләр үзәге белән партнерлыкта эшләп, 2023 елда инвестицияләр күләме буенча Россия фондлары арасында лидерларның берсе булды.

– Татарстанның ИВФ һәм Евразия инновацияләр үзәге программаларында seed (чәчү, башлангыч стадияләрнең берсе – ред. иск.) стадиясендә катнашу безгә үз компетенцияләребезне үстерергә һәм 12 млн сум күләмендә инвестицияләр җәлеп итәргә ярдәм итте, нәтиҗәдә LearnMore базарга тулы күләмдә чыга алды. Хәзер без 50 млн сумнан артык акча җәлеп итәргә ниятлибез. Планда – платформаны киңәйтү, шул исәптән офлайн-форматта, илнең әйдәп баручы югары уку йортлары белән коллаборация, тагын да күбрәк укытучы-экспертлар җәлеп итү, – дип аңлата Анастасия Майорова.

ConHearts проектын Идел Табиев һәм аның командасы үз көчләре белән гамәлгә ашыра, әмма берничә ел элек Татарстан Инвестиция-венчур фонды программасы буенча откан грантка төзелгән матди-техник базага таянып. Хәзер уйлап табучыларга ConHearts проектын эшләп бетерү өчен 5 млн сум кирәк.

– Без хезмәттәшлеккә ачык, шулай ук краудфандинг, ягъни бергәләп финанслауга да каршы түгел, – ди Идел Табиев.

EPIT 3D-принтерлар проекты шулай ук әзлекле рәвештә Инновацияләргә ярдәм итү фондының «Старт» программасын, шулай ук Татарстан Инвестиция-венчур фонды химаясендә яңа стартаперлар өчен булдырылган «Старт» программасын узган. Иртә стадияләрдә 11 млн сумлык инвестицияләр җәлеп ителгән, аннары – «Сколково» резиденты, соңрак «Росатом»ның «Иннохаб» портфель компаниясе булган. Бүгенге көндә проектка җәлеп ителгән инвестицияләр суммасы 17 млн сум тәшкил итә.

Саклык банкы, X5, «Росатом», «Ростелеком» һәм башка компанияләрнең корпоратив фондлары инициативаларны реаль бизнес-кейсларга кадәр җиткерү өчен көчле акселерация программалары эшли, Россия стартапларын актив инвестицияли һәм сатып ала. Әмма аларның проектларга таләпләре шактый югары.



ТӨРЛЕ ЮНӘЛЕШЛӘР БУЕНЧА

– EPIT безнең игътибарны продуктының инде тышкы базарга чыгуы белән җәлеп итте. Акселерация программасына сайлап алу өчен безнең критерийлар арасында – «Росатом»ның гамәлдәге интеграторлары таләпләренә туры килүе һәм тышкы базарда үсеш потенциалы, ягъни өч ел дәвамында 100 млн сумлык еллык керемгә чыгу. Тармаклар диапазоны шактый зур – батарея һәм электромобильдән квант исәпләүләренә кадәр, – ди «Росатом»ның «Иннохаб» «Инновацияләр портфеле» юнәлеше җитәкчесе Алексей Аброськин. Ел саен портфельгә 5 проект сайлап алына, аларның һәрберсе 25 млн сумга кадәр инвестициягә өметләнә ала.

«Иннополис» МИЗ, Евразия инновацияләр үзәге һәм Казан ИТ-паркы белән актив хезмәттәшлек итүче «Ростелеком» корпоратив фонды 2023 елда базардагы иң активлар унлыгына керде. Фондта HR, креатив икътисад, финанс, ритейл, электрон коммерция, аналитика, цифрлы киңәшче һәм игезәкләр, әйберләр интернеты, авыл хуҗалыгы һәм башка юнәлешләрдә 100 млн сумнан кереме булган уңай юнит-икътисадлы (аклану мөмкинлеге – ред. иск.) тиз үсештәге югары технологияле стартаплар белән кызыксынуларын яшермиләр. Хәзерге вакытта, мәсәлән, фонд TravelTech – сәяхәтләрне цифрлы планлаштыру юнәлеше буенча акселерация программасына гаризалар җыя.

Аналитиклар фаразлавынча, 2024 елда венчур инвесторлары бизнес өчен программа һәм аппарат тәэмин итү, тармак ясалма интеллектына, сәламәтлек саклау, логистика, машина өйрәнү өлкәләренә караган проектларга игътибар итәчәк.

БАЛЕРИНАГА ЦИФРЛАШТЫРУ НИК КИРӘК?

ЯҢА ИКЪТИСАД ӨЧЕН ЯҢА КАДРЛАРНЫ НИЧЕК ӘЗЕРЛӘРГӘ

Әңгәмәдәш – Евгения Чеснокова

«Цифрлы икътисад өчен кадрлар» проекты гамәлдәге «Россия Федерациясенең цифрлы икътисады» илкүләм программасының мөһим проектларыннан берсе булып тора. Моңа гаҗәпләнәсе юк, чөнки цифрлы дөньяда җиңел эшли алырлык кешеләр юк икән, цифрлы икътисад та булмаячак. Һәм мондый шартларда квалификацияле кадрлар әзерләү чын мәгънәсендә стратегик бурычка әверелә.

Бер яктан караганда, нинди проблема булырга тиеш соң? Безнең югары уку йортлары IT-юнәлешләр буенча инде күптән төркем-төркем студентлар әзерли. Шулай да…

– Вуздан соң эшкә килгән студентларны, ниндидер проектларда азрак эшкә җигәргә мөмкин урта кул белгеч итеп үстерү өчен, бүген ел ярым чамасы вакыт китә, – ди Казанның ИБР компаниясен оештыручы һәм аның үсеш буенча директоры Юлия Лунина.

– Юлия Владимировна, ни өчен абруйлы уку йорты дипломы булган яшь белгечләрне өстәмә укыту ихтыяҗы туа соң?

– Без гел үзгәреп торган дөньяда яшибез, анда бик зур күләмдәге мәгълүматны тиз һәм тиешенчә эшкәртү таләп ителә. Һәм монда югары уку йортының кызыл дипломы гына түгел, хәтта элек тупланган тәҗрибә дә җитми. Күпчелек һөнәрләр бик тиз үзгәрә. Кайбер бүгенге хезмәткәрләрне (шул исәптән югары профессиональ хезмәткәрләрне дә) якын киләчәктә технологияләр алыштырачак. Ләкин хәзер үк үзләштерү кирәк булган яңа һөнәр һәм юнәлешләр барлыкка килә. Тик университет эскәмиясендә утырганда яки искечә эшләгәндә, аларны өйрәнү читен.

– Яшь хезмәткәрдән лаеклы белгеч үстерү өчен, реаль секторда цифрлы продуктлар җитештерә һәм гамәлгә кертә торган компанияләргә шактый инвестицияләр кертергә туры килә, димәк…

Фотография IBR компаниясеннан алынды. РЕКЛАМА



Безнең белешмә:

Татарстан базарында инде 12 ел эшләп килгән ИБР («Мәгълүмати бизнес-ысуллар») компаниясе предприятиене автоматлаштыру һәм аның белән цифрлы идарә итү юнәлешендәге проектларны гамәлгә ашыру өлкәсендә зур тәҗрибәгә ия. Компания 1С продуктларын төрле тармакларда гамәлгә кертә, алар арасында төп продукт – ERP, предприятие ресурслары белән идарә итү. Ширкәтнең иң билгеле клиентлар исемлегендә – «КамАЗ» ГАҖ, «Татспиртпром» АҖ, Polaris кибетләре челтәре...

– Әйе, тик шунысын да истә тотарга кирәк: соңыннан ул белгечләрнең кайберләре генә синдә эшләп калачак. Шуңа күрә без «түбәннән башладык»: егет-кызларны үзебезгә стажировкага студент чагында ук чакырдык. Стажерлар белән эшләгән арада, без бер үк вакытта үз белгечләребезне дә камилләштердек һәм шул рәвешле көчле укытучылар командасы булдырдык.

Ә федераль дәрәҗәдә цифрлаштыру программасы барлыкка килгәч һәм югары уку йортлары цифрлы юнәлештәге кафедралар ача башлагач, аларның безнең кебек партнёрларга ихтыяҗы туды. Чөнки проект шартлары кушканча, цифрлы юнәлеш кафедралары реаль сектордаге партнёрлар белән тыгыз бәйләнештә эшләргә тиеш. Безне Казан федераль университеты хезмәттәшлеккә чакырды, инде ике елдан артык бергә эшлибез.

– Практик укытучыларның югары уку йортларындагы гадәти укытучылардан төп аермасы нәрсәдә?

– Классик югары уку йорты белгече студентларга нигез белемнәрне бирә. Әгәр гамәли юнәлешле белем бирү, ниндидер проектлар эшләү турында сүз бара икән, безнең белән бергә гыйлем туплау күпкә кызыклырак һәм нәтиҗәлерәк. Без реаль сектордагы реаль бизнесның анык ихтыяҗларын күздә тотып эшлибез. Мондый проектларда егетләр һәм кызлар конкрет практик эшнең кечкенә генә булса да бер өлешен башкара. Шулай итеп, студентлар бизнеска нәрсә кирәклеген һәм теге яки бу эшнең чынбарлыктагы проблемалары ничек хәл ителүен аңлый башлый. Мондый дәрес-курслардан соң алар югары уку йортыннан реаль эш тәҗрибәсе алып чыга.

– Студентлар белән эш ничек алып барыла? Сезнең белгечләр аудиториягә киләме?

– Бөтен уку-укыту процессы читтән торып бара. Без лекцияләр укый торган, видеоматериаллар һәм эш өчен кирәкле башка материалллар куела торган махсус платформа бар. Һәр модульне узган саен, студентлар биремнәр үти һәм программа ахырында диплом эше яза.

Программаларыбыз төрле. Быел, мәсәлән, аларның берсе «Җитештерүдә предприятие ресурслары белән идарә итү» дип атала. Идарә итү һәм автоматлаштыру системаларының ниндиләре барлыгы, җитештерү белән идарә итүне цифрлаштыру кысаларында нинди мәсьәләләр хәл ителгәнлеге турында сөйлибез. Белемнәрне ныгыту өчен, студентларга практик биремнәр бирәбез, мәсәлән, машинаны җыю һәм сөтү процессын диспетчерлаштыруны оештыру яки логистик транспорт маршрутларын оптимальләштерү.

– Сез «технарь» студентлар белән генә эшлисезме?

– Юк, чөнки «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» программасы техник югары уку йортлары студентларын гына күздә тотмый. Бүген мондый цифрлы кафедраларны башка өлкәләрдә дә эшләтеп җибәрү бурычы тора. Әйтик, без инде дизайнерлар, табиблар белән эшлибез.

Мәсәлән, студентлар ниндидер күргәзмәнең дизайн-проектын ясаган, без күргәзмә кунаклары аерым экспонатлар турында тәфсиллерәк белешә, ниндидер өстәмә мәгълүмат ала алсын яки призлы, мавыктыргыч квест үтә алсын өчен, студентларга мобиль кушымтаны ничек көйләргә икәнен күрсәтәбез. Табибларны пациентның шәхси кабинеты белән ничек эшләргә, күләмле мәгълүматны ничек эшкәртергә өйрәтәбез.

Гомумән алганда, без студентларга базарда теләсә нинди эшчәнлекне цифрлаштырырга ярдәм итә алырлык нинди ысул-алымнар барлыгын күрсәтәбез. Эшкәртелә торган мәгълүмат күләме һәр тармакта зур тизлек белән үсә бара һәм хәзерге белгечләр яңа цифрлы дөньяда ничек яшәргә һәм эшләргә икәнен аңларга тиеш.

– Башка гуманитар юнәлештәге башка белгечлекләр белән эшләргә теләк юкмы?

– Әгәр вуз үзендә цифрлы юнәлеш кафедрасы оештырырга тели икән, без хезмәттәшлеккә әзер. Ә менә ул, әйтик, балет биергә өйрәтә торган уку йортында кирәкме икән, монысы инде башка мәсьәлә...

– Мәсәлән, соңыннан хаталарны җентекләп тикшерү өчен, хәрәкәтләрне цифрлаштыру...

– Кызыклы идея. Ләкин кабатлыйм: беренчел мөрәҗәгать югары уку йортыннан килергә тиеш. Әгәр алар цифрлаштыру программасын тормышка ашырырга теләп, партнёр эзләсәләр, без әзер.

– Сез белем биргән студентлар соңыннан компаниягезгә эшкә килә алырлармы?

– Без, әлбәттә, барысын да эшкә ала алмаячакбыз. Былтыр безнең аша 450 студент үтте, быел инде өч меңнән артык. Ә безнең компания 70 хезмәткәрдән гыйбарәт, бу исә оештыру стратегиябез – «суперпрофессионалларның җыйнак команда» туплауга туры килә.

Әлбәттә, безнең проектлар белән кызыксынган яшь белгечнең коллективыбызга кушылу мөмкинлеге бар. Әмма уку йортын тәмамлап башка компанияләргә эшкә барачак белгечләр дә безнең «йогынты ясаучы агентларыбыз» булачак, үз эш урыннарында безнең компания тәкъдим иткән продуктларны да гамәлгә кертәчәкләр. Гомумән алганда, алар икътисадның реаль секторында яңа технологик ысул-алымнарны тормышка ашыручылар булачак. Чөнки алар предприятие белән цифрлы идарәнең нәрсә икәнен, заманча технологияләрнең бизнесны коруга һәм нәтиҗәлерәк эшләргә ничек ярдәм иткәнен аңлыйлар.

ДАМИР НИГЪМӘТҖАНОВ:
«ХОКУК САКЛАУ ОРГАННАРЫНДА ЭШЛӘҮ ТӘҖРИБӘСЕ, БЕЛЕМ – МИНЕМ ТӨП БАЙЛЫГЫМ!»

«Контр-Юниверсити 2» хосусый сак предприятиесе (ХСП) ҖЧҖ җитәкчесенә 5 сорау

1 Сак оешмасы җитәкчесе булу өчен нинди сыйфатлар кирәк?

Предприятие 2010 елда оештырылды, ул чакта мин Эчке эшләр министрлыгы органнарыннан пенсиягә чыккан гына идем. Һичшиксез, ХСП һәм бөтен коллективның эшен югары дәрәҗәдә оештыруда миңа тәҗрибәм һәм белемем бик ярдәм итте. Безнең тармакта үздисциплина, югары әхлак һәм намус кебек сыйфатлардан башка чын профессионал була алмыйсың. Әмма боларны хезмәткәрләрдән таләп итү өчен, иң әүвәл үзең дә шундый булырга тиеш. Без профессионал булган очракта гына кешеләр безгә үзләренең иминлеген, гомерен саклауны ышанып тапшыра алачак.

Минем өчен уңышка, максат һәм хыялга ирешү юлы үзем үтәргә тиешле бик күп вак этаптан гыйбарәт. Әгәр гел соңгы нәтиҗәне генә истә тотып алга барсаң, ярты юлда хәлдән таярга һәм теләгеңә ирешмәскә дә мөмкин. Процессның үзеннән рәхәтлек алырга өйрәнү зарур, ә иң мөһиме исә – һәрвакыт кеше булып һәм үз-үзеңә тугры калу.

2 Сезнең компаниянең төп кадрлары кемнәрдән гыйбарәт?

Без – дәүләтнеке түгел, коммерция хосусый сак компаниясе, һәм безнең хезмәткәрләр – хосусый сакчы булырга өйрәтелгән гади гражданнар. Урта буын җитәкчеләренең төп кадрлары офицерлар корпусыннан чыккан. Алар – бөтен гомерләрен Ватанга хезмәткә багышлаган кешеләр, һәм бүген аларга кабат аеруча җаваплылык – куркынычсызлыкны тәэмин итү йөкләнә.

3 Сез нинди хезмәтләр күрсәтәсез?

Безнең сак оешмасы түбәндәге хезмәтләрне күрсәтә:

- Стационар объектларны физик саклау;
- Дөньяви, спорт, мәдәният, мәгариф һәм башка чараларда иминлекне тәэмин итү;
- Йөкләрне һәм аеруча кыйммәтле әйберләрне саклау һәм озата бару;
- Техник сак чаралары;
- Тиз гамәл кылу төркеме;
- Хокук яклау мәсьәләләре буенча консультация бирү;
- Шәхси сак.

Безнең соңгы яңалыклардан – иминлекне тәэмин итү һәм пилотсыз очу аппаратларыннан саклау (без хезмәткәрләребезне әлеге юнәлеш буенча укырга җибәрәбез һәм техник базабызны баетабыз), шулай ук теләсә нинди хәлдә дә сезнең иминлекне тәэмин итәргә сәләтле эскорт-тәнсакчысы өстәмә хезмәтен үстерү.

Бирегә түбәндәгеләр керә:

- Бизнес-чара, сөйләшүләр, тантана, сәфәрләрдә һәм хәйрия кичәләрендә аерым шәхесне саклап йөрү;
- Бизнес белән шөгыльләнүче хатын-кызларны эшлекле очрашуларда һәм сөйләшүләрдә саклап йөрү;
- Балаларны мәктәпкә, өстәмә дәрес, түгәрәк, секцияләргә йөртү өчен эскорт;
- Аэропортта, тимер юл вокзалларында каршылау һәм озатып йөрү;
- Күчереп йөрткәндә, командировкаларда, бизнес-сәфәр һәм чараларда, килешүләр төзегәндә аеруча кыйммәтле әйберләрне саклап тору;
- Күңелгә ятышсыз очрашулардан, кирәксез танышу һәм элемтәләрдән саклау;
- «Аек машина йөртүче» хезмәте.

4 Сезнең эш нигезенә нинди төп принциплар салынган?

Әгәр бер теория буенча Җирне өч кит тотып торса, безнең эштә андый китлар кимендә җидәү! Бу – сак хезмәтенең хөрмәт, законлылык, хокук саклау органнары белән үзара килешеп гамәл кылу, һөнәри осталыкка ия булу, оперативлык, мобильлек һәм өзлексезлеккә нигезләнүе.

5 Көндәшләрегездән нинди өстенлекләрегез бар?

Сак кәсәбәсендә көндәшлек шактый зур. Минемчә, безне нәкъ менә сыйфат аерып тора: без сак хезмәтләрен шулкадәр югары дәрәҗәдә күрсәтергә омтылабыз ки, заказчылар үзләренең иминлегендә бер генә минутка да шикләнмәслек булсын. Моннан тыш, хезмәткәрләребез белем-күнекмәләрен даими камилләштерә, без яңа юнәлешләрне үстерәбез һәм иң заманча технологияләрдән файдаланабыз. Мәсәлән, ерактан торып эшләүче хезмәткәрләребезне реаль вакытта контрольдә тотуның үзебез уйлап тапкан уникаль IT-системасын керттек, ул безгә ачыкланган проблемаларны бик тиз арада хәл итү мөмкинлеген бирә.

Фото: Луиза Габидуллина. РЕКЛАМА

«Контр-Юниверсити 2» ХСП ҖЧҖ
Юридик адрес: Казан шәһәре, Юлиус Фучик ур., 82, 1Н корылмасы
+7 (937) 292-75-57
kontrohrana@yandex.ru

«БЕЗНЕҢ БЕЛӘН ТӨЗҮ КУРКЫНЫЧСЫЗРАК»

«Татгеотикшеренүләр» компаниясе башкарма директоры Алиса Гафиятуллина геологик тикшеренүләр үткәрүнең зарурлыгы, ни өчен җиңел юллар эзләмәүләре һәм эштәге төп принциплар хакында фикер йөртә.

БАШТА ИНЖЕНЕРЛЫК ТИКШЕРЕНҮЛӘРЕ – АННАРЫ ПРОЕКТ

– Мөгаен, һәр дөрес төзелеш объекты аның эстетик ягын – тышкы кыяфәтенең нинди булуын ачыклаудан түгел, ә килеп туачак хәвефләрне бәяләүдән башланадыр: «Йортның ныклыгын ничек тәэмин итәргә?», «Нинди фундамент сайларга?», «Ничә катлы бинага исәп тотарга була?», «Төзелеш планлаштырылган җир астында берәр төрле куркыныч юкмы?» һ.б.

Әлеге һәм башка сорауларга инженерлык тикшеренүләре җавап бирә ала. Алар эшләрнең тулы бер комплексын үз эченә ала:

Геодезик тикшеренүләр – җирлекнең тулы масштаблы топографик картасын төшерү, анда әлеге җирдәге барлык конструктив элементлар һәм аларның биеклеге күрсәтелергә тиеш. Җирлекнең рельефы турында мәгълүмат алганнан соң киләсе этапка күчәргә була.

Геологик тикшеренүләр – төп нигез, анда скважиналар бораулап һәм грунт үрнәкләре алып, төзелеш планлаштырылган территориянең геологик үзенчәлекләре өйрәнелә, туфрак характеристикалары ачыклана һәм аның халәте бәяләнә. Эшебезнең нәкъ менә әлеге юнәлеше фундаментның тиешле тибын сайларга булыша.

Гидрометеорологик тикшеренүләр – гидрологик һәм метеорологик шартларның объект эшенә йогынты ясарлык үзгәреше хакында мәгълүмат бирелә. Мәсәлән, җил өермәсе, су басу, кар ишелеп төшү кебек куркыныч табигать күренешләре яки климат шартлары турында.

Экологик тикшеренүләр – төзелеш өчен сайланган мәйдандагы туфрак, һава, җир өсте һәм җир асты сулары, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының халәте һәм үзлекләре өйрәнелә. Әлеге мөһим этап проектлана һәм төзелә торган объектларның экологик куркынычсызлыгын бәяләп кенә калмый, бәлки әйләнә-тирә мохит һәм кеше сәламәтлеге өчен тискәре нәтиҗәләрне алдан кисәтергә булыша.

Төзелешнең төгәллеге һәм анда яшәячәк, эшләячәк, ял итәчәк кешеләрнең иминлеге нәкъ менә барлык шул мәгълүматларның дөреслегенә, тәфсиллегенә бәйле.

ТӨГӘЛ БУЛГАНГА КҮРӘ

– Без үз эшебездә инженерлык технологияләреннән файдаланабыз, чөнки алар төгәл, аларны төрле җайланмалар белән үлчәп була.

Мәсәлән, геодезия өчен бу иң заманча GRS-җайланмалар, алар ярдәмендә координаталарны миллиметрга кадәр төгәллек белән билгеләп була. Күптән түгел без трассаэзләгечнең яңа модельләрен сатып алдык, алар су, газ, электрика, элемтә коммуникацияләренең җир астында нинди тирәнлектә ятуын 10 сантиметрга кадәр төгәллек белән күрсәтә ала.

Геология өчен – колонкалы һәм шнеклы бораулау ысуллары («КАМАЗ», «Урал» базасындагы бораулау җайланмалары һәм «Газель» базасында кечкенә габаритлы җайланма), лаборатория тикшеренүләре, шулай ук статик зондлау методлары, кырда штамп сынаулары ысуллары һәм лаборатория шартларында грунтларны өч күчәрле кысу методлары.

Шулай ук геофизик тикшеренүләр ысулларыннан да файдаланабыз, алар җирне 100 метрга кадәр тирәнлеккә яктырту мөмкинлеген бирә.

Хәзер исә без җирлектәге зур булмаган кишәрлектә 3D-модель макетын әзерлибез, ул коммуникацияләр коридоры буйлап йөрү һәм җирнең эчке катламнарына күз салу мөмкинлеген бирәчәк. Инженерлык тикшеренүләренең киләчәге бу! Т

Казан ш.,
Вишневский ур., 24, 404 нче офис
+7 (843) 212-60-30
tatgeo@inbox.ru
tatgeo116.pro

Фото «Татгеотикшеренүләр» компаниясеннән алынды

КИЕЗ ИТЕК ЗАМАНАДАН КАЛЫШМЫЙ!

Хәзер авыл яшьләре генә түгел, модалы киенергә яратучы күп кенә шәһәр егет-кызлары да заманча киез итек киеп йөри. «Кукмара киез итек басу-киез комбинаты» акционерлык җәмгыяте исә, үзенә тугры калып та, һәрвакыт зур ихтыяҗ тудыра алуга үрнәк булып тора.



– Халык киез итекләрне борын-борыннан үз иткән. Хәзер исә табигый сыйфатлы чималдан, җитмәсә әле төрле дизайнерлык хикмәтләрен кулланып басылган әлеге аяк киемнәренең популярлыгы безнең киез итекне бөтен дөньяга танытты, – ди комбинатның генераль директоры Лэлэ Шәрипова.

ИХТЫЯҖ ҺӘРВАКЫТ БАР!

– Без мода тенденцияләренә тәңгәл килгән аяк киемнәре җитештерергә тырышабыз, – дип дәвам итә ул. – Авыл һәм шәһәр шартларында кию аерымлыкларын гына түгел, төрле яшьтәге кешеләрнең үзенчәлекләрен һәм зәвыгын да исәпкә алабыз, шунлыктан безнең киез итекләргә ихтыяҗ һәрвакыт зур. Җенесе, яше, яшәү урыны нинди булуга карамастан, һәр сатып алучы нәкъ үзе теләгән аяк киемен таба ала.

Традицион киез итекләр белән беррәттән, төрле фасондагы һәм төрле төстәге чигүле-язулы-рәсемле заманча модельләр дә бик популяр. Әлбәттә, киез итек – бик уңайлы һәм җылы аяк киеме, әмма нигә әле ул стильле һәм модалы да булмасын, ди! Җитмәсә, киез итек ел саен диярлек модалы подиумнарда пәйда була, бу исә безгә башкалардан калышмау һәм һәрдаим актуальлекне саклау өчен җитди этәргеч булып тора.

ЕЛ САЕН – ЯҢА КОЛЛЕКЦИЯ

Комбинатның төп бурычларыннан берсе – ассортиментны даими киңәйтү, дизайн һәм сыйфатны яхшырту. Базаны тәшкил иткән классик итекләр белән беррәттән, ел саен

Фотолар Кукмара киез итек басу-киез комбинатыннан алынды.. РЕКЛАМА

каталогка өлкәннәр һәм балалар өчен яңа модельләр өстәлә, аларны сәнгать советы раслый.

Мәсәлән, бу сезонда табигый аяк киеме яратучы балаларны яңа итекләр белән сөендерәчәкбез. Хатын-кызлар өчен иркенрәк кунычлы итекләр, ир-атларга исә җиңел кроссовкалар тәкъдим итәчәкбез. Яшүсмерләргә тәгаенләнгән серия исә даими үз стилен эзләүчеләрнең күңеленә хуш килерлек гармонияле төсмерләр белән тулыланачак.

КУКМАРА ИТЕКЛӘРЕН БЕЗНЕҢ РЕСПУБЛИКАБЫЗДА ГЫНА ТҮГЕЛ, БӘЛКИ БАШКОРТСТАН, ЯКУТИЯ, БУРЯТИЯДӘ, УРАЛ ҺӘМ СЕБЕР ФЕДЕРАЛЬ ОКРУГЛАРЫНДА, ХАНТЫ-МАНСИ ҺӘМ ЯМАЛ-НЕНЕЦ АВТОНОМИЯЛЕ ОКРУГЛАРЫНДА, ЕРАК КӨНЧЫГЫШТА, ТӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ҺӘМ ҮЗӘК РОССИЯДӘ ДӘ ЯХШЫ БЕЛӘЛӘР ҺӘМ РӘХӘТЛӘНЕП КИЯЛӘР.

ҖӘЙДӘН ӘЗЕРЛӘҮ МӨҺИМ

Әйе, без сезонлы продукция җитештерәбез. Сәүдәнең төп өлеше сентябрь–октябрь айларына туры килә. Әмма күп кеше үзенә кышкы аяк киемен җәйдән үк әзерләп куя, мәсәлән, җылытылмый торган биналарда эшләүчеләр пима һәм кыска кунычлы итекләрне, аягы авырткан кешеләр чуни һәм өйдә кию өчен башмакларны ташламалар вакытында шактый арзан бәягә сатып ала.

РӘЕШКӘ ДӘ, ЭШКӘ ДӘ

Каталог ассортиментында спорт һәм классик киез аяк киемнәренең прогрессив яшь буынны һич битараф калдырмаячак кеда, кроссовка, лофер кебек стильле һәм актуаль модельләрен табарга була.

СЫЙФАТ – МЕНӘ ДИГӘН!

Кукмара итекләре бары тик сарык йонынннан гына басыла. Безнең аяк киемнәре сыйфатлы булсын һәм барлык таләпләргә, стандартларга җавап бирсен өчен, комбинат лабораториясе сатып алына торган йонны, ярымфабрикатлар һәм әзер продукциянең авырлыгын, үлчәмнәрен җентекләп тикшерә. Моннан тыш, кулланучылар үзләре дә сораштыруларда даими катнаша һәм үз фикерен белдерә.

САКЛАП ТОТ!

Киез җитештерүнең яңа технологиясе сүс структурасына көчле тәэсир итми, шунлыктан йонның тиңдәшсез дәвалау һәм җылы саклау үзлекләрен югалтмау мөмкинлеген бирә. Әмма аяк киеме кулланучыга озак еллар хезмәт итсен өчен гади кагыйдәләрне үтәү зарур:

- Киез итекне батарея, мич башында, җылыткычларда һәм ачык ут янында киптермәү сорала;
- Киез итекне артык дымландырмау. Әмма инде бик каты юешләнгән икән, эченә бөтен дымны сеңдерерлек итеп кәгазь тутырырга һәм йомшак тукыма белән яхшылап корытырга кирәк;
- Аяк киемен чистартуның иң гади ысулы – дымлы тукыма яки губка белән сөртеп алу. Бик каты пычранган очракта келәм чистарткыч матдәләрдән файдаланырга була;
- Җәен саклауга куяр алдыннан көя күбәләген китерми торган матдә сиптерергә, аннары чиста кәгазьгә төрергә яки чиста кәгазь пакетка салырга кирәк.

КИЕЗ ИТЕК КЕНӘ ТҮГЕЛ
Комбинатта шулай ук сарык йоныннан сырылган юрган, йокы капчыклары, мунча комплектлары, киез һәм йон жилетлар, милли түбәтәйләр дә җитештерелә.

КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

Күпләп сату бүлеге:
e-mail: opt@kvvk.org
Телефоны: (84364) 2-08-31, 8-800-250-11-32

Фирма кибете:
Адрес: Кукмара шәһәре, Вахитов ур., 1
Телефон: (84364) 2-08-78

АЛТЫН КУЛЛЫ ТЕГҮЧЕЛӘР ТӨБӘГЕ

Кешене эше данласа, һәр төбәк үзенә генә хас җитештерүләре белән дан казана. Татарстанның Кукмара районы исә борын-борыннан үзенең оста һөнәрчеләре белән данлыклы. Кукмара тегү фабрикасы – бүген бу төбәкнең иң танылган брендларыннан берсе.

Әле Казан ханлыгы чорында ук кукмаралылар терлекчелек һәм игенчелек белән генә түгел, һөнәрчелек белән дә яратып шөгыльләнгән. Биредә искиткеч оста тимерчеләр, чуен коючылар, мехчылар һәм тегүчеләр яшәгән.

Район халкының үз осталыгын гасырлар дәвамында саклап калуы сөендерә. Мисал өчен, Бөек Ватан сугышына кадәр биредәге «Кызыл тукучы» киез фабрикасында 3300 кеше хезмәт куя.

СЫНАУЛАР СЫНДЫРМАГАН

Район оешкан 1930 нчы елларда биредә «Ил» һәм «Ярыш» артельләре кебек җиңел сәнәгать предприятиеләре эшли башлый. 6 нчы Кукмара тегү фабрикасы ТАССР җиңел сәнәгать министрының 1956 елның 22 сентябре фәрманы белән «Ярыш» тегү артеле базасында оештырыла. Фабрикага аннан 106 кеше күчерелә.

Цехларга персонал туплау, җиһазлар табу, яңа ассортимент булдыру һәм аны үзләштерү, тегүне конвейерга салу – бу бик катлаулы еллар була. Ләкин үткән дәвердәге барлык сынаулар фабриканы чыныктыра гына. 1990 нчы еллар үзләре генә дә ни тора – бу чорда республикадагы тегү фабрикалары берсе артыннан берсе ябыла. Әмма Кукмара предприятиесе әлеге сынауны уңышлы үтә һәм үз мөмкинлекләрен арттыра гына бара.

Мәсәлән, 1996 елда республика прокуратурасы хезмәткәрләре өчен махсус кием җитештерелә башлый. Биредә тегелгән фирма плащлары, җылытылган куртка һәм ярымкомбинезоннар бик күп уңай бәя ала. Фабрикада корпоратив кием, шулай ук энергетиклар, газчылар, нефтьчеләр, төзүчеләр өчен сыйфаты иң кырыс шартларда сынала торган махсус кием тегелә.

Корпоратив һәм махсус киемнәрнең тиндәшсез дизайн-проектын булдыру, заказчының бөтен теләгән исәпкә алып тукыма һәм фурнитура сайлау, тегү, аннары исә төрле ысуллар белән логотип төшерү – болар барысы да Кукмара тегү фабрикасы хезмәтләре спектрына керә. Клиентларның гел уңай бәяләмәләре фабриканың абруе югары булуны дәлилли, аларның күпчелеге тегү предприятиесе белән күп еллар буе хезмәттәшлек итә.

Бүген киез итек басу-киез комбинаты, металл савыт-саба заводы белән беррәттән, Кукмара тегү фабрикасының да район икътисадына керткән өлеше иң саллылардан саналуы бер дә гаҗәп түгел.

ИҢ МӨҺИМ КЕШЕЛӘР ӨЧЕН

Предприятие ассортиментында сабыйлар өчен кышкы кием кебек катлаулы эшләнмәләр дә бар. Ул җылы да, шул ук вакытта балаларның хәрәкәтенә комачауламаслык уңайлы да булырга тиеш. Һәм, билгеле инде, ул модалы да булсын – бусын әниләр таләп итә. Биредә кече яштәге мәктәп балалары өчен дә, яшүсмерләр өчен дә киемнәр тегелә. Балалар киеме Graf Kids маркасы белән чыгарыла.

– Бездә балалар өчен елына ике тапкыр өр-яңа коллекция тудырыла – кышкы һәм язгы. Ә бу – яз һәм көз өчен 30 дан артык модель һәм кыш өчен дә шуның кадәр диярлек! Ассортимент 100 процентка диярлек яңартыла, – дип сөйли «Кукмара тегү фабрикасы» АҖ генераль директоры Руслан Рафаэлевич Голов. – Биредә иң мөһиме – маркетинг бүлеге тикшеренүләре, ул сатып алучыларны хәзерге вакытта нәрсә кызыксындыруын ачыкларга тиеш. Төсләр төсмерендәге трендларны да исәпкә алабыз.

Фотолар Кукмара тегү фабрикасыннан алынды. РЕКЛАМА

Кукмара тегү фабрикасы ассортиментында «Хыял» бренды астында өлкәннәр өчен бик күп кием тегелә: куртка, пальто, кыска пальто, тау чаңгысы костюмнары. Кукмара фабрикасының плащлык тукымадан тегелгән барлык киемнәре дә шулай ук ГОСТ буенча стандартлаштырылган һәм сертификатлаштырылган.

Заманча технологияләр уңышлы кулланыла. Мисал өчен, продукциягә каптыргыч-төймәләр югары төгәллектәге җиһазлар ярдәмендә куела. Һаваны һәм парны яхшы үткәрә торган мембраналы тукымалар киң файдаланыла. Фабрика белгечләре ГОСТ һәм башка норматив документлардагы таләп һәм кагыйдәләрне төгәл үти.

Фабрика продукциясе Россия күләмендә уздырылган ярминкәләрдә даими бүләкләнә һәм дипломнар ала. Эшләнмәләрнең бик югары сыйфатлы булуын тикшерү өчен исә Кукмарага барып йөрисе дә юк: моны предприятие сайтында һәм маркетплейсларда эшләү мөмкинлеге бар.

Соңрак конструкторлар эшкә керешә, аннары сынауларга чират җитә. Киемнең ничек килешле утыруы, молния һәм кесәләренең уңайлылыгы, киеп йөрергә җайлымы-юкмы булуы ачыклана. Бары җентекләп тикшергәннән һәм кимчелекләрне төзәткәннән соң гына модель күпләп тегелә башлый.

– Мәсәлән, катламнар саны һәм җылыткыч материалның тыгызлыгы үзгәрергә мөмкин. Сайлап алу мөмкинлеге зур: тыгызлыгы 60, 80, 100, 120, 140, 160 г/$м^2$ булган материалларыбыз бар, чөнки җылыткычны без үзебез уйлап таптык, аны безнең белгечләр ясый, – ди Руслан Рафаэлевич Голов. – Җиңел, сулый торган, чыдам материал хәтта дымлы мохиттә дә җылылыкны саклый һәм югары гигиена үзлекләренә ия.

БЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫНА

Кукмара тегү фабрикасы быелгы уку елында шәһәр һәм районнагы барлык беренче сыйныф укучыларына форма теккән: малайларга – чалбар һәм жилет, кызларга – сарафан. Ата-аналар әйтүенчә, форма уңайлы һәм бөгәрләнми торган булып чыккан. Урта сыйныфлар өчен дә комплект уйланылган инде, бу категориядәге кызларга итәк яки чалбар белән жилет тегеләчәк.

Хәзер исә район һәм шәһәр хакимияте башлыгы әкренләп барлык мәктәп балаларын да форма белән тәэмин итү бурычын куйган. Алты меңнән артык укучыга төрле үлчәмдәге кием бит бу! Бик җаваплы һәм катлаулы бурыч, әмма Кукмара тегүчеләре бернәрсәдән дә курыкмый һәм моны тормышка ашырырга әзер.

Кукмара ш., Эшче тыкрыгы, 1

+79061172836

+7 (84364) 2-67-49,
+7 (84364) 2-68-62

t.me/fabrika_kukmor_official

e-mail.kukmor.fabrika@mail.ru

fabrika_kukmor.ru

Предприятие күрсәткечләре

- Предприятиедә 100 дән артык кеше эшли, шулардан 14 е югары белемле, 14 е урта махсус белемле белгеч.
- Бу – Татарстанда өлкәннәр һәм балалар өчен өске кием, шулай ук спорт, корпоратив, махсус киемнәрне шундый зур ассортиментта җитештерә торган бердәнбер фабрика. 2023 елда предприятие белгечләре кышкы һәм язгы ассортимент өчен ике коллекция – 94 модель уйлап тапкан. Фабрикада шулай ук «Динамо», «Ракета» спорт командалары, «УНИКС» баскетбол клубы, Чаңгы узышлары федерациясе өчен киемнәр, ТР Спорт министрлыгы өчен комплектлар тегелгән.
- Корпоратив киемнәргә Татарстанның «Кукмара элеваторы», «Татпотребсоюз», «Гидрострой», «Восток», «Феникс», Faiza, AuraStroy, «Артлоджик» кебек компанияләре, «Буревестник» транспорт компаниясе заказ биргән. Фабрика белгечләре 2024 елда Россия Федерациясендә Гаилә елына багышланган халыкара «Россия» күргәзмә-форумында катнашучылар өчен кием теккән.

ЯШӘҮ КӨЧЕН ТОРГЫЗУ

2024 елның ноябрендә Баулы шәһәрендә урнашкан «Иволга» шифаханәсенә 55 ел тула. Иң яхшы шифаханәләргә хас матур дата, бай эш тәҗрибәсе. Ни өчен Татарстанда һәм Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче йөзәрләгән кеше ел саен дәвалану өчен «Иволга»ны сайлый соң?

«ИРКЕН СУЛЫЙМ»

Шифаханә-профилакторийның өч корпусы саф һавалы урман читендә урнашкан. Аның территориясеннән матур булып Баулы шәһәре күренеп тора, ә терренкур – кунакларның гына түгел, ә баулыларның да яраткан ял итү урыны.

«Татнефть» ГАҖнең «Татнефть-Забота» структур бүлекчәсе шифаханәсендә ял итүчеләр өчен урман сукмаклары буйлап поход-сәфәрләр оештырыла, калкулыкларга менеп, табигатьнең иситкеч матурлыгына сокланырга мөмкинлек бирелә.

Ял итү өчен бильярд, фитнес, дискотека, кинофильм һәм концертлар тәкъдим ителә. Баулы шәһәре һәм район буенча экскурсияләр дә үткәрелә. Әмма иң мөһиме – «Иволга» шифаханә-профилакториеның үз кунакларын дәвалау, аларның яшәү көчен торгызу өчен уникаль мөмкинлекләре бар. Дәвалау корпусларында заманча медицина җиһазлары урнаштырылган, алар төрле авыруларны дәваларга мөмкинлек бирә: сөяк-мускул, нерв системасы, сулыш органнары. Шифаханәдә шикәр диабеты белән авыручы йөкле хатын-кызлар, шулай ук инсульт һәм инфаркт, йөрәк һәм магистраль кан тамырларына операция кичерүчеләр тернәкләнү уза ала.

Монда сәламәтлекне яхшырту, авырудан соң савыгу һәм ял итү өчен барлык шартлар да тудырылган. Ә шулай ук «Иволга»да «Иркен сулыйм» программасы гамәлгә ашырыла.

САВЫГУ ИННОВАЦИЯЛӘРЕ

Баулы шифаханәсе үзенчәлекләренең берсе – инновацияле технологияләрне актив куллану, нәтиҗәдә тернәкләнү вакыты кыскара. Дәвалау өчен Кырымдагы Сак күленең кыйммәтле сульфидлы ләме, озон терапиясе, карбокситерапия, гипокситерапия («тау һавасы») кулланыла. Монда шулай ук гомуми криотерапия – экстремаль түбән температура тәэсиреннән дә файдаланырга була.

Арсеналда дәвалау ванналары (йод-бромлы, энҗеле, диңгез, ылыслы һ.б.) кебек традицион шифаханә хезмәтләре дә бар. Дәваланучыларга шулай ук дәвалау душы (Шарко, биеккә күтәрелә торган, циркуляр, яңгыр душлары), су асты массажы һәм дәвалау массажының төрле төрләре (кул белән классик, вакуумлы, өермәле, аппаратлы, массаж кәнәфиендә) билгеләнә.

Ләм белән дәвалау, лазер, магнит һәм яктылык терапиясе, электр тәэсирендә йоклату, электрофорез, гальванизацияләү һ.б. кулланыла.

Фитотерапия, аквааэробика, фитомичкәдә дәвалану, дәвалау физкультурасы кебек ысулларны яратучылар да биредә үзләре теләгәнне табачак. Һәм, ниһаять, шифаханәдә акватренажер, солярий һәм инфракызыл сауна да эшли.

Биредә бассейнда йөгерү юлы, кояш симуляторы, офтальмологик электростимулятор, йөрү имитаторы, нейромускул диагностикасы һәм тернәкләндерү системасы, оча төбендәге мускулларны электромагнит дулкыннары белән стимуллаштыру аппаратлары кебек яңа ысуллар да кулланыла.

«Иволга» заманча комплекс – каршы агым, гейзер, каскадлы душ, фин һәм төрек сауналары булган бассейнга ия. Намаз өчен бүлмә бар. Күптән түгел тукلануга да караш үзгәрде. Медицина оешмасы ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы «Хәләл» стандарты комитеты аудитын узды.

ТАЛӘПЧӘННӘР ӨЧЕН СЕРВИС

- Шифаханәдә рус, татар, башкорт, Кавказ халыклары һәм үзбәк кухнясы көннәре уздырыла;
- берничә көн алдарак аш-суга заказ бирү мөмкинлеге бар;
- туй, юбилейлар, ял көне турлары өчен меню каралган;
- корпоратив, банкет һ.б. бәйрәмнәргә, балалар күпләп килгән сменаларга хезмәт күрсәтәбез.

Фото: ivolga.tatneft.ru. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ВАКЫТ ҮЗ КАНУННАРЫ БУЕНЧА АККАНДА

Сәламәтлекне ныгыту, җанга сихәт алу өчен кая юл тотарга дисезме? Татарстанның Яшел Үзән районындагы «Васильевский» шифаханәсендә дәвалану – вакытны файдалы да, күңелле дә итеп үткәрү өчен менә дигән форсат. Бу турыда тулырак – «Татарстан» журналы битләрендә.

МИНЕРАЛЬ СУЛЫ ШИФАХАНӘ

«Васильевский» – күп профильле шифаханә, анда йөрәк-кан тамырлары, терәк-хәрәкәт һәм нерв системасы, шулай ук урология, гинекология, эндокринология һәм гастроэнтерология авыруларына дәва алып була. Шифаханә саф һавалы имән урманында урнашкан, биредә үзләренең минераль сулы ике скважиналары да бар.

Йод һәм бромлы куе суны сыеклап ванна өчен кыйммәтле чимал ясыйлар. Минераль, энҗе, ылыслы, радон, скипидар, каштан, метилсалицил, ялкынсынуга каршы, шулай ук пантлы (Алтай маралы мөгезләре экстракты белән) ванналар кабул итәргә мөмкин. Берничә төрле душ тәкъдим ителә, шул исәптән – су асты душы.

Кунаклар арасында «Гейзер» коры углекислоталы ванналар популяр. Процедураның төп максаты – кандагы кислород күләмен арттыру, аны яшәү өчен мөһим органнарга җиткерү, регенератив процессларны тизләтү. Процедура спортчыларны җәрәхәтләрдән һәм интенсив күнегүләрдән соң тиз арада тернәкләндерү өчен кулланыла. Шулай ук углекислоталы ванналар организмның картаюын акрынайта.

Эчәргә яраклы минераль су да чыгарыла. Ул сульфатлы-хлоридлы-натрийлы төргә карый, төрле авыр халәтләрдә кешенең кәефен яхшыртырга булыша.

КИЛӘЧӘККӘ КАРАШ

Гасырдан артык тарихка ия шифаханә заманча технологияләрне дә актив кулланышка кертә. Мәсәлән, ниндидер җәрәхәтләрдән һәм ялкынсыну процессларыннан соң, барлык орган һәм тукымаларның функцияләрен активлаштыра торган баротерапия ысулы кулланыла.

«Васильевский»да массажның төрле төрләре тәкъдим ителә: лимфодренаж, абдоминаль, роллинг һәм экспресс-массаж.

Сәламәтләндерү ысуллары исемлегенә шулай ук гирудотерапия һәм спелеотерапия – тозлы мәгарә микроклиматы йогынтысын куллану да кертелгән.

Күпләр өчен шифаханәгә килү, ниһаять, үзенә дә игътибар күрсәтү өчен яхшы бер мөмкинлек, чөнки монда табиб-косметолог эшли, косметология процедуралары үткәрелә.

Теләге булганнар бассейнлы сауналы арендалый ала, ә җәй көне җылытылган ачык бассейннан файдалану мөмкинлеге бар. Шифаханә территориясендә уңайлы кафе эшли. Һәм, әлбәттә, тренажер залында шөгыльләнергә, бильярд һәм өстәл теннисы уйнарга, концертка барырга, киноконцерт залында фильмнар карарга мөмкин.

ГАИЛӘ БЕЛӘН ЯЛ ИТҮ

«Васильевский»да гаилә белән ял итү һәм савыгу мөмкинлеге төп формат санала. Барысы да шәһәр ыгы-зыгысыннан читтә рәхәтләнеп ял итү өчен, гаиләнең һәр кешесенә сәламәтлеген ныгытырлык итеп, җентекләп уйлап эшләнелгән.

Кунакларны глэмпинглар аеруча кызыксындыра. Бу уңайлы йортларда яшәү өчен бөтен нәрсә бар, ә тәрәзәдән искиткеч матур күл күренеше ачыла.

«Васильевский» шифаханәсе – биредә вакыт үз кануннары буенча ага. Т

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



«БӘКЕР» ШИФАХАНӘСЕ – ТАБИГАТЬТӘ БУЛГАННЫҢ ИҢ ЯХШЫСЫ

Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышындагы иң матур урыннарның берсе – «Мәхәббәт» тавы итәгендә, Чишмә елгасы тугаенда һәм Озын күл үзәнендә, тиңсез хозурлыклы табигать кочагында «Бәкер» шифаханәсе урнашкан. Урманнар белән капланган таулар тәэсирендә һәм төрледән-төрле кечкенә елгалар, инеш-чишмәләрнең су белән даими тәэмин итеп тору нәтиҗәсендә дәвалау үзлекләренә ия уникаль климат формалашкан.

Табигать һәм климат шартлары, саф һава, тирә-яктагы искиткеч манзара югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтү һәм бик бай дәва төрләре белән берләшә. Бу факторлар барысы бергә шифаханәбезне һәркем теләп килә торган ял һәм гарантияләнгән, ышанычлы сәламәтләндерү урынына әйләндерде.

«Бәкер» шифаханәсендә 17000 нән артык кеше ел саен, сәламәтлеген ныгытып, аның уникальлегенә, уңайлылыгына һәм җанга якын аерым бер мохиткә ия булуына инана.

Татарстан горурлыгы булган «Бәкер» курортына 1933 елда нигез салына. Инде 90 елдан артык монда, ял итәргә һәм савыгырга дип, Россиянең барлык төбәкләреннән кунаклар килә. Шифаханә ел әйләнәсе тулы, «сезон арасы» дигән төшенчә аның өчен ят, юлламаларны 1,5-2 ай алдан броньларга кирәк. Хәзер гражданнар сәламәтлеккә аеруча игътибар бирә – барысы да яшь, энергияле, һәрвакыт сафта булырга тели.

Шифаханәнең тиңсезлеге Бәкер җиренең бөтен илгә билгеле табигый үзенчәлекләре – сапропель ләмләр һәм сероводородлы минераль суларында гына түгел. Асылда «Бәкер» шифаханәсе сәламәтлек саклау – медицина тернәкләндерүе өлкәсендәге иң алдынгы ысул-алымнарны, заманча ял итү чараларын, «Бакировская» минераль суын җитештерүне, үз умарталыгын, югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне колачлаган, диагностика һәм дәвалау өчен бай база тупланган хәзинәгә тиң.

Ял итү дигәндә, дөрес дәвалау гына күздә тотылмый, биредә буш вакыт та күңелле һәм файдалы итеп оештырыла: шифаханәдә мини-зоопарк, шугалак, апитерапия йорты, бильярд залы һәм ачык кафе бар. «Бәкер» балага уза алмауны уңышлы дәвалавы белән дә дан казанды. Белгечләр тарафыннан дөрес сайланган урологик һәм гинекологик программалар бик күп гаиләләргә бәхетле ата-ана булырга булышты. Ял итүчеләр тарафыннан шифаханә-курорт системасын оештыруга таләпләр даими үсә барган җитди көндәшлек чорында эшлибез. Төбәктә генә түгел, ә бөтен ил күләмендә үз тармагыбызда иң алдынгыларның берсе булып калу өчен, безгә гел үсәргә кирәк. Шуңа күрә «Бәкер»дә кунакларның ялын тагын да югарырак дәрәҗәгә күтәрү мөмкинлеге биргән күп кенә проектлар тормышка ашырылды.

Бирегә килүчеләрнең ихтыяҗлары һәм теләкләре төрле, алар еш кына бер-берсеннән шактый нык аерыла. Әле күптән түгел генә без клиентларыбызның теләкләрен тулысынча канәгатьләндерә алмый идек, бигрәк тә номерлар фонды мәсьәләсендә. Хәзер минимализм яратучыларны да, иң таләпчән һәм зәвыклы клиентларыбызны да сөендерү мөмкинлегебез бар. Бүген кунакларыбызга яңартылган «Аккош» корпусын тәкъдим итәбез, анда тулы канлы ял һәм савыгу-сәламәтләнү өчен Европа стандартларына туры килгән, затлы-зәвыклы клиентларның иң югары таләпләрен канәгатьләндерерлек яхшы шартлар тудырылган. Швед өстәле принцибында хезмәт күрсәтә торган ашханә залы яңартылды, яңа спа-комплексны исә быел көз көне ачу планлаштырыла.

Үзең яшәгән географик киңлекләрдә ял итү күпкә файдалырак, үз төбәгеңдә дә сыйфатлы ял итеп була! «Бәкер»гә барыр вакыт!

Фотография «Бәкер» шифаханәсе идарәсе тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

акыллы
гамәлләр
игелекле
мәңгелек
кыйммәтләр
эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Кеше приюты»на **кемнәр** ярдәм кулы суза

Тинчурин театры юбилейга **ничек** җыена

Язмыш бормалары **кайларга** илтә

Вазыйх Ногманов сугышта **ниләр** күргән

«КЕШЕ ПРИЮТЫ» – ЯЗМЫШЛАРМЫ, ЯЛГЫШЛАРМЫ?

Руфия Фазылова

Казанның «Колхоз базары» тукталышы. Һәркем каядыр ашыга, һәркемнең үз мәшәкате. Шушы кешеләр ташкынында бер ир-ат күзгә ташланды. Ул бер җиргә дә ашыкмый, гамьсез генә алга атлый. Бермәл тукталыш артына кереп югалды. Аңлашылды, Борһан Шаһиди урамында урнашкан «Кеше приюты»на килүе. Шушы ир-атны күздән югалтмаска дип, без дә адымнарны тизләттек...

Әнә ул вагоннар тирәсендә тәмәкесен көйрәтеп басып тора. Карашы уйчан. Гомер уртасына җиткән ир-атны монда килергә нәрсә мәҗбүр итте икән? Якынрак барып сүз каттык...

Фото: Александр Ефремов

«ҮЗЕМ ГАЕПЛЕ...»

Борһан Шаһиди урамындагы бу үзәк кайчандыр мохтаҗларга бушлай ризык таратыр өчен оештырыла. Бүген тулы бер комплекска әйләнгән. Биредә бер дигән яшәү шартлары: аерым мунча, кер юу бүлмәсе, спорт залына кадәр бар. Ә үзәкнең әйләнә-тирәсе шау чәчәктә утыра...

Приют илле урынга исәпләнгән, әлегә монда утыздан артык кеше яши икән. Аерым вагоннар тибында эшләнгән бу тораклар хостелны хәтерләтә. Дүрт кешегә дүрт карават, тумбалар, көзгегә кадәр бар. Узган елның сентябрендә капиталь төзекләндерү уздырылган, монда барысы да яңа, чиста.

Сүз башым бит Шүрәле: тәмәкесен авызыннан алып, теге ир сорауга җавап бирде:

– Альберт булам. Ике ай яшим монда. Безнең кебек җүнсез адәмнәрне шулай кеше итеп тоталар, рәхмәт.

– Җүнсез? Сез үзегез турында шулай әйтәсезме?

– Үзем турында да. Илле яшеңә җитеп, баш өстеңдә түбәң булмасын инде!

– Гаиләгез юкмы?

– Бар иде, хәтта ике тапкыр өйләндем.

– Алайса?

– Минем кебек ир белән хатын торамы инде? Менә сез яшәр идегезме?

–?..

– Һәм дөрес эшлисез. Без бит имгәкләр... Барысына да үзем гаепле. Ике тапкыр төрмәдә булдым, беренчесендә – әйбер урлаган, икенчесендә сугышкан өчен утырдым.

– Казанда тудыгызмы?

– Юк, Ульяновск шәһәреннән мин. Икенче хатын белән Казанда яшәдек. Балабыз да бар. Әгәр аякка бассам, улым янына барачакмын. Тик башта кешегә әйләнергә кирәк.

Альберт тәмәкесен тартып бетергәч, вагонга, үзенең бүлмәсенә ашыкты. Фотога төшерергә рөхсәт бирмәде.

– Ике айдан килегез, пока кешегә күренәсем килми. Кодировка ясадылар, хәзер эчмим. Матурлангач фотога төшерерсез. Әле берәр хатын да табып бирмәссезме...

«КЕШЕ ПРИЮТЫ» 2018 ЕЛДАН БИРЛЕ ЭШЛИ.

Приют эшчәнлеге:

- халыкның социаль якланмаган катламнарына кайнар ризык өләшәләр, вакытлыча торак, кием-салым белән тәэмин итәләр. Шулай ук социаль мунча, кер юу бүлмәсе хезмәтләре күрсәтәләр;
- социаль чәчтарашханә, юридик һәм психологик консультация, социаль патруль хезмәтләре;
- эшкә урнашырга ярдәм итәләр;
- документлар, медицина тикшерүләре узу, инвалидлык алу, льготалар һәм пенсияләр рәсмиләштерүдә булышалар;
- мохтаҗ, мобиль булмаган кешеләргә, инвалидларга медицина учреждениеләренә баруда ярдәм кулы сузалар.

Приютның әйләнә-тирәсе шау чәчәктә утыра. Бакчаны биредә яшәүчеләр үзләре карый.

«СЕЗНЕҢ НИ ЭШЕГЕЗ БАР?»

Приютта көн саен ике йөз илле кешене ашаталар. Юк, юк, алар барысы да йорт-җирсез кешеләр түгел. Пенсионерлар, күп балалы әниләр – кем генә килми.

Биредә без әбәт вакытына туры килдек: һәр көнне 11:00 дән 13:00 гә кадәр кайнар ризык тараталар. Приют ашханәсендә өстәлләр, эскәмияләр тезелеп киткән. Теләгән кеше шунда утырып ашый, кемнәрдер ризыкны үзләре белән ала. (Махсус савыт алып киләләр.)

Ашханәгә ыспай гына киенгән илле яшьләрендәге бер хатын-кыз керде. Урамда очратсаң, һич кенә дә аны мондый җирдә ашый димәссең! Затлы сумкасыннан ике савыт чыгарды: «Күршемә дә ризык алам», – диде ул. Фотоаппаратны күрүгә тавыш чыгарды:

– Минем рөхсәттән башка сез мине фотога төшерә алмыйсыз!

– Сез дә мохтаҗ кешеме? Монда килергә сезне нәрсә мәҗбүр итте? – дим, исем китмичә.

– Ә сезнең анда ни эшегез бар? Сездән рөхсәт сорарга кирәкмидер бит?

Һәм тиз генә ризыгын сумкасына салып ашханәдән чыгып китте.

Телсез калдык. Бер мескен әби булса, аңлар идең, ә монда? Җир җимертеп эшләрдәй, бизәнгән-ясанган ханым! Безнең аптыраулы карашны күреп, «Кеше приюты»ның администраторы Эльмира Тимонина болай диде:

– Әйе, шундый ыспай киенгән, үзләрен эре тотучы ханымнар да килә. Дөрес аңлагыз, без ярдәм сорап килгән бер кешене дә кире бормыйбыз. Бердәнбер таләп: кеше аек булырга тиеш. Әгәр салган икән, йөреп килегез, азрак айнырсыз, дип җибәрәбез. Монда һәр кешенең үз сәбәбе. Шуның өчен кемнедер гаепләү безнең эш түгел. Менә әйтегез әле, сез бирегә ризык алырга килер идегезме?

– Юк, әлбәттә.

– Шул шул. Кул сузып бару берәүгә дә рәхәт түгел. Ул ханымның да язмышын белмибез. Алай йөрергә беребезгә дә язмасын...

ҖОМГА САЕН ЧӘЧӘК БӘЙЛӘМЕ?!

Ашханә ишекләре көне буе ачык. Читтән килүчеләр әбәт ашаса, приютта яшәүчеләр

Әлфия исемле күршем яшәргә дә чакырды, тик аның төрмәдән кайткан улы бар иде, курыктым...

Приют хезмәткәрләре Нина түтине 2021 елның гыйнвар аенда үзе яшәгән йортның подъездыннан барып ала. Көчкә атлаучы әбекәйне юындыралар, киендерәләр, бүген исә ул хәтта эшләп тә йөри. Аңлашыла ки, якыннары белән элемтәсе юк. Оныкларын сагына икән... Нина түти тораксыз калуда кызын түгел, киявен гаепли. Ана гына баласын шулай сукыр мәхәббәт белән ярата аладыр:

– Рәхәтләнеп үзләренчә яшәсеннәр. Минем торыр җирем бар, тамагым тук, пенсиям килә, – диде ул бер риясызлык белән.

«АЧТАН ҮЛҮЧЕЛӘР БАР»

Аңлашыла ки, монда килеп эләккән һәр кешенең язмышы аянычлы. Күбесе (җитмеш процентка якыны) кайчандыр иректән мәхрүм ителгән булган. Төрмәдән чыккач, аларны якыннары кабул итмәгән. Араларында гаиләле кешеләр дә шактый. Кемдер сукбайлыкта ярты ел, кемдер өч ел йөргән... Барысы да диярлек эчәргә ярата, наркоманнар да очрый. Һәм бәхетле очрак аларны бирегә алып килгән. Бәхетле дип басым ясап әйтәм, приютта чынлап та адәм баласы тормышын яңадан башлый ала. Әлбәттә, теләге булса.

монда өч тапкыр туклана икән. Иртәнге биштә үк ашханәгә керүчеләр бар, эшкә китәр алдыннан тамак ялгап алалар.

Приютка атна саен блогерлар, хәйриячеләр, җитәкчеләр килә, шуның өчен биредә яшәүчеләр аралашуга ачык. Аеруча хатын-кызлар сөйләшергә ярата. Гүзәл затлар өчен биредә ике вагон-йорт бар. Аларда өчәр хатын-кыз яши. Һәркайсының үз шкафы, анда ислемай, башка бизәнү кирәк-яраклары тора. Һәм чәчәкләр. Баксаң, монда яшәүче гүзәл затларга хәйриячеләр җомга саен чәчәк бәйләмнәре алып килә икән!

– Балалардан да мондый мөнәсәбәт күргәнем юк иде, – дип күз яшьләрен сөртте Нина Алексеевна. – Приютта ике ел яшим инде. Монда мине әниләре кебек якын күрәләр. Барыр җирем юк, шуның өчен чыгарып та җибәрмиләр. Үлгәнче яшәрмен инде. Юк, сез мине һич кенә дә кызганмагыз, монда бик рәхәт. Әйтәм бит, мондый җылы мөнәсәбәтне беркайчан күргәнем булмады. Берәү дә кычкырмый, сүгенми, сукмый...

Аллаһ сакласын... Нина түтәй сөйләгәндә, әллә ничә тапкыр шулай дип куйдым. Биектау районының Усад авылында туып-үскән ул. Соңрак Казан егетенә кияүгә чыгып, гаилә тормышы башлаганнар. Бер кызлары туган. Җәмәгате, каенанасы, кызы – ике бүлмәле фатирда шулай матур гына яшәгәннәр. Нина Алексеевна башта каенанасын, аннан соң җәмәгатен соңгы юлга озаткан. Ә көннәрнең берендә үзе артык кашыкка әйләнгән:

– Барысына да кияү гаепле, – дип дәвам итте ул. – Кызымны ул гына котыртты. Ике бүлмәле фатирны сатып, Биектаудан йорт алдык. Шул ике катлы йортта миңа урын табылмады. Кияү берничә тапкыр кыйнады, нинди генә сүзләр ишетмәдем. Инде үзем яшәгән подъездда үләрмен дип уйлаган идем. Күршеләр ташламады, ашаттылар.

↑ –Приютта ике ел яшим, – ди Нина Алексеевна.

Биредә бер дигән яшәү шартлары: аерым мунча, кер юу бүлмәсе, намаз бүлмәсе, спортзалга кадәр бар. ↓



– Дөрес аңлагыз, без әрәмтамаклар үрчетмибез, ә кешегә яңадан тормышка кайтырга булышабыз, – диде «Кеше приюты» җитәкчесе Александр Суханов.

– ТР наркология диспансеры белән килешү бар: ай саен ун кешене дәваларга җибәрә алабыз, – диде «Кеше приюты» җитәкчесе Александр Суханов. – Бушка кодировка турында сүз бара. Юристлар, психологлар, дин белгечләре – барысы да, приютка килеп, биредә яшәүчеләр белән эшли. Тәртип шулай: башта урамнан килгән кеше барлык медицина тикшеренүләрен уза, юына, өс-башын карыйбыз. Һәм өч ай эчендә кеше эшкә урнашырга, кешечә яши башларга тиеш.

– Өч айдан соң приюттан чыгып китәләрме? – дим.

– Әгәр туры юлга басмаса, әйе. Инде эшкә урнашса, эчүен ташласа, аннан соң да ярдәм итәбез. Авиатөзелеш районында тулай тороктан берничә бүлмә арендалап торабыз. Моннан киткәч, алар шунда яши. Алай гына да түгел, Авиатөзелеш районында шундый кешеләр өчен аерым торак булачак. Шәһәр мэриясе җир бүлеп бирде, төзелеш эшләре инде башланды. Дөрес аңлагыз, без әрәмтамаклар үрчетмибез, ә кешегә яңадан тормышка кайтырга булышабыз. Документларын тәртипкә китерәбез, эш урыны тәкъдим итәбез. Аңлашыла, әллә нинди зур хезмәт хаклары турында сүз бармый: урам себерүче, төзелештә ярдәмче һ.б. Приютта дисциплина: кеше йоклаган урынын җыештырырга, өс-башын чиста йөртергә, хәмер кулланмаска тиеш, хәтта кайчакта алкотестер белән дә тикшерәбез. Шулай ук наркотик матдәләрне тикшерү өчен тест та бар. Бер карасаң гаҗәп тә: ләкин олы кеше булсалар да, аларның күбесен яшәргә өйрәтергә туры килә: иртән теш чистартудан башлап кичен юынып ятуга кадәр. Алар башта карыша, аннан ияләнә инде. Җиде ел эчендә приют йөзләп кешегә аякка басарга ярдәм итте. Әллә нинди гыйбрәтле хәлләр бар монда. Кайчандыр биредә яшәгән ир-ат бүген эшмәкәр, кибетләре бар. Икенчесе Яңа Сокуры бистәсендә йорт салды, өйләнде. Менә дигән итеп яшәп яталар. Өченчесе үз гаиләсе янына кайтты, матур гына эшләп йөри.

– Андый бәхетле очраклар күпме? Сукбайлыкка чыгучыларның күпмесе яңадан кешечә яши башлый?

– Яшермим, приют аша узган кешеләрнең утыз процент чамасы гына кешечә яши башлый. Ә калганнары шул юлын дәвам итә. Ләкин йөздән бер генә кеше булса да,

без ярдәм кулы сузарга тиеш. Монда эшли башлагач кына аңладым: Татарстанда ачтан үлүчеләр дә бар икән! Без хәзер республика районнарында да кайнар ризык таратуны оештырдык. Егермедән артык районда шундый нокталар бар. Мисал өчен, Биектау районындагы бүлеккә көн саен алтмыш кеше кайнар ризык алырга килә. Апас, Буа кебек районнарда да филиаллар эшли. Нигездә мохтаҗларга, урын өстендә булган кешеләргә кайнар ризыкны өйләренә илтәләр. Безнең максат – Татарстанның һәр шәһәр, районында шундый нокталар ачу.

ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘ ДӘ СУГА САЛ...

«Кеше приюты» дәүләт оешмасы түгел, ул фәкать хәйриячеләр акчасына яши. Иң гаҗәбе – бу кешеләр күп очракта үзләренең исемнәрен күрсәтергә теләми. Хәйриячеләрнең туксан проценты мөселман, диделәр безгә. Ислам кануннары буенча сәдаканы кычкырып бирмиләр. Ә бит сүз бик зур суммалар турында бара. Бер эшмәкәр ай саен егерме мең сум күчереп барса, икенче бер хәләл ресторан хуҗасы көн саен илле кеше ашатуны үз өстенә алган. Барысын да санасаң, саллы гына исемлек җыела. Мисал өчен, Борһан Шаһиди урамындагы приютны яшәтү өчен ай саен 600 мең сум акча кирәк икән. Моңа барлык коммуналь түләүләр, җир арендасы, көн саен 250 кешегә азык тарату һәм башка чыгымнар кергән. Һәм бу сумманы тулысынча Казандагы танылган бер компания күчерә!

– Без бик күп, – дип сүзен дәвам итте приют җитәкчесе Александр Александрович. – Кемдер акчалата булыша, кемдер волонтер сыйфатында ярдәм итә. Һәм барыбыз да изгелек эшлибез – мохтаҗларга, авыр хәлдә калганнарга ярдәм итәбез. Бирегә еш кына хәлле кешеләр гаиләләре белән килә. Шул рәвешле гаилә башлыгы хатынына, балаларына тормышның икенче ягын да күрсәтә, шөкер итәргә өйрәтә. Без барыбыз да кешеләр, изгелек эшләгән саен күңел чистара. Озак еллар эчке эшләр бүлегендә хезмәт иткән кеше буларак моны тәгаен әйтә алам.

...Приютта һәр кешенең үз язмышы. Ләкин аларны бер нәрсә берләштерә – ялгызлык һәм упкын төбеннән күтәрелергә омтылу... Кемгәдер, чынлап та, бәхет елмая – аякка баса, ә кемдер исә шунда – упкын төбендә кала. Ничек кенә булмасын, приютта һәркайсына тормышны яңадан башларга мөмкинлек бирәләр. Ә шушы изге эшкә өлеше кергән һәр кешегә ЗУР РӘХМӘТ әйтәсе килә. Дөньяны нәкъ менә шундый кешеләр коткара – монысында шик юк.

Фотолар Александр Ефремовтан, театрның матбугат хезмәтеннән алынды

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫ: ТЫНЫЧЛЫКМЫ?

Руфия Фазылова

Туфан Имаметдиновның Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрына баш режиссер булып килгәненә өч ел тула. Сер түгел: ул вакытта театрда шактый ыгы-зыгы булып алды. Бүген вазгыять ничек соң? Яңа режиссер труппа белән уртак тел тапканмы? Театр 90 еллык юбилеена ничек әзерләнә? «Татарстан» журналының шушы һәм башка сорауларына Туфан Риф улы бик теләп җавап бирде.

– Туфан Рифович, баш режиссер сыйфатында коллективка кереп китү авыр булдымы?

– Яңа коллективка кереп китү һәрвакыт катлаулы. Театрда бигрәк тә, 90 ел дәвамында формалашкан тере организм бит ул. Аның үз традицияләре, үзенчәлекләре бар. Коллективка яңа килгән кешенең бурычы – шуны аңлау һәм санлау. Театрны организм дидек бит, шулай булгач, аның үз «авырулары» була. Минә без шул проблемаларны хәл итү өчен эшләргә тиеш.

Кемдер мине кабул итә, кемдер юк, моның өчен борчылмыйм. Ул шулай булырга тиеш. Тик берәүгә дә каршы төшкәнем юк. «Мине кабул итмәсәң, сине эштән җибәрәм», – кебек сүзләр диктатура була. Андый чакта кеше курка башлый. Ә әгәр артистта андый хис-тойгы бар икән, ул йомыла, аны башка ачып булмый. Һәм моннан беренче чиратта театр зыян күрә.

Берәүне дә битараф калдырмаган «Флешка, рэп һәм мәхәббәт» спектакле.

Шөкер, театрда тынычлык, яңа идеяләр, яңа планнар белән яшәп ятыш...

– Сез 2010 елда Алабуга мәдәният һәм сәнгать училищесының режиссерлык факультетын тәмамлагансыз. Аннан соң ГИТИСның режиссерлык факультетында белем алгансыз. Беренче уку йорты сезгә нәрсә бирде? Ә икенчесе? Аларны чагыштырып карарга мөмкинме?

– Әле шушы ике уку йорты арасында тагын берсе бар – тугыз ай Мәскәү дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында белем алдым. Ни өчен алай килеп чыкты дигәндә, ГИТИСта режиссерлык факультеты барлыгын белмәгәнмен. Алабугада чакта анда актерлар гына әзерлиләр дип уйлый идем. Ул чорда бит хәзерге кебек интернет заманы түгел, мәгълүмат аз. Мәскәүнең мәдәният һәм сәнгать институтын бер елдан ташлап, ГИТИСның режиссерлык факультетына кердем. Яңадан беренче курстан укый башладым.

Инде әлеге уку йортларын чагыштырганда, Алабугада остазым Зилә Садриева күп нәрсә бирде, дип әйтә алам. Пьесаны анализларга ул өйрәтте, төп нигезне аңардан алдым. ГИТИСта музыкальлек, композиция, образлар, метафоралар белән эшләргә өйрәттеләр. Шулай ук хореография белән эш үзенчәлекләренә дә шунда төшендем. Кыскасы, һәркайсы багаж тупларга ярдәм итте. Әлбәттә, теорияне Алабуга мәдәният һәм сәнгать училищесы бирде. Һәр уку йортына мин бик рәхмәтле. Остазларымнан уңдым, дип саныйм.

– Сез Тинчурин театрына кадәр рус ТЮЗында эшләдегез. Актерлык бүлекләрендә дә русча укыгансыз. Чын татар мохитенә килеп кергәч, нинди каршылыклар очраттыгыз?

– Әйе, Тинчурин театры – ул чын татар дөньясы, аның аудиториясе дә милли. Рус ТЮЗы белән чагыштырганда, башка аермалыклар да җитәрлек. Әмма, минемчә, нинди эшкә алынсаң да, башта һәрвакыт иллюзия була. Ә туксан тугыз процент очракта ул акланмый, чөнки тормышның үз кагыйдәләре бар:

яки син аны җимерәсең һәм яңаны булдырасың, яки инде берни дә үзгәртмисең – шундый ук пьесаларны куюны дәвам итәсең.

Тинчурин театрында эшли башлагач, шуңа инандым: рус яки чит ил драматургиясе татар театрына ябышмый. Музыка белән дә шул ук хәл: Бах, Гендель көйләрен куйсаң, халык кабул итми. Хәтта ул музыка артистлар арасында да зур сораулар уята. Ләкин, минемчә, без үзебезне дөнья культурасыннан чиклибез, әйтерсең лә без ниндидер кабырчык эчендә һәм аннан чыгасыбыз килми. Шул рәвешле бөтен дөнья сәнгатенә юлны ябабыз.

– Туфан Рифович, татарга музыкаль театр кирәк дип күптән сөйләшәбез. Тинчурин театрын да шул юнәлештә эшләтергә дигән фикерләр булды. Ә сез бу турыда ни уйлыйсыз?

– Минемчә, Тинчурин театры татар музыкаль театрына база була алмый. Әйе, безнең үзебезнең оркестр бар. Тик музыкаль театр өчен мөһим булган башка бернәрсә дә юк. Аның өчен бит профессиональ җырлый һәм бии торган артистлар таләп ителә. Әгәр бу билгеләр буенча карасак, бүген труппадагы ике-өч кешене калдырырга да калганнарын эштән җибәрергә кирәк. Димәк, бүген бездән берничек тә музыкаль театр ясау мөмкин түгел. Монысы бер. Икенчесе: татарларга музыкаль театр кирәк. Безнең классик драматургиянең нигезе җыр һәм биюгә корылган. Шулай булгач, бу татарга якын әйбер. Әйе, безнең опера һәм балет театры бар. Ләкин ул бөтенләй башка жанр. Опера дөнья культурасына йөз тота, безгә исә милли музыка театры кирәк. Бәлки киләчәктә булыр да. Камал театрына яңа бина төзелеп ята бит, аларның хәзерге бинасында музыкаль театр ясарга бөтен мөмкинлекләр дә бар. Яшермим, андый сүзләр йөри. Вакыт күрсәтер.

Безнең әзер татар опералары бар, аларны аерым чараларда күрдек. Югары дәрәҗәдәге әсәрләр. Аларны әзерләү өчен зур акчалар түгелде, күпме профессионал эшләде. Менә шул хезмәтләрне киң халык массасына чыгарсак яхшы булыр, дип уйлыйм. Безнең бу өлкәдә тәҗрибә бар, ныклап торып тотынырга кирәк, минемчә.

– Татар театрына бүген нәрсә җитми дип уйлыйсыз? Сезнеңчә, аның кыйбласы кая таба булырга тиеш?

– Дөньяга ачык булу җитми. Әгәр пьеса кешелек кыйммәтләренә, яхшылык, матурлыкны күрсәтүгә нигезләнгән икән, башка әдәбиятны, шул ук рус классиклары әсәрләрен дә куярга мөмкин, дип саныйм.

– Күптән түгел «Флешка, рэп һәм мәхәббәт» хип-хоперасының премьерасы булды. Миңа калса, ул берәүне дә битараф калдырмады: һичшиксез, Тинчурин театры өчен яңалык бу. Тамашачы буларак бер фикер белән бүлешәсе килә: спектакль ошады миңа. Ләкин бер генә уңай хатын-кыз роле дә юк иде. Тагын шулай дип әйтүчеләр булмадымы?

– Булды, төрле фикерләр ишеттек. Премьерадан соң кайбер җиргә үзгәртүләр дә керттек. Ләкин монда шуны аңларга кирәк: бу комедия. Спектакльдә персонаж явыз икән, димәк, шулай уйнарга тиеш. Мәсәлән, хатын-кызның фамилиясе «Җилбәзәкова» икән, ул аны баш-

кача уйный алмый. Әгәр инде жанрдан читкә китеп, ниндидер тирәнлек эзли башласак, алар инде үз фамилияләрен акламаячак. Бу инде драма жанрына әйләнәчәк. Спектакль махсус яшьләргә, студентларга атап куелды. Аларга акыл сатып утыра башласак, тамашачы алдында кыланабыз булып чыга. Яшьләр өчен ак яки кара төс кенә бар. Башланганда да җырда әйтелә: «Монда кара һәм ак кына,
Бүтән төсләр эзләмәгез...»

Хореография буенча бик күп эшләнелде. Марат Казыйханов артистлар белән махсус тренинг та үткәрде. Аны Татарстанда хип-хоп буенча төп белгеч дип әйтеп була. Бу юнәлеш нәкъ яшьләр өчен, аны инде утызда биеп булмый. «Флешка, рэп һәм мәхәббәт» ул гадәти спектакль генә түгел, монда сүз белән бергә хәрәкәтләр бара. Ул энергия, хәрәкәт, эмоцияләр...

– Бу сезон театрның 90 нчы юбилей сезоны иде. Шул уңайдан нәрсәләр эшләнде һәм эшләнәчәк?

– Нинди генә түгәрәк дата булмасын, ул – нәтиҗәләр ясау вакыты дигән сүз. Шул вакыт эчендә көчле һәм көчсез якларны ачыклыйсың. Ә 90 еллык юбилей бигрәк тә мөһим. Без хәзер үткәнгә нәтиҗә ясап, киләчәкне күзаллап, үзебезгә сораулар бирәбез. Әмма рефлексия итеп түгел, ә спектакль форматында сорыйбыз. Тамашачының реакциясе шул сорауларга төп җавап булып тора. Чагыштырып карасак, хәзерге Тинчурин театры 20 ел элек булган театрдан аерыла.

Инде конкрет эшләргә килсәк, «Ай, былбылым» спектаклен чыгардык. Ул өлкән буын турында. Шул рәвешле күп еллардан бирле Тинчурин театрының йөзен саклау, аны яшәтү өчен бик зур көч куйган тәҗрибәле артистларыбызга рәхмәт әйтү дә булды ул. Юбилей сезонында чыккан тагын бер спектаклебез – «Җан Баевич». Ул ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә эшләнде. Тагын берсе – «Флешка, рэп һәм мәхәббәт», аның турында сөйләштек инде. Әле тагын ике премьера булачак дип планлаштырабыз. Һәм юбилей елын бер үзенчәлекле спектакль белән тәгәллисебез килә. Ул Кәрим һәм Заһидә Тинчуриннарның гомерен чагылдырачак, ягъни реаль вакыйгаларга нигезләнгән булачак. Пьеса язылып бетеп ята.

– Тинчурин театрының тарихы бик үзенчәлекле. Күчмә театрдан калган нинди дә булса традицияләр сакланамы?

– Күчмә театр икәнлегебез әле һаман да күп кенә артистларның башында утыра. Нәрсә дигән сүз бу? Янәсе, син алып килгән спектакль тамашачыга ошамаса, сине анда башка чакырмаячаклар. Халыкка комедия кирәк дип кенә уйлау да дөрес түгел. Тамашачы нәрсә әйтер дип куркып, аңа яраклашырга тырышып кына иҗат итәргә ярамый. Тамашачыны комфорт зонасыннан да чыгарырга кирәк, шунда гына хакыйкать туа.

– Хатын-кызның фамилиясе «Җилбәзәкова» икән, ул аны башкача уйный алмый, – ди баш режиссер.

– Туфан Рифович, укучыларыбызга шәхси тормышыгыз да кызыклы булыр дип уйлыйм. Гаиләгез, тормыш фәлсәфәсе, яшәү рәвешегез...

– Сорауга җавап биргәнче, бер фикер әйтәсем килә: минә «Татарстан» журналының февраль санын карап чыктым. Шунда ук тышлыктагы Мөхәррәм абый Мөхәммәтҗанов игътибарны җәлеп итте: кар көри торган техникага чана таккан, аның өстенә урындык куйган. Шул рәвешле үзенчәлекле машина ясаган. Өстәвенә, тау шуганда кия торган күзлеге дә бар. Менә бу безнең Татарстан, юктан кәнфит ясый беләбез. Йорт-җирне төзекләндерү, башкасын да без булдырабыз. Дингә дә йөз белән борылдык. Тик менә мәдәният өлкәсендә үсәргә теләмибез. Безнең барысы да тәти, матур булырга тиеш, кыз тәрәзә төбенә утырып сөйгәнен көтә... Ләкин чынбарлыкта алай түгел бит. Тормышта төрле хәлләр була, без аның барысын да күрсәтергә тиеш дип уйлыйм.

Гаиләмә килгәндә, җәмәгатем белән өч бала үстерәбез. Балаларның берсе мәктәптә, берсе балалар бакчасына йөри, өченчесе әле кечкенә, өйдә генә.

Гаиләмә бик зур игътибар бирәм. Һәр балам белән аерым уйнарга тырышам.

Ислам дине кануннары буенча яшибез. Ашауга килгәндә, төрле чак була. Ач торып та караганым бар. Кыскасы, тормышка үз фәлсәфәм булган кебек, туклануга да җитди карыйм.

Фотолар проектта катнашучыларның шәхси архивыннан, Лилиана Вәлитовадан

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар юллар сала, күперләр төзи. Балаларны, аларның укытучыларын өйрәтә. Арабызда алтын куллы иске әйберләрне яңартучы, сирәк һөнәргә ия фидакарь затлар яши. Бөек Ватан сугышы кырларында илне дошманнардан азат иткән ветераннарыбыз да әле сафта.

«Татарстан» үз укучыларын шундый якташларыбыз, аларның могҗизага тиң эшчәнлекләре белән таныштыруны дәвам итә.



19 НЧЫ ТАРИХ
Нәзирә Бикмөхәммәтова ил иминлеген кайда саклаган

20 НЧЕ ТАРИХ
Вазыйх Ногманов ничек ил азатлыгы өчен көрәшкән

Элекке тарихларны «Татарстан» журналында укыгыз: 2022 елның 10-12 нче саннары, 2023 елның 1-2, 6 нчы саннары, 2024 елның 1,4 нче саннары.

19 нчы тарих

ЯЗМЫШ БОРМАЛАРЫ: ИДЕЛДӘН ЕНИСЕЙГА КАДӘР

Әскәр Сабиров

Енисей яры, Атаман сырты, тайга... Ә тайгада – әкияти матур шәһәр. Красноярск-26 – аның яшьлек шәһәре. Бу кала турында сөйләү аңа дистә еллар дәвамында тыелып килә: гранит тау сырты итәгендә урнашкан шәһәрдә хәрби корал плутоние җитештерә торган гигант комбинат эшли...

Казаннан Красноярск-26 дип аталган калага Нәзирә Бикмөхәммәтова 1950 нче еллар уртасында ире янына килә: җәмәгате армия хезмәтеннән соң монда эшкә кала. Илдә бары тик билгеле бер кешеләр генә белгән ябык шәһәргә керү җиңел булмый: бихисап анкеталар тутыру, тикшерүләр, рөхсәтне озак көтү... Нинди җитди җиргә эләгүен кыз, шәһәр капкасы янына килеп, контроль-тикшерү пунктында кораллы сак һәм чәнечкеле тимерчыбыктан ясалган, каядыр куе тайгага кереп югалган биек койманы күргәч кенә аңлый...

ТАЙГАДАГЫ ЯБЫК ШӘҺӘР

Ләкин Нәзирә бу шәһәргә шунда ук гашыйк була. Илнең атом-төш калканын булдыручылар өчен Ленинград архитекторлары проекты буенча төзелгән үрнәк социалистик шәһәр була ул. Мәһабәт «сталинка»лар белән уратып алынган мәйдан, йөзьяшәр агачлы урамнар, стадион, кибетләр... Шәһәргә яшь кадрлар бик кирәк.

– Шәһәрнең товар экспертизалары бюросы башлыгы булачаксың, – ди аңа кадрлар бүлеге мөдире кире кагарга урын калдырмаслык тавыш белән. Бу тәкъдим әле кичә генә югары уку йортын тәмамлаган кызны тәмам һушсыз калдыра. Гадәти калаларда мондый вазыйфа алу өчен кимендә егерме ел бил бөгәргә кирәк. Җаваплылыгы да никадәр бит!

Ләкин монда сорап тормыйлар – боералар гына. Хәзер ул көн-төн эштә. Бөтен кирәк-ярак төялгән вагоннар шәһәргә, төзелешкә бер-бер артлы килеп тора. Һәрберсен кабул итәргә, товарның сыйфатын бәяләп, рөхсәт биреп уздырырга яки бракка чыгарырга кирәк. Бу әле аның йөкләнгән бурычларның бер өлеше генә...

Фото: Динә Климина, Нәзирә Бикмөхәммәтованың шәхси архивыннан

ЛАВРЕНТИЙ ПАВЛОВИЧНЫҢ УДАР ТӨЗЕЛЕШЕ

Аның каравы көнкүреш белән барысы да яхшы кебек тоела. Казандагы кытлыктан соң монда чын оҗмах. Кибетләрдә җаның теләгән бцтен нәрсә, хәтта әфлисун да бар. Үз фатириң турында хыялланасыңмы? Шунда ук диярлек бирәләр. Ләкин аларның йорты торган урам шәһәр үзәгеннән зират ягына алып бара. Һәр көн тәрәзә яныннан кайгылы җеназа процессиясе уза. Җирләү командасы солдатлары, тынлы оркестр, кызыл табутка салынган яшь егетләр...

– Ничек инде ул, сугыш вакыты түгел бит, ни өчен үлә соң алар? – дип, елый-елый иреннән сорый яшь хатын. Сугышы юк, әмма булачак тау-химия комбинаты цехын ике йөз метр тирәнлектә гранитны чокып төзиләр. Аварияләр, шахталарның ишелүләре гомерләрне өзә. Баштан ук Лаврентий Берия алып барган төзелештә корбаннарны санап тормыйлар: иң мөһиме – ил оборонасын ныгыту.

Аннары гаиләгә матәм процессияләре күренми торган башка фатир бирәләр. Ләкин шәһәрнең үзенчәлеге барыбер үзен искә төшереп тора. Бервакыт күрше авылдан тыелган территориягә сыер килеп керә, хайванны суеп, түшкәсен яндыралар: радиация...

САК БУЛЫГЫЗ, РАДИАЦИЯ

Бервакыт Нәзирәне җитди учреждениегә чакырып алалар. Саклагыч кием, складтан бирелгән перчаткаларны кияргә кушалар һәм кургаш ишекле бүлмәгә озатып куялар. Берничә костюм күрсәтәләр һәм, тузу дәрәҗәсен искә алып, аларны бәяләргә кушалар. Аның аптыраулы карашын күргәч, тыныч кына аңлатып китәләр: эштәге иптәшләр нурланыш алган, костюмнарны – утильләштерергә, ә хуҗаларга аларның бәясен компенсацияләргә туры киләчәк...

Ул үз эшен башкарып чыга, шулай да озата баручыларга: «Кешеләр сәламәтлеген югалта, ә сез тиеннәрне санйысыз...» – дип әйтүдән тыелып кала алмый. Соңыннан аны берничә ай дәвамында куркыныч төшләр бимазалый: саклагыч киемнәрне пычрак зонада калдырса да, кәгазьләрне тутырган каләмне ялгыш сумкасына салып, өенә алып кайткан була...

– Шулай да күңелле вакытлар иде, – дип искә ала Нәзирә Мифтах кызы. – Без ил өчен мөһим эш башкаруыбызны тоеп яшәдек. Яшь идек. Барысына да өлгерә идек: эшләргә дә, ял итәргә дә. Еш кына коллектив белән Красноярск шәһәр театрына бара идек. Дөрес, кагыйдәләр кырыс булды. Бөтен төркемне исемлек белән автобуска утырталар, исемлек белән КПП аша үткәрәләр һәм хезмәткәрләр өчен ишек янына алып киләләр. Исемлек буенча театрга кертеп җибәрәләр, ә спектакльдән соң шунда ук автобуска утыртып, кире алып кайталар...

Ял көннәрендә берәрсенең кухнясында җыелалар. Анда ирек, иркен аралашу хөкем сөрә. Нәзирә кулына аккордеон ала, яраткан җырын суза, аңа башкалар да кушыла...

МУЗЫКА ДӘРЕСЛӘРЕ

Ул үзен белә-белгәннән бирле музыкага тартыла. Ләкин бу юнәлештә укырга туры килми. Казанда очын-очка ялгап яшәгән ишле гаиләдә үсә. Сугыш елларында кыз колхоз кырыннан өшегән бәрәңге җыеп йөри. Әнисе госпитальдән үлгән сугышчыларның канга баткан аяк чолгауларын алып кайта, шуларны юып, агартып-буяп, үзләренә кием тегәләр.

Кыз 15 яшендә эшкә чыга. Комиссион кибеткә өйрәнчек итеп алалар. Нәзирә сатучыларның башка бүлмәгә төшке аш ашарга кереп китүләрен хәтерли. Тамак ялгап, канәгать йөз белән килеп чыгалар да:

– Син ашамадыңмы әле? - дип сорап куялар.

– Ашадым, рәхмәт, – дип алдый кыз һәм, уңайсызланып, өлкәннәр артыннан савыт-саба юарга кереп китә.

Аның каравы ул эшләгән бүлектә музыка уен кораллары була – трофей буларак кайткан «Хохнер», «Вильдмайстер» аккордеонна-

Казан. Нәзирәгә 15 яшь.

туган ягына кайту телəге барлыгын тоя. Кибетлəрдə товарлар сыгылып тормаса да, Сочиның иң яхшы шифаханəлəренə юлламалар таратылмаса да, мондагыдай туры һəм төзек урамнары булмаса да, телəгəн вакытта театрга барырга мөмкин булган туган ягына. Махсус рөхсəт алмыйча, телəсə кайсы шəһəргə барып була торган Казанга!

Туган төбəклəренə бер елдан соң – 1959 елда кайта ала алар. Ул вакытта инде кайбер белгечлəрне җибəрə башлыйлар: комбинат эшли, шəһəр төзелгəн. Нəзирə дə, ире дə шəһəр турында серне сакларга сүз биреп кул куялар. Шул вакыттан бирле инде 60 елдан артык вакыт үтсə дə, аңа һаман да бер үк куркыныч төш керə: менə алар шəһəрдəн чыгар өчен, контроль-тикшерү пунктына килə, һəм шулчак кинəт паспортларын тартып алалар...

УНБИШ ЕЛ ДИРЕКТОРЛЫК

Казанда барысы да элеккечə: сусыз һəм канализациясез агач йортлар, җимерек асфальт, ярымбуш кибетлəр... Ə эш ягыннан ничек? Хəзер инде ул монда да тəҗрибəле, кадерле белгеч. Кибет директоры булырга тəкъдим итəлəр. Теге, əле өйрəнчек кыз гына булган чакта, үзе ярымач килеш тук апалар артыннан савыт-саба юган кибеттə. Тик аларның берсен дə күрергə насыйп булмый, ниндидер махинациялəр аркасында элəккəннəре турында гына ишетеп... Сирəк була торган хəл: аңа шунда ук диярлек аерым фатир бирəлəр. Дөрес, фатир – уңайлыклары булмаган агач йортта, əмма Казан өчен бу да бəхет санала.

Ул монда унбиш ел эшлəп, совет чоры директорлыгының барлык авырлыкларын татырга өлгерə: нормасыз эш көне, еш кына сигнализация эшлəве аркасында төн уртасында да шалтыратулар... Һəм югарыдан туктаусыз явып торган талəп: план, план, план! Өстəвенə, ОБХСС тикшерүлəре. Лə-

ры. Сатып алучылар булмаганда, үзлегеннəн яраткан көйлəрен уйнарга өйрəнə.

Кибеткə еш кереп йөргəн өлкəн яшьтəге бер ханым кызның көй чыгарырга азаплануын күреп ала. Ул хатын профессиональ музыкант булып чыга.

– Уйнарга өйрəнергə телисеңме? Минем янга, өйгə кил əле, сиңа дəреслəр бирермен, – ди ул бервакыт Нəзирəгə.

Бу чын бəхет була, тик бик кыска гомерле. Беренче дəрес, икенчесе... Нəзирəнең өченче килүенə ишек бикле булып чыга.

– Бакыйлыкка күчте ул, – дип хəбəр итə күршелəре. – Кичə җирлəдек.

Ул хəтердə калдырган көйлəрне уйнавын дəвам итə, үзенə аккордеон алу турында хыяллана. Беренче хезмəт хакыннан сатып та ала, югыйсə ул акчага яңа телогрейка алса, рəхəтлəнеп җылынып йөрер иде. Ə икенче көнне Шмидт урамындагы өйлəренə милиция ишек шакый. Аккордеонны комиссион кибеткə караклар тапшырган булган. Аккордеонны алып китəлəр, тик акчасын кире кайтармыйлар.

Шулай итеп, аңа матур хыялыннан баш тартырга туры килə.

ХУШ, АТОМ КАЛАСЫ

1958 елның августында алар яшəгəн Красноярск-26 шəһəрендə зур вакыйга була – тау-химия комбинаты эшли башлый, анда беренче атом реакторын эшлəтеп җибəрəлəр. Атом-төш бомбаларының төп өлеше өчен махсус корал плутониен җитештерү башлана.

Өч айдан соң, ноябрьдə, гаилəдə беренче бала туа. Бөтен игътибар аңа юнəлə. Чəнечкеле тимерчыбык уратып алган, һəр почмагын кораллы сакчылар саклаган шəһəр буйлап коляска этеп йөргəндə, Нəзирə үзендə өенə,

1958 елның ноябре. Красноярск–26. Шəһəр үзəгендə беренче балалары белəн.

Бу гранит тау астында корал плутоние җитештерү заводы яшеренгəн.

кин аның кибетендә аларга эш юк: барысы да дөрес һәм гадел алып барыла.

«СЕЗ МИНЕМ ЯРАТКАН УКЫТУЧЫМ»

Мораль яктан авырлыгы башкада: совет чорында һәр сәүдә хезмәткәрен диярлек карак итеп күрәләр. Шуңа күрә һөнәри-техник училищега укытырга чакыргач, асылда яңа һөнәр үзләштерергә туры килсә дә, Нәзирә ханым һич икеләнмичә ризалаша. Көндез дәресләр алып бара, төнлә эш планнары яза, педагогиканы өйрәнә. Гаиләдә ике бала үсә, аларга да вакыт табарга өлгерә: улы да, кызы да мәктәпне «биш»легә тәмамлый.

Ул училищеда иң яхшы укытучыларның берсенә әйләнә. Мактау кәгазьләре, бүләкләр... Әмма наың өчен башкасы мөһимрәк. Казанның һәр кибетендә диярлек аның элекке укучылары хезмәт куя. Хәзер алар үзләре директорлар, бүлек мөдирләре, сатучылар... Мөгаллимнәрен танып дәшәләр:

– Нәзирә Мифтаховна, миңа өчле куйганыгызны хәтерлисезме? Ләкин сез барыбер минем яраткан укытучым!

1984 елда пенсиягә чыкканда, аның хезмәт стажы инде 40 елдан артып китә. Тагын берничә ел эшли дә, булды, җитте, ди. Дөнья бик тиз үзгәреп тора – өлгерерлек түгел. Аннары, кем әле пенсиядә эш юк дип әйтә ала?!

ПАРК ӨЧЕН КӨРӘШ

Нәзирә Бикмөхәммәтованың көн тәртибе төгәл билгеләп куелган. Кышын, атнага бер тапкыр булса да, мәҗбүри рәвештә чаңгыда йөреп кайту. Кырык, илле һәм алтмыш ел элек кебек. Яшең туксаннан артып китү сәламәт яшәү рәвешеннән баш тарту дигән сүз түгел әле ул. Яздан көзгә кадәр аның өчен дача мәшәкатьләре дә мәҗбүри. Помидор һәм кыярсыз яшәп була димени? Үсентесен дә үзе үстерә, уңышын да җыя. Шәһәрнең икенче башына барып, сеңлесенең хәлен белеп кайтырга да кирәк. Аллаһы үзе кушкан гамәл ләбаса. Дөрес, сеңлесе яшьрәк, сиксән дүрттә генә, тик нигәдер еш авырый...

Нәзирә Мифтах кызы бүген дә тирә-юньдә булган бөтен вакыйгадан хәбәрдар. Алай гына да түгел. Өч ел элек үзләренең микрорайон халкы Казансу ярындагы төзелешкә каршы чыкканда, ул беренче сафларда йөри.

– Ничек инде, бу урында бердәнбер табигать почмагы, асылда, әзер парк, һәм аны юк итәргә телиләр! – дип, бик хисләнеп сөйли ул журналистка интервью биргәндә, соңыннан бу интервью җирле телеканалларның берсендә күрсәтелә.

Сүз уңаеннан, бергәләшеп паркны яклап калалар.

Юбилей көнендә оныгы белән.

ЧӘКЧӘК ҺӘМ ПРЕЗИДЕНТТАН КОТЛАУ

Сигезенче мартта тыл хезмәтчәне, хезмәт ветераны Нәзирә Мифтах кызы Бикмөхәммәтовага 95 яшь тулды. Аны куанычлы яңалык көтә: Россия Президентыннан котлау открыткасы килеп төшә. Бу көнне һәрвакыттагыча тәмле аш шулпасы, чәкчәк пешереп бәйрәм табыны әзерли. Ләкин көтмәгәндә балаларына һәм оныкларына, бер көн соңрак, тугызында килерсез, дип шалтырата:

– Мин сезнең 8 Мартыгызны гел урлыйм, бу юлы гаиләләрегездә бәйрәм итегез.
Ә икенче көнне – минем янга...

Тормыш дәвам итә.

Кайвакыт, хатирәләр зилзиләсе еракларга алып кереп киткәндә, ул үзенең иске аккордеонын тартып чыгара да яраткан көйләрен уйный. Красноярск-26 каласында яисә ял көннәрендә дачада шат күңелле чаңгычылар компаниясе җыелган чакта сузган көйләрне.

«Хохнер»ның бер төймәсе басылып кала, бармаклары да инде элекке кебек җитез түгел, ләкин көйләре аныкы. Аның тормышыннан.

20 НЧЕ ТАРИХ

«СУГЫШТА ТАМАГЫМ ТУЯР, ДИДЕМ...»

Руфия Фазылова

Бөек Ватан сугышы башланганда Кама Тамагы Keләнче авылында яшәүче Вазыйх Ногмановка ундүрт яшь була. Авылның дистәләгән ир-атын барысын берьюлы фронтка озаталар. Шуның өчен дә үсмер егетләр колхозның төп эшче көченә әйләнә. Ләкин егетләрнең тылда түгел, фронтта үзләрен күрсәтәсе килә. Уналты тулгач ук, ул район военкоматына китә. Аны өенә кайтарып җибәрәләр. Бер елдан соң, унҗиде яшендә генә, кулына повестка бирәләр. Әнә шулай итеп 1944 елның сентябрендә Keләнче авылының япь-яшь егете армиягә китә...

«ӘСИРЛЕККӘ ЭЛӘКТЕК»

Вазыйх бабай 20 мартта 97 яшен тутырган. Бүген ул улы Ринат, килене Алсу тәрбиясендә яши. Гадәттә, «нурлы» сүзен акъэбиләргә карата кулланабыз, бу очракта безнең ветеранга да бик туры килә бу сүз. Вазыйх бабайның да ниндидер бер сөйкемле сөяге бар.

– Исән-сау килеп җиттегезме? – дип, ихластан сөенеп, кулын сузды ул.

Бу мизгелдә тамакка төер тыгылды... Их, сине шулай каршы алучы дәү әтиең булса иде... Бабакайның оныклары бу бәхетне аңлыймы икән?

– Шушы нигездә гомерем узды, – диде Вазыйх бабай. – Ә минә бабаларым аргы якта яшәгән. Җәмәгатем Мәрьям белән монда балалар үстердек. Өч кыз белән бер ул безнең. Ринат безнең янда калды, Аллаһның рәхмәте булсын. Әле минә хәзер кем карар иде. Яшь барган саен ялгыз яшәп булмый, бик кадерләп тоталар, сүз әйтә торган түгел.

Җайлап кына Вазыйх бабайдан үткәннәр турында сорашабыз. 17 яшендә үзе теләп хәрби хезмәткә китә бит.

– Ул вакытта ФЗӨ яки шахтага алып китәләр иде, – дип ачыктан-ачык сөйләде ветеран. – Район военкоматында безнең авыл кешесе Хуҗи Нәҗмиев эшли иде. «Хуҗи абый, минем анда барасым килми. Зинһар, фронтка җибәр», – дидем. Хуҗи абый каршы килмәде. Әнә шулай итеп унҗиде яшемдә армиягә чакырылдым.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Шахтага караганда сугышта әйбәтрәк булыр дип уйладыгызмы? – дим, аптырап.
– И, кызым, яшь чак бит, илдә сугыш барганда бөтен кешенең үз өлешен кертәсе килде. Аннан, фронтта тамак туяр, дип тә уйладым. Ул елларда ачлыктан бик интектек, бик...
Вазыйх Ногманов фронт юлын Белоруссиядә – 251 нче конвой гаскәрендә башлый. Беренче Белоруссия фронты белән Вильнюс шәһәренә җитә. Яшь солдатның беренче бурычы – партизаннарга азык-төлек һәм корал илтү. Икенчесе – тоткыннарны тиешле урынга озату, качырмау. Алар гаскәре Минск, Гроднода хезмәт итә, Польша чигендә дә булалар.
– 1945 елда Брест шәһәрен азат итүгә безнең дә өлеш керде, – диде ветеран. – Белоруссиядә партизаннар күп иде, без аларны азык-төлек белән тәэмин иттек. Берсендә үзебезнең солдатларга әсирлеккә эләктек. Чынлап менә! Хәлгә ачыклык керткәнче, безне бер айга якын бикләп тоттылар. Совет солдатлары икәнлегебезгә инангач кына җибәрделәр.
Вазыйх Ногманов 1950 елның апреленә кадәр Брестта хезмәт итә. Әнә шулай алты ел илен саклап читтә йөргәннән соң, туган ягына әйләнеп кайта.
– Сугыш беткәндә солдатлар аз иде, шуның өчен дә безне хәрби хезмәттән азат итмәделәр, – ди ветеран. – Татарстаннан Белоруссиядә алты кеше идек. Алты ел эчендә ике тапкыр авылга ялга кайттым. Әти-әнием карт булганга күрә, шулай җибәрделәр. Беренче кайтканда әти исән, икенчесендә мәрхүм иде.

АЛДЫНГЫ БРИГАДИР

Туган авылында Вазыйхны дүрт күз белән көтәләр: эшче көчләр бик кирәк. Фронтта булган, дәүләт бүләкләре алган егеткә зур өметләр баглыйлар. Һәм Вазыйх Ногманов аларны аклый да. Колхозга эшкә керә, беренче елны ат җигә. Озакламый Келәнченең икенче урамында яшәүче Мәрьям исемле кыз белән гаилә дә коралар.
– Мәрьям апа белән озак очрашып йөрдегезме? – дим.
– Юк, берничә ай гына. Мәрьямнең игезәк Исхак белән Исмәгыйль исемле абыйлары бар иде, мин шулар янына барып йөрдем. Алар белән колхозда да бергә эшләдек. Шул чакта Мәрьям белән дә якыннан аралашып киттек. Язын Келәнчегә кайтсам, көзен гаилә дә кордым. Дөресен генә әйткәндә, апалар ашыктырды. Әни өлкән яшьтә, аңа тәрбия кирәк иде. Йортта хатын-кызсыз булмый. Мәрьям каршы килмәде, яраткандыр инде. Рәхмәт, җәмәгатем ипле кеше иде, әни белән дә матур яшәделәр.
1951 елның көзендә Вазыйх Ногмановны колхоз бригадиры итеп билгелиләр. Дүрт класс белеме булган яшь ир башта каушап та кала. Ни дисәң дә, җаваплы эш – колхозда биш бригада, аларның барысының да эшләрен җайлап, тәртипләп тотарга кирәк. Ләкин колхоз рәисе сүзендә нык тора: «Син булдырасың аны, Вазыйх. Тырышлыгың, җаваплылыгың бар!» – ди. Рәис ялгышмый, тиз арада Келәнче авылы колхозы яшелчә үстерү буенча алдынгылар рәтендә йөри башлый. Әлбәттә, монда Вазыйх Ногмановның өлеше бик зур була.
– 1954 елда авылга тракторлар, комбайннар кайтты, шул рәвешле кул хезмәте кимеде, – дип искә ала Вазыйх бабай. – Яшелчә үстерү буенча данныбыз районда гына түгел, республикада да таралды. Тәҗрибә уртаклашырга дип, башка районнардан да килделәр.
Кырык елга якын эшләү дәверендә Вазыйх Ногманов күпсанлы орден-медальләр, ВДНХ дипломнары, мактау грамоталары белән бүләкләнә. Ветеран аларның һәркайсын кадерләп саклаган. Безгә дә бер горурлык белән күрсәтте. Әйе, совет кешесе өчен ул бүләкләрнең кыйммәте бәһасез, берминди акчалар белән дә алыштырып булмый торган хөрмәт билгесе шул алар.
Ветераннан озын гомерле булу сере турында да сораштык. Туганнары, чордашлары, берсе дә исән түгел икән. Аллаһка шөкер, яше өлкән булуга карамастан, Вазыйх бабай үз аягында йөри, акылы камил, хәтере яхшы.

НОГМАНОВ ВАЗЫЙХ ҖИҺАНША УЛЫ ОКТЯБРЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕ, КЫЗЫЛ БАЙРАК, «ПОЧЕТ БИЛГЕСЕ» ОРДЕННАРЫ, «ГЕРМАНИЯНЕ ҖИҢГӘН ӨЧЕН» ҺӘМ БАШКА БИК КҮП МЕДАЛЬЛӘР БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘНГӘН.

Бүген Вазыйх Ногманов улы Ринат, килене Алсу тәрбиясендә яши.

– Кече Кариледән Салих, Варис исемле егетләр белән бергә хезмәт иттек. Алар мәрхүм инде, – дип куйды Вазыйх бабай. – Бу кадәр озак яшәрмен дип уйламый идем. Тәрбия яхшы, Аллаһка шөкер. Күптән түгел төш күрдем, бер фәрештә килеп: «101 яшькә кадәр яшисең», – диде.

– Әтинең күңеле бик яхшы, берәүгә дә үпкә сакламый, – диде ветеранның улы Ринат абый. – Гомер буе бригадир булып эшләп, ник бер кеше белән сүзгә килеп йөрсен. Шуның өчен дә озын гомерле булгандыр ул. Безгә карата да яхшы, үрнәк эти булды. Исән генә булсын, дип телибез.

...Бүгенге көндә Вазыйх Җиһанша улының 8 оныгы һәм 9 оныкчыгы бар. Алар кайтып йөри, ветеранның зур юанычлары. Бабакайның тагын бер сөенече – умарталар. Вазыйх бабай гомер буе умарта тоткан, кайчандыр бабасыннан калган бу шөгыльне дәвам иткән. Иң сөенечлесе – нәсел шөгыле әле дә яши, бүген дә берничә дистә корт оясы бар. Бу эш хәзер Ринат абый җилкәсендә, ә Вазыйх ага читтән күзәтеп кенә тора. Алар ветеранга яшәргә көч, дәрт бирә.

Нәсел шөгыле әле дә яши, бүген дә гаиләдә берничә дистә корт оясы бар.

Вазыйх бабай бакча башындагы чишмәне дә карап торган.

ЭЛЬМИРА ЗАРИПОВА, ТР хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры:

– Кызганыч ки, биш ел эчендә ветераннар саны өч тапкырга кимеде. Соңгы мәгълүматлар буенча, 2024 елның май башына Татарстанда 11 058 Бөек Ватан сугышы ветераны һәм хәрбиләрнең тол хатыннары яши. Шуларның 41 е – сугышта катнашучы, 113 е – инвалид ветеран, тагын 41 кеше хәрби хезмәттә катнашкан, хәрби частьләрдә, учреждениеләрдә һәм хәрби-уку йортларында хезмәт иткән, ләкин алар хәрәкәттәге армия составына кермәгән.

САН

Бөек Ватан сугышы инвалидларына ай саен акчалата компенсация бирелә.

2024 елның 1 гыйнварыннан ул

I төркем инвалидларга – **22 908** сум,

II төркем инвалидларга – **11 454** сум,

III төркем инвалидларга **4 581** сум тәшкил итә.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Галимҗан Сәйфетдинов тарихта **нинди** эз калдырган

Муса Җәлил Минзәләдә **кемгә** атап шигырь язган

Шәехгаттар Иманаев **нинди** эшләр башкарган

Китап киштәсендә **ниләр** бар

БОЛЬШЕВИК ГАЛИМҖАН СӘЙФЕТДИНОВ

Илдус Заһидуллин

Галимҗан Ибраһимов «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле хезмәтендә бу шәхескә бик югары бәя бирә: «Ямашевтан бер генә ел соң, аның белән бергә социал-демократ большевиклар сафында эшли башлап, үзенең ару-талу белмәс тырышлыгы, гадәттән тыш фидакарьлеге, иң каты кысу, җәберләү вакытларында да үз юлыннан кайтмавы белән аеруча урын алганнарның берсе, беренчесе – шөбһәсез, Галимҗан Сәйфетдиновтыр».

Бүген марксизмның социалистик һәм коммунистик җәмгыять турындагы теориясе утопия икәнлеген аңлаган хәлдә, большевик Галимҗан Сәйфетдиновның тормыш юлы үзенең эш-гамәлләренең хаклыгына чын күңелдән ышанган, сыйнфый дошманнарны тар-мар итеп, патшаны җиңеп, хакимиятне эшчеләр үз кулларына алгач төзеләчәк җәмгыятьтә генә чын демократия, гади халыкка яхшы һәм тук тормыш булачак дип инанган һәм аңлы тормышын шушы максатка багышлаган шәхес эшчәнлеге буларак кызыклы. Галимҗан Сәйфетдинов шәхесе, бернинди кыенлыкларга карамыйча, сәяси максатына ирешү өчен ахыргача көрәшкән татар революционеры буларак та игътибарга лаек.

СӘЯСИ КАРАШЛАР ФОРМАЛАШУЫ

Галимҗан Җамалетдин улы Сәйфетдинов Оренбург губернасында урнашкан Троицк шәһәрендә 1882 елның 15 гыйнварында дөньяга килә. Гаиләдә беренче бала була. Әти-әниләре Җамалетдин белән Хәбибҗамал, бәхет эзләп, Казан өязеннән шушы урынга килеп төпләнә. Гаиләнең матди хәле җиңелдән булмый.

Әтисе улын 8 яшендә мәдрәсәгә бирә. Галимҗан анда, дин сабагыннан тыш, уку йорты каршында эшләп килгән рус сыйныфында белем ала. 1898 елны Троицкиның 3 нче шәһәр училищесына укырга керә, зиһенле һәм бик яхшы билгеләргә генә укучы булып таныла.

Укуын тәмамлаганчы ук имтиханнарын уңышлы тапшырып, башлангыч рус-татар мәктәбе өчен мөгаллимнәр әзерләүче Казан татар укытучылар мәктәбенә (КТУМ) кабул ителә. Биредә иҗтимагый-мәдәни чараларда актив катнашучы, нәфис сүз остасы, фәннәрне җиңел үзләштерүче, рус әдипләренең әсәрләрен яратып укучы йөгерек каләмле егет булып танылa.

Галимҗан Хөсәен Ямашев йогынтысында 1902 елны КТУМндә революцион юнәлешле яшерен укучылар түгәрәге оештыра.

1903 елда егетнең Крестовников заводы эшчеләренең яшерен марксистик түгәрәге эшендә катнашуын ачыклагач, артыннан күзәтү оештырыла. Кулга алынырга берничә көн калгач, укудан ял алып, Галимҗан Верхнеуральск шәһәренә китә, шул рәвешле зинданга эләкми кала.

Казанга кайткач, Россия социал-демократик эшчеләр партиясенең (РСДРП) Казан комитеты әгъзасы итеп кабул ителә, 1904 елның 8 ноябрендә Татар зираты янында уздырылган татар приказчиклары сходкасы вакытында кулга алына һәм укудан куыла.

1905 ЕЛ ВАКЫЙГАЛАРЫНДА

Гаебе расланмагач, 1905 елның март аенда аның өстеннән полиция күзәтүе алына. Беркайда да эшләмәгән Галимҗан 1905 елдан, Хөсәен Ямашев белән бергә, большевикларның листовкаларын татарчага тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Русча белмәгән һәм туган телләрендә укучы татарларга йогынты ясауның мөһим чарасы була алар. Җәйдән башлап РСДРПның Казан комитеты тәрҗемә эшләрен тулысы белән Сәйфетдиновка йөкли. Галимҗан

Фотолар автордан алынды

бу елда 20 прокламация, 8 брошюра һәм 4 революцион җыр текстын тәрҗемә итеп бастыра. Шул исәптән, ноябрь аенда 6 прокламация, гектографта 2370 данә итеп күбәйтелеп, Оренбург, Әстерхан, Самара, Уфа губерналарына җибәрелә.

Галимҗан бер үк вакытта, Казан комитеты кушканны үтәп, татар эшчеләренә һәм приказчикларына сәяси түгәрәкләр оештыра, шулай ук Крестовниковлар, Алафузовлар һәм Дары заводы эшчеләре арасында аңлату эшләре алып баруда һәм сходкалар оештыруда катнаша.

Аның мәхәббәтен табуы да шушы эш белән бәйле килеп чыга. 1905 елның октябрендә Воскресенская урамында митингка җыелган халыкны атлы полиция камчылап тарата башлагач, җәрәхәт алып, Галимҗан аңын җуя. Урамда һушсыз яткан егеткә беренче ярдәмне Александра Войдинова исемле кыз күрсәтә, фатирына алып кайта. Соңрак алар бергә яшәп китәләр.

1905 елның 11 декабрендә шәкертләр җыелышында полиция тарафыннан тоткарлана, икенче көнне фатирында тентү ясаганда конфискацияләнгән әйберләр егетнеңниләр белән шөгыльләнгәнен чамаларга мөмкинлек бирә: 25 рөхсәтле китап, большевикларның «Заря» журналы, РСДРПның Казан комитеты тарафыннан басылган русча манифест, патша хакимиятен бәреп төшерергә өндәгән русча прокламацияләр һәм аларның татарчага тәрҗемә ителгән караламалары, шулай ук татарча революцион җырлар караламалары, 6 револьвер патроны табыла.

Галимҗан татар эшчеләре, приказчиклары, шәкертләре арасында агитация алып бара, «Дуслар», «Иптәшләргә», «Казан гражданнарына», «Һәркемгә», «Приказчикларга», «Җәмәгать», «Бөтенхалык учредительное собраниесе» һ.б. исемнәр куеп листовкалар тәрҗемә итә.

Хакимияткә каршы эшчәнлектә гаепләнеп, революционер 6 ай ярым шәһәрнең күчү зинданында утырып чыга.

БЕРЕНЧЕ СӨРГЕН ЧОРЫ: ОРЕНБУРГНЫҢ АКТИВ ЖУРНАЛИСТЫ

Галимҗан 1906 елның июль аенда ике елга Оренбургка сөрелә. Александра Войдинова да хатыны сыйфатында бирегә күченеп килә.

РСДРПның Оренбург төркеме Галимҗанга сәяси пропаганда һәм агитация алып баруны йөкли. Татар эшчеләре белән аралашудан тыш, Сәйфетдинов большевикларның Оренбургта рәсми нәшер ителгән «Наш край» (1906), «Степь» (1906), «Простор» (1907) газеталарында үзенең сәяси кушаматын – «Гассан» исемен – куеп мәкаләләр бастыра.

Сәйфетдинов 1906 елның октябрендә «Оренбургский край» газетасы редакциясенә эшкә урнаша. Анда татар телендә газета чыгару фикере туа. Планын тормышка ашыру өчен, 1906 елның ноябрь башында РСДРПның Казан комитетынннан татарча шрифтлар һәм типография станогы сората. Ләкин җибәрергә әзерләнгән әйберләрне полиция конфискацияли. Шул сәбәпле ул шәһәрдә татарча китаплар, газета-журналлар нәшер итүче бердәнбер матбага хуҗасы Фатих Кәрими белән үзенең яңа газетасын бастыру хакында сөйләшә.

1906 елның ноябрендә Оренбургка гаиләсе белән Хөсәен Ямашев та күченә. 1905 ел ахырында РСДРПның Казан комитеты туздырылгач, ул, полиция эзәрлекләвеннән качып, Чистайда, Уфада яшәп алган була.

Шул арада Фатих Кәрими типографиясе нигезендә, Оренбург сәүдәгәре Х. Хөсәенов, Орск сәүдәгәрләре Рәмиевләр һәм М.Г. Фәйзуллин керткән 40 мең сум акча хисабына «Кәримов, Хөсәенов һәм К ширкәте» оештырыла, татар шрифтлары алына.

1907 елның 4 гыйнварыннан атнага 2–3 тапкыр 4 битлек («Искра» кебек кечкенә форматта) «Урал» газетасы басыла башлый. Аның фикри җитәкчесе – Хөсәен Ямашев, рәсми редакторы Хәдичә Ямашева була, нәшире итеп Тимерша Соловьев билгеләнә. Газета бастыру белән бәйле көндәлек мәшәкатьләр (кульязмаларны редакцияләү, газетаны таныш адреслар буенча шәһәрләргә җибәрү һәм даими рәвештә «Гассан», «Баязит», «Баязитов», «Сәйфи» псевдонимнарын куеп мәкаләләр, шулай ук авторы күрсәтелмәгән «ачык хат» һәм «мөрәҗәгать» текстларын язу) Галимҗан җаваплылыгында була. «Урал» үзен рәсми төстә социал-демократик басма дип атамый, ләкин аның беренче санындагы баш мәкаләсендә редакциянең сәяси мәсләге ачык чагыла.

Редакция газетага кушымта рәвешендә татарчага тәрҗемә итеп бастырган биш сәяси эчтәлекле брошюраның өчесен – «Гомуми сайлау правасы турында», «Россия социал-демократлар партиясе авыл халкы өчен нәрсә булдырырга тырыша?», «Безнең якында булдырырга теләгән нәрсәләребез һәм төп максатыбыз» исемлеләрен – басмага Сәйфетдинов әзерли. Шулай ук аның тәрҗемәсендә берничә революцион җырлар җыентыгы («Эшчеләр марсельезасы», «Авыл кешесе җыры», «Алга, иптәшләр!» һ.б.) нәшер ителә.

Полиция «Урал» редакциясендә берничә тапкыр тентү үткәрә, 1907 елның 27 апрелендә газетаны яба. Оештыручылар, шул исәптән Галимҗан да хөкемгә тартыла, аларга карата тикшерү эше 1909 елга кадәр дәвам итә.

ИКЕНЧЕ СӨРГЕН ЧОРЫ: УРЖУМ ШӘҺӘРЕ ҺӘМ КАЧЫП ЙӨРҮ

Хакимият Сәйфетдиновны, Оренбургта сәяси пропаганда алып бармасын өчен, 1907 елның 11 маенда 1 елга Вятка губернасындагы Уржум шәһәренә сөрә.

Уржумда аның кебек сөрелгән большевиклар, меньшевиклар, анархистлар, эсерлар

шактый була. Сәйфетдинов РСДРПның Уржум төркеменә керә һәм төрле сәяси карашлы шәхесләрне берләштергән «Уржум өязенә сөрелгәннәр союзы»нда әгъза була. Сәяси диспутларда катнаша, хәтта союзның үзәк идарәсенә дә сайлана. Август ахырында фатирында крестьяннарны укытуда гаепләнеп тентү ясаганда, күпчелеге сәяси эчтәлекле 30 китап конфискацияләнә.

Галимҗан сентябрь ахырында, ялган паспорт юнәтеп һәм сөргеннән качып, Уфа шәһәренә килеп урнаша. Янына килгән көмәнле хатыны Войдинова белән Чиләбегә барышлый Златоуст шәһәрендә улы Вениамин туа.

Качкын Чиләбедә китап төпләү мастерскоена эшкә урнаша һәм шәһәрдәге большевиклар оешмасында татар төркемен оештыра, кабат татарча газета чыгару мәшәкатьләре белән йөри башлый. Ләкин илдә башланган сәяси әзәрлекләүләр максатына ирешергә мөмкинлек бирми. Ул, качып, бер шәһәрдән икенчесенә күченеп йөрергә мәҗбүр була.

Сөрген срогы бетәр алдыннан, иреккә чыгу турында документ юнәтү өчен, Уржумга кайта һәм кулга алына. Качып йөргәнен исәпкә алып, сөрген срогы 10 ай 9 көнгә озайтыла. Хатыны һәм улы күченеп килеп, тоткынның тормышына гаилә җылысын бирәләр.

КАЗАНДАГЫ ТОРМЫШ, ЯКИ «МИЛЛӘТ МИКРОБЫ»

Галимҗан, сөрген срогын тутырып, 1909 елның маенда гаиләсе белән Казанга кайта һәм 7 ай дәвамында даими эш таба алмый интегә. Кадетлар матбагасы «Камско-Волжская речь» редакциясенә эшкә урнашырга тырышып, «Гассан» имзасы куеп, рус укучысын татар мәдәнияте һәм мәгарифе белән таныштырган дистәдән артык мәкалә бастыра.

Сәяси тоткын Галимҗан Сәйфетдинов. 1906 ел.

Фәкать 1910 елның башында зур кыенлык белән Глинкинның «Экспорт конторасы»на хезмәткәр булып урнаша.

Сәйфетдинов социал-демократ студентлар төркеменә керә, таркау төркемнәрне берләштерергә тырыша. 1909 елны аның фатирында булган киңәшмәдә Галимҗан тәкъдиме белән РСДРПның Казан комитетын торгызу һәм прокламацияләр бастыру өчен типография булдыру хакында карар кабул ителә. Ләкин 1910 елның 29 апрелендә РСДРПның Казан төбәк төркеме тар-мар ителә һәм сөргенгә җибәрелә.

Сәйфетдинов һәм Ямашев бу вакытта татар яшьләре белән аралашуны көчәйтәләр. Галимҗан Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров, Г. Тукай, Г. Камал белән якыннан аралаша. Бер үк вакытта Сәйфетдинов фатирында даими рәвештә большевикларның яшерен җыелышлары үтә.

1912 елның 26 мартында вафат булган Хөсәен Ямашевны җирләгәндә татар зиратында чыгыш ясап, Галимҗан остазын татарлар арасында социалистик хәрәкәтнең җитәкчесе дип атый.

Шул елның 18 мартында төзелгән РСДРПның Казан вакытлы комитеты, 20 апрельдә җитәкчеләре (16 большевик) кулга алынгач, кабат яшәүдән туктый. Сакланып калган кечкенә төркем составында Галимҗан завод-фабрика эшчеләре арасында агитация эшен дәвам итә.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк: Галимҗан көчле либерал рухлы татарча матбугат нәшер ителүне, татарларда милли үзаң көчәюне сыйнфый көрәшкә һәм интернационализмга зыян салучы факторлар дип саный. Әйтик, бер мәкаләсендә Галимҗан «Бәянелхак»тан сатлыкҗан матбага дип көлә. Урамда барганда газетаның нәшире Әхмәтҗан бай Сәйдәшев аңа таяк белән ташлана; большевикны милли хисләре булмаган «милләт микробы» дип мыскыллап мәкалә бастыра. Галимҗан «әл-Ихлас»ның 1909 елның 22 июль көнне дөнья күргән соңгы санында Сәйдәшевкә атап «ачык хат» урнаштыра, үзенең милләткә зыян китермәвен дәлилләргә алына, киләчәктә нәрсә теләсә, шуны язачагын белдерә. Шул ук вакытта, 1913 елны татар приказчиклары җыелышында, сыйнфый бердәмлек хакына, аларны җомга көнне түгел, ә рус приказчиклары белән бер көнне ял итәргә үгетләп һәм, кыйналудан чак котылып, җыелыштан качып китәргә мәҗбүр була. 1914 елның 23 февралендә Габдулла Кариев фатирында узган татар зыялылары җыелышында бәхәсләшеп, Гаяз Исхакый яклылылар белән сүзгә килә. Татар милләте язмышын кайгырткан актив җәмәгатьчелек белән мондый каршылыкларга мисалларны тагын да китерергә мөмкин.

Галимҗанның әтисе Җамалетдин, улы Вениамин һәм сеңлесе Хәдичә.

Сугышта Россиянең җиңелүе өчен җан аткан һәм империалистик сугышны гражданнар сугышына әверелдерү хакында В.И. Ленин күрсәтмәсен тормышка ашыручы большевиклар башка партияләргә каршы позициягә басалар. Сәяси бәхәсләр нәтиҗәсе буларак Галимҗан Сәйфетдинов һәм Александра Войдинова гаиләсе таркала, соңгысы Я. Брук фамилияле меньшевикка кияүгә чыга. Шуңа да карамастан, Галимҗан улы Вениамин белән еш аралаша.

1917 елның Февраль инкыйлабыннан соң Казанда татар милләтчеләре Вакытлы хөкүмәт яклы Мөселман комитеты төзи.

Галимҗан Сәйфетдиновның турыдан-туры катнашында 1917 елның мартында бер төркем татар эшчесе большевиклар сафына кабул ителә.

7 апрель көнне татар социал-демократларын һәм социал-революционерларын берләштерәчәк Мөселман социалистик комитетының Мулланур Вахитов һәм Галимҗан Сәйфетдинов төзегән уставы раслана. Галимҗан яңа оешманың эшчеләр эшләре буенча комиссиясен җитәкли. Берничә айдан Мөселман социалистик комитеты составында Сәйфетдинов җитәкчелегендә 6 кешелек большевиклар фракциясе оеша.

Ул кабат тәрҗемә эшенә алынып, большевиклар партиясенең уставын һәм программасын, шулай ук «Марсельеза» һәм «Варшавянка» җырларын татарчага тәрҗемә итә. Татар эшчеләре 1917 елның 1 Май демонстрациясендә, кызыл байрак күтәреп, Кәрим Тинчурин хор белән җырларга өйрәткән шул сәяси куплетларны Казан урамнарында яңгыраталар.

Май уртасында агитация һәм пропаганда үзәгенә әверелгән Эшчеләр клубының уставын һәм эчке кагыйдәләрен әзерләүдә актив катнаша.

Сәйфетдинов, Приказчиклар союзы матбагасы «Аваз» газетасының редколлегия әгъзасы сыйфатында аның битләрендә татар эшчеләрен яклап, Вакытлы хөкүмәткә каршы мәкаләләр бастыруга да зур игътибар бирә, үзе дә мәкаләләр яза. 1917 елның 17 июленнән Мөселман социалистик комитетының үз матбагасы – «Кызыл байрак» газетасы нәшер ителә башлый. Галимҗан Сәйфетдинов аның редколлегиясе әгъзасы була.

Шәһәрдә оештырылган күпсанлы митингларда ялкынлы чыгышлар ясаучыларның берсе большевик Сәйфетдинов була. 1917 елның июль аенда ул хәрби хезмәткә алына, Казан юнкерлар мәктәбенә укырга билгеләнә. Биредә дә курсантларның яшерен түгәрәген оештырып җибәрә.

1918 елның 7 августында Казанга чехословаклар корпусы бәреп кергәч, шәһәрдән чыгып китә алмый кала. Кызыл гаскәр Казанны азат иткән 1918 елның 10 сентябре көнне интервентлар кулыннан һәлак була.

РСФСР хөкүмәте һәм Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты Президиумының 1926 елның 22 апрелендәге уртак карары белән Галимҗан Сәйфетдиновның революцион казанышлары өчен әтисе Җамалетдингә гомерлек персональ пенсия билгеләнә. Аның вафатыннан соң, РСФСР хөкүмәтенең 1933 елның 8 апрелендәге карары нигезендә гомерлек персональ пенсия әнисе Хәбибҗамалга түләнә башлый. Бу аларның улларыннан күргән бердәнбер яхшылыгы дияргә нигез бар.

Галимҗан Сәйфетдинов, реакция елларында большевиклар партиясе карарларына тугры булып, «ике фронтта» – милләтчелеккә һәм хакимияткә каршы көрәшә. Без аны, беренче чиратта, сәясәтче дип атый алабыз.

СУГЫШКА КАДӘР 56 КӨН

Әхмәт Шакиров

Муса Җәлилне сугышның беренче аенда ук мобилизацияләр. Ләкин язмыш аны туган ягына тагын бер мәртәбә кайтара әле. Мәңгелек кебек тоелган бу 56 көнен шагыйрь татар җирендә – Минзәләдә үткәрә. Бүген биредә эшли торган Муса Җәлил музеенда бу көннәр турында барысын да беләләр кебек.

Минзәлә үзәгендә ике катлы борынгы йорт. Кырык беренче елның ноябрендә Җәлил шунда торган. Ничек булган соң? Сугыш башында немецлар зур көч белән илнең үзәгенә ыргыла. Курсант Җәлилов укыган политруклар курсы фронт сызыгына бик якын кала, шуңа күрә командование аларны тиз арада тылга эвакуацияләргә карар итә.

СӘКЕ, БЕРЕНЧЕ РӘТ. ӨСКЕ КАТ

Эшелон белән Бөгелмәгә кадәр кайталар, аннан Минзәләгә кадәр – йөз илле чакрым җәяүләп. Көзге яңгырлардан сазга әйләнгән юлдан атлаганда Җәлилнең күнитеге яраксызга чыга, дип искә алалар. Муса югалып калмый, якындагы бер авылда беренче очраган йортка кереп, берничә минуттан, итеген култык астына кыстырып, чабатадан килеп чыга һәм сафка баса. Аны күлеп каршы алалар – бу мәзәк хәл кәефне күтәреп җибәрә...

– Ә менә бу йорт – педагогика училищесы бинасында (бүген – педагогика көллияте) курсантлар укыган да, яшәгән дә, – дип таныштыра экскурсовод. – Хәрби, кырыс вакыт. Казармада өч рәт итеп сәкеләр ясалган. Муса белән бергә укыган курсташлары аның уңайсызлыкларны бөтенләй сизмәвен искә ала.

Дөрес, шагыйрь берсендә шаяртып кына бер танышына зарланып ала: барысы да яхшы, әмма аңа, кечкенә буйлы булганга, ятакка

Фото: Әскәр Сабиров, Александр Ефремов, menzelinsk.tatarstan.ru

мену авыррак, чөнки шагыйрьгә иң «почетлы» өченче каттагы урын туры килә.

Өч рәткә тезелгән сәкеле казарма, әлбәттә, сакланып калмаган. Ләкин музей бүлмәсендә аның макетын күрергә мөмкин. Янәшәдә ул вакыттагы әйберләрнең төп нөсхәләре: үзебезнең һәм трофей булып алынган корал, политруклар корал кулланырга да өйрәнгән. Алар янында Совинформбюроның соңгы хәбәрләре тапшырыла торган тавыш көчәйткечле радио: халык фронт сводкаларын тыңлар өчен шул «тәлинкә» янына җыелган. Патефон да шул елларныкы – анысында кыска ял вакытларында яраткан җырлар яздырылган пластинкалар әйләндергәннәр...

«ҖЫРЫ БЕЛӘН ИСКӘ АЛЫРСЫҢ»

Танылган шагыйрьнең Минзәләдә булуы турында җирле халкы очраклы рәвештә белә. Ике кыз элемтә бүлегендә «нәкъ Җәлил кебек» бер абыйны күреп, укытучылары Мөхәммәт Гарифуллинга әйтә. Ул, ышанып бетмичә, почтага керә. Һәм чыннан да Җәлил бит! Кыскарак буйлы, озын шинельдә, аягында – кирза итек. Исәнләшәләр, шагыйрь үзенең кыяфәте турында шаяртып та ала: янәсе, шинельне кыскартырга кирәк, җиңнәреннән бармаклары күренми... Гарифуллин шагыйрьне кунакка чакыра, кунак иkенче көнне килә дә...

Муса курсларда яхшы укый, шәһәргә чыгарга рөхсәт алу белән проблемалар булмый. Кичләрне ул еш кына танышлары – Сабировлар йортында үткәрә. Кайвакыт мандолина чиртә, хуҗаларның кызы Иншәрдән, шаяртып кына, артист була аламмы, дип сорый. Мәктәптә яхшы укырга да, өйдә әнисенә булышырга да өлгерүче Иншәргә Җәлил чын күңелдән сокланып карый. Фронтка китәр алдыннан аңа багышлап шигырь дә яза:

Хуш, акыллым, авыр, канлы елда
Таныштык без, үтеп барышлый.
Китәм саклап кайнар йөрәгемдә
Сезгә булган татлы сагышны.

Исән кайтсам, тагын күрешербез,
Ә кайтмасам... җырым сагынсын!
Сине сөйгән шагыйрь абыеңны
Җыры белән искә алырсың.

Иншәр шагыйрь абыйсының үтенечен үти – Җәлил бүләк иткән текстны саклап кала. Батырларча һәлак булган шагыйрьне хыянәтче дип санаган елларда мондый гамәл бик куркыныч тәмамланырга мөмкин булса да.

«...СИНДӘ КУНАК БУЛДЫМ БИК АЗ ГЫНА, ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ»

Музейда Җәлил еш кунак булган Сабировлар йортындагы бүлмә күренешен дә торгызалар. Өстәлдә – пионерка Иншәр фотосы. Диварга мандолина эленгән. Өстәл янына кайчандыр Сабировларныкы булган урындык – төп нөсхә.

Музейда курсант Җәлиловның шәхси әйберләре юк. Хәер, курсантның шәхси әйберләре нинди булырга мөмкин соң? Шинель, форма, биштәр, дәфтәр? Алар барысы да хуҗалары белән фронтка китә. Әмма шәхси әйберләргә караганда да кыйммәтлерәк саналган экспонатлар бар - шигырь юлларына күчкән Җәлил фикерләре һәм хисләре. Биредә, Минзәләдә дә, ул иҗатын туктатмый. Шигырьләренең күбесе шул вакытта ук җир-

ле газетада басыла – 1941 елгы район матбагасының саргайган битләре хәзер музей витринасына урнаштырылган.

56 көн дәвам иткән уку чорында Муса күп кенә минзәләлеләр белән аралаша. Район мәдәният йортында шигырьләр укый, әдәби-музыкаль кичәләр оештыра, «Кызыл кичү» колхозында авыл халкы белән очраша. Яңа 1942 ел алдыннан хәтта иҗат кичәсе дә үткәрә: кичәнең тулы бер бүлеге дәвамында мәдәният йорты сәхнәсеннән үз шигырьләрен укый, икенче бүлектә курсантларның җыр һәм бию ансамбле чыгыш ясый.

Җәлилнең Минзәләдә тагын бер, соңгы чыгышы булган, дип сөйлиләр. Ул политруклар курсын тәмамлау уңаеннан оештырылган тантаналы җыелышта була. Тантанада дөрес, әмма бик рәсми сүзләр күп яңгырый. Аннары сәхнәгә Җәлил чыга һәм, бөтен кешенең кәефен күтәреп, калага багышланган шигырен укый.

Хуш, Минзәлә, синдә кунак булдым
Бик аз гына, үтеп барышлый;
Шуңар күрә нәни шаярулы
Бу җырымны сиңа багышлыйм.

Исән калсын миннән урамнарың,
Урам баскан карың, бозларың.
Бер лейтенант күрсә, акылыннан
Шаша торган иркә кызларың.

Исән калсын кызылармеец күрсә,
Күкрәгенә кысып орчыгын,
Мышык-мышык кына елый торган
Бала җанлы карчык-корчыгың.

Исән калсын шаян малайларың,
Беләм, алар «сугыш» уйныйлар.
Усалрак этне «Бу – Гитлер» дип,
Чыбык белән тотып кыйныйлар.

Нишлисең бит, көяз кыз шикелле
Басып тора завод кырында.
Шулай булгач, ничек язмый түзим
Ак күбекле сыраң турында.

Исән калсын киноң, театрың,
Карт артистың – данлы Шункарың,
Тик, ахрысы, хәзер театрны
Аз уйный ул, каһәр сукканың!

Исән калсын шаулы базарларың
Һәм куырган тәмле симәнкәң.
Исән калсын сусыз-парсыз мунчаң,
Баскыч-баскыч коры эләүкәң.

Тик әйтегез, азрак бу клубны
Җылытсыннар иде киленнәр,
Юкса, моны «котып» диеп белеп,
Ак аюлар гына килерләр.

Беләм, кызлар, сезне куркытмыйдыр
Ирен өчен буяу юклыгы;
Беләм, беләм, сезне куркытадыр
Минзәләдә кияү кытлыгы!..

Чынлап әйтәм, кияү – «мөһим нәрсә».
Указ сезне мактап тормас бит!
Кияүгә дә чыкмый, бала тапмый
Йөрсәң, әйдә, түлә процент!

Ярый, дуслар, кызу көннәрдә дә
Шаяргалап шулай көлешик.
Сау булыгыз, Ватан сугышында
Җиңеп кайтып, исән күрешик!

Гаҗәп, эмма әлеге шаян һәм бер үк вакытта сагыш тулы шигырь юллары, күп кенә документ һәм истәлекләрне барысын бергә алгандагыга караганда да, сугыш чорындагы Минзәләне төгәлрәк һәм күләмлерәк күз алдына китерергә булыша.

СОҢГЫ ХАТ

1942 елның 1 гыйнварында Җәлил Минзәләдән китә. Ике атнадан соң ул шәһәр халкына аталган хатын юллый... Җитди һәм эчкерсез хат: «Минзәләдә булган аз гына вакыт эчендә мин, сезнең миңа күрсәткән игътибарыгыз һәм кайгыртучанлыгыгызны күреп, ватанны саклауга һәм әдәби эшемә чиксез дәрт үскәнне сиздем. ...Минзәлә халкының бу җанлы, кайгыртучанлык мөнәсәбәте минем күңелдә онытылмаслык матур эз калдырды. Мин бу кадер-хөрмәтегезне, фронтта булсын, әдәбиятта булсын, чын эш белән акларга сүз бирәм» һәм имзасын да куя: «Тагын бер кат рәхмәт һәм кайнар сәлам белән Муса Җәлил». Хатны ул 1942 елның 18 гыйнварында яза.

P.S. Минзәләдә Муса Җәлил музее 1970 елда ачыла. Аны булдыру инициаторларының берсе Мөхәммәт Гарифуллин – шагыйрьне кырык беренче елда элемтә бүлегендә очраткан кеше. Бу ил күләмендә беренче Җәлил музее була – Казандагы музей 13 елдан соң ачыла.



ШӘЕХГАТТАР ИМАНАЕВНЫҢ ХӘЯТЕ ҺӘМ ХОКУКЫ

Айдар Шәйхин

Аның эшчәнлеге гаять кызыклы: татарлар арасында беренче адвокатларның берсе, ислам хокукы турында фәнни хезмәтләр язучы, шул ук вакытта татар теле белеменә дә саллы өлеш кертергә өлгергән шәхес. Затлы нәсел вәкиленең язмышы да гади булмаган. Сүз юрист Шәехгаттар Иманаев турында.

ТИРСӘДӘН ИМАНАЕВЛАР

1875 елның 7 августында Тирсә авылында ахун Хәсән Ибраһим улы Иманаев гаиләсендә бала туа. Аңа атаклы шагыйрь Шәех Гаттарның исемен бирәләр. Иманаевлар нәселе башкорт-типтәрләр сословиесенә караган һәм ярлы гаилә саналмаган.

Аларның авылы ул елларда Вятка губернасының Алабуга өязенә караган, хәзер исә бу җирләр Әгерҗе районына керә. Биредә үзенчәлекле Әгерҗе феномены турында да әйтеп булыр иде. Бу төбәктән мәгърифәт ияләре Бубыйлар, Мөхетдин Корбангалиев, Таҗи Гыйззәтләр чыккан бит. Ә Шәехгаттарның Тирсәсе шагыйрь Чыңгыз Мусинның, сәясәтче һәм журналист Гасыйм Мансуровның да туган авылы. Морза Тәфкилевләргә бүләк ителгән авылларның берсе булганга, биредә шырпы, кирпеч, пыяла заводлары да ачыла, төрле һөнәр йортлары эшли. Мәдрәсәләре 1815 елда ук ачылган, 1882 елдан земствоның башлангыч

Фотолар автордан алынды

мәктәбе дә эшли башлаган. Үзенчәлекле архитектурага ия таш мәчетләре дә булган.

Хәсән ахунны 1878 елда үтерәләр. Өч яшьлек Шәехгаттарны туганы Казанга алдыра, ул шунда үсә. Казанда 1 нче гимназиядә дүрт ел, Уфа гимназиясендә өч ел уку бәхетенә ирешә. Гимназист статусы исә университетка да керергә мөмкинлек бирә. Чыннан да, ул 1897 елдан Казан Император университеты студенты булып, аны уңышлы гына тәмамлый. Укуын 250 сумлык Оренбург крае стипендиясе каплый. Бу – махсус булдырылган квота.

Шәехгаттар университетта бер үк вакытта юриспруденция юнәлешен дә, тарих-филология өлкәсен дә үзләштерә. Хәзерге вакытта аны ике диплом алган дип әйтерләр иде. Ахыр чиктә, гомере буена ул шушы ике белгечлекне берләштереп яшәячәк һәм хезмәт итәчәк. Тамагын туйдырганда юрист дипломы кирәк булса, күңелен күтәрергә тел белгече дәрәҗәсе булышкандыр, дип фаразлый алабыз.

Белем вә фән белән мавыгу буыннан буынга күчә барган. Шәехгаттар Иманаевның кызы Ракия 1924 елда туа. Гаиләгә берничә елдан таркала, 1931 елда әнисе кызын Томскига алып китә. Үсеп, университет тәмамлаган Ракия, соңрак Казанга кайтып, озак еллар буена университетның метеорология һәм климатология кафедрасында хезмәт куя.

ТАТАРНЫҢ ИКЕНЧЕ АДВОКАТЫ

1900 елда Иманаев, «II дәрәҗә хокук белгече» дипломын яклап, Казан суд палатасы округының присяжный поверенныйлар корпорациясенә кабул ителә. Ул башта адвокат ярдәмчесе сыйфатында хезмәт итәргә тиеш була. Казан университетының Юридик җәмгыяте әгъзасы да булып тора. Кайбер чыганакларда Шәехгаттарның мировой судья булуы да хәбәр ителә. Әмма бу мәгълүмат документлар нигезендә расланмый булса кирәк, чөнки шәхеснең язмышын өйрәнгән галимнәр моңа шикләнеп карый.

Патша Россиясендә присяжный поверенный – югары юридик белеме, мәхкәмәдә яки адвокат ярдәмчесе вазыйфасында 5 еллык хезмәт тәҗрибәсе булган һәм башка адвокатларның разыйлыгын алган белгеч. Бу вазыйфаны биләүчеләр арасында Шәехгаттар Иманаев икенче татар кешесе дип санала. Беренчесе, сүз уңаеннан, атаклы Сәетгәрәй Алкин була.

Иманаев Казан мәхкәмә округы судларында адвокат буларак еш катнашкан. Бу вазыйфаларны ул, өзеклекләр белән булса да, инкыйлабтан соң да биләвен дәвам иткән. 1928 елның декабрендә генә аны Татарстанның адвокатлар коллегиясеннән чыгаралар.

Татарстан Милли архивында Иманаев катнашында үткән мәхкәмә утырышларының беркетмәләре һәм төрле эшләр саклана. Адвокатлык – вазыйфа. Вазыйфадан чыгып, Иманаевка төрле кешеләрне якларга туры килгән. Мәсәлән, сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Сәйдәшевнең бер хатын белән хезмәт хакы мәсьәләсендә килеп чыккан низагында ул Сәйдәшевне яклаучы поверенный була. Шактый гына апелляцияләрдән соң, Иманаев судта җиңеп чыга. Хәер, бу урында мәсьәләнең әхлакый ягы турында әллә ни артык сүз дә куертасы килми.

Сәйдәшевләр белән Иманаевның мөнәсәбәтләре, чыннан да, бик җылы һәм тыгыз була. Шәехгаттар – Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләрнең тугры булышчысы, адвокаты, ышанычлы кешесе. Юкка гына Әхмәтҗан аны Дәүләт думасына ук уздырырга хыялланмагандыр.

Шәехгаттар әфәндегә хезмәттәшләре белән бәхәскә кергәләргә дә туры килгән. Ул шул ук Алкин белән ызгышып ала, шуның аркасында Присяжный поверенныйлар советы аны каты итеп кисәтергә мәҗбүр була. Иманаев тагын бер атаклы татар хокукчысы, адвокат ярдәмчесе Садри Максудины «Йолдыз» газетасы (нәшире - абыйсы Әхмәтһади Максуди) битләрендә үзен рекламалауда гаепли.

Бу мәсьәләне дисциплинар суд тикшерә һәм Садри Максуди гаепсез дип табыла.

Инкыйлабтан соң беренче елларда Иманаевның нияләр белән шөгыльләнүе билгеле түгел. Ул Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә мөселман университетын төзү мәсьәләсен караган булса кирәк, гомумән, уку-укыту мәсьәләләре белән мавыга. Шул елларда ук аның Казан университетында ислам хокукы буенча лекцияләр укырга теләгәне билгеле. Ә инде 1925 елда аңа рәсми рәвештә мәхкәмәләрдә адвокат буларак катнашырга рөхсәт бирәләр. Яңа хөкүмәтнең адвокатура системасы әле оешып кына килгән елларда, «иске режим»ның элеккеге присяжный поверенныйлары да ярап куйган, күрәсең. Ләкин өч ел үткәч, үз йортында яшәгән, университет тәмамлаган үзсүзле Шәехгаттар Иманаевны адвокат дәрәҗәсеннән мәхрүм итәләр.

БЕРЕНЧЕ ХОКУК ЖУРНАЛЫ

Шәехгаттарның матбугат белән бәйле эшчәнлеге «Бәянелхак» газетасы һәм «Хокук вә хәят» журналлары белән бәйле. Беренчесен туганнары Сәйдәшевләр чыгарса, икенчесе тулаем үзенең проекты була.

Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләрнең «Бәянелхак» газетасы Казанда 1906-1914 елларда даими чыгып килгән. 1913-1914 елларда нәшир һәм мөхәррир вазыйфасы Шәехгаттар Иманаевка йөкләнә. Бу вакытка «Бәянелхак»ның татар галәмендә үз исеме була инде. Чиктән тыш мактаулы һәм горур исем дип тә әйтеп булмый аны. Газета битләрендә дөнья күргән язмаларның берише консерватив һәм күпмедер дәрәҗәдә карагруһ фикерләрне алга сөргәнгәме, реклама күп басылгангамы, газетаның төп мәсләге тотрыклы булмагангамы, аны башка матбугат чаралары еш кына

Шәехгаттар Иманаев эшеннән фотосурәт, 1933 ел. Татарстан буенча ФИХ (ФСБ) идарәсе архивы.

көчле тәнкыйть утына тотканнар. Исмәгыйль Рәми «Вакытлы татар матбугаты альбомы»нда «газетаның бер санында 87 игълан булып, мәкалә һәм хәбәрләргә ике багана ярым урын гына бирелгән иде» дип яза. Анда язышучыларның составын да түбән бәяли: ачлыктан йөдәгән шәкертләр һәм йорт-җирсез йөргән мәхдүмнәр иде, ди. 1912 елның 19 декабрендә Шәехгаттарның үзенә «Хокук вә хәят» исемле яңа журнал чыгарырга рөхсәт бирелә.

Документта редакциянең адресы да күрсәтелгән. Эш шунда ки, чыганаклардан күренгәнчә, 1902 елда Шәехгаттар Фукс урамы, 31 адресында урнашкан иске агач йортны сатып ала да, су коммуникацияләре кертеп, яңа агач йорт төзи, бакча да үстереп җибәрә. Ә инде 1912 елгы мәгълүматларда аның Екатерининская урамында яшәве ачыклана. «Хокук вә хәят» тә Екатерининская урамының 71 нче йортында урнаша.

Журнал ике телдә чыга. Анда татарча да, русча да язмалар урын ала. Эчтәлеге буенча ул хокукый һәм гомуми темаларны берләштерергә тиеш булган. Хөкүмәт карарлары, хокукый сорауларга җаваплар, мәхкәмә хроникалары, халыкка юридик ярдәм күрсәтү, законнарны аңлату, әдәбият-сәнгать, яңалыклар һәм игъланнар бу журналда даими басылыр дип көтелгән.

Ниһаять, 1913 елның 20 гыйнварында журналның беренче саны дөнья күрә. Ул редакторның «Хокук вә хәят» дип исемләнгән кереш мәкаләсеннән башлана. Биредә ул татар-мөселман тормышының хокукый аспектлары турында сүз кузгата. Татарларның үзара мөнәсәбәтләре дә, башка халыклар белән эш кылулары да ике яссылыкта – Россия кануннары күзлегеннән дә, шәригать ягыннан да – каралуына игътибар итә. Димәк, татарлар ике төрле белемгә ия булырга тиеш. Шәригатьне китап ятлап түгел, ә аңлап һәм заманга яраклы рәвештә кулланып өйрәнергә кирәк, ә иң мөһиме – илдәге дөньяви кануннарны да исәпкә алып, ике якны дуслаштырырлык система булдырырга кирәк. Бу урында без Иманаевның 110 елга алдан күрүчәнлегенә сокланмый кала алмыйбыздыр. Соңгы елларда Россиядә, хәләл индустрия үсеше белән бергә, законнар системасында да шәригатьнең аерым өлкәләрен өйрәнү активлашты бит.

Иманаев мәкаләсе – татар телендә хокук системасының үзенә күрә бер манифесты. Ул, беренчедән, татарларны дәүләт теле булган рус телен өйрәнергә өндәсә, икенче яктан, мәхкәмәләрдә һичшиксез тәрҗемәчеләр катнашырга тиеш, ди.

Журналның башка саннарында үзе язган мәкаләләрдә (әйтергә кирәк, язмаларның шактыен ул үзе әзерләгән) ул татар җәмгыятендә шәригать һәм дөньяви канунның урыны турында фикерләвен дәвам итә. Бер үк вакытта аны тел мәсьәләсе дә кызыксындыра. Ул халык өчен язылган китапларда мөмкин кадәр гадирәк, «татарчарак» итеп язарга өнди. Җирле халыкның үз телендә чыгарылган китаплардан файда күбрәк булачак, ди. Ахыр чиктә, ул университетларда булачак юристларга ислам хокукы буенча дәресләр бирергә кирәк, ди. Бу хыялы да соңрак чынга ашачак, әлбәттә. Әмма үзенә Казан университетында шәригать белән таныштыру лекцияләрен укытырга насыйп булмый.

Иманаевның мөһим бер идеясе шуннан гыйбарәт: Россия мөселманнары өчен ике канун бар. Шәригать кагыйдәләре Россия кануннары системасы эченә керергә тиеш дип саный ул. Бу гаять каршылыклы фикергә кайбер галимнәр бик каршы чыга, чөнки алар монда дәүләт эчендә дәүләт төзелү куркынычын күрә.

Нинди якты хыяллар белән янса да, журнал очрагында да Иманаевның максатлары тулысынча чынга ашырылмый кала. 1913 елның 25 октябрендә журналның соңгы, тугызынчы саны дөнья күрә. Татар дөньясы беренче юридик журналның шулай тиз сүнүенә һич тә аптырамаган, күрәсең. Эчтәлегенең чуарлыгы да популярлык казанырга комачаулаган дип уйларга нигез бар. Мәсәлән, «Хокук вә хәят» турында татар матбугаты тарихчысы Исмәгыйль Рәмиев бер дә мактау сүзләре әйтми. «Ләкин монда хокукый мәсьәләләр бик аз урын алалар иде. Шәп нәрсә түгел иде. Язарлык, сөйләрлек тәэсире дә, кирәге дә булмады шикелле» – мондый бәя белән алга китеп булмый, әлбәттә. Шәрык белгече, Матбугат эшләре комитеты әгъзасы П. Жузе да журналның кимчелеген чуарлыкта күрә: «Басылып чыккан тугыз саныннан карап, аның йөзен ачыклау мөмкин түгел», – ди.

Әмма ничек кенә булмасын, «Хокук вә хәят», чыннан да, четерекле юриспруденция һәм хокук мәсьәләләренә багышланган беренче татар


Шайх-Аттар Иманаев.
Cheich-Attar Imanaief.

МУСУЛЬМАНСКИЙ ГРАЖДАНСКИЙ ЮРИДИЧЕСКИЙ СТРОЙ КАК ПРОДУКТ ОБЩЕСТВЕННОСТИ.
Das Civilrecht der Mohammedaner als Erzeugnis ihrer gesellschaftlichen Ordnung.

ЧАСТЬ ПЕРВАЯ.
Erster Theil.

(Очерк по методологии истории права).
(Beitrag zur Methodologie der Rechtsgeschichte).

КАЗАНЬ.
1926.

Шәехгаттар Иманаевның «Мусульманский гражданский юридический строй как продукт общественности» исемле китабы. Бу нөсхә Надежда Крупскаяга бүләк ителгән һәм аның китапханәсендә сакланган. Хәзерге вакытта «Горки Ленинские» музей-тыюлыгында саклана.

журналы. Бердәнбер дисәк дә ялгыш түгелдер, чөнки аның дәвамы буларак 1998 елда чыга башлаган «Право и жизнь - Хокук һәм хәят» журналы хокукчыларның тар даирәсе өчен генә нәшер ителә торган басма буларак билгеле.

ТАНЫЛМАГАН ГАЛИМ

1910 елда «Бәянелхак» газетасы типографиясендә «Татар теленең нәхүе вә сарыфы» исемле фәнни хезмәт басыла. Шәехгаттар Иманаев язган бу китап фонетика, морфология һәм синтаксиска багышланган. Аның яртысы диярлек чынлыкта татар фонетикасы мәсьәләләре турында. Бу ягы белән хезмәт шактый үзенчәлекле дип санала. Эш шунда ки, университетның тарих-филология факультетында да укып чыккан Иманаев, татар галимнәреннән беренче булып, авазларның барлыкка килүен, ясалуын һәм үзгәреш кичерүен физика законнарына һәм биологиягә бәйләп аңлата. Китабында ул һәр авазның ясалган урынын тасвирлый, телебездә 34 тартык һәм 9 сузык аваз барлыгын искәртә. Һәр авазның үз хәрефе булырга тиеш, дип әйтә.

Шактый алдынгы тезисларга бай хезмәт Шәехгаттар исән чакта татарлар тарафыннан берничек тә бәяләнми. 1921 елда гына рус галиме Николай Катанов Иманаевның филология өлкәсендә эшчәнлеген мактап искә алачак.

1920 нче еллар башында Иманаев Казан университеты мөгаллимнәре арасына кушылырга омтылыш ясый. Эш шунда ки, моңарчы университетның юридик факультетында ислам белән бәйле фәннәрне укыткан Пантелеймон Жузе Бакуга китә. Кайчандыр булачак юристларны шәригать белән таныштырырга хыялланган Шәехгаттар өчен бу зур форсат булып тоела. Ул комиссиягә гаризасын һәм хезмәтләрен тапшыра. «Мусульманский гражданский юридический строй как продукт общественности» исемле булачак зур хезмәтенең тезисларын бастыра. Имтиханнарын да тапшыра. Әмма комиссия, башка белгечләрнең дә фикерләренә колак салып, Иманаевны эшкә алудан баш тарта. Олыгайган юристның исламга артык якын булуы да, бик авыр холкы да тәэсир итми калмагандыр...

ТЫНГЫСЫЗЛЫК ФАҖИГАСЕ

1932 елның 21 декабрендә ОГПУ контрреволюцион буржуаз милләтчеләр оешмасы турында эш ача. Бер айдан соң бу эш буенча 109 гаепле кеше ачыклана. Шәехгаттар Иманаев та, Һади Максуди, Мостафа Бигаев, Мөхәммәд Мостафин, Рөстәм Алкин һәм башкалар белән бергә, кулга алына.

Иманаевның авыр холкы аркасында дошманнары шактый булгандыр. Бу беренче кулга алыну очрагында да шәхси дошманлыкның роле булмый калмагандыр. Аның йортында дүртенче фатирда яшәгән күршесе Иманаев өстеннән күрсәтмәләр бирергә ризалаша һәм, «ул төннәрен туганы Мостафин белән бергә язу машинасында листовкалар бастыра», дип хәбәр итә.

Сорау алулар барышында Иманаев үзенә ягылган гаепне дә танымый, башкаларны да сатмый. Ул үзен горур тота, тикшерүчеләргә үзенең галимлеген, Покровский һәм Крупскаялар белән танышлыгын искәртеп тора. Аның сәер җавапларыннан шикләнеп, психиатрия дәваханәсенә мөрәҗәгать итәләр. Аны сәламәт дип табалар, ә 1934 елда хөкем итәләр һәм 3 елга Себергә сөргенгә җибәрәләр.

1936 елның гыйнварында сөрген вакыты тәмамлана һәм Иманаев Казанга кайта. Менә шуннан соң аның гомерендә соңгы көрәш башлана да инде.

Кулга алынган кешеләрнең йорт-җирләре, кеше ирекккә чыккач, кире кайтарылырга тиеш була. Һәрхәлдә, Иманаев очрагында шундый карар кабул ителә. Ә ул исә кулга алынганчы Фукс урамының 31 нче йортында яши. Ирекккә чыгып, Казанга кайтканда, бу йорт тулысынча шәһәр кулына күчәргә өлгерә, ә андагы 111 квадрат метрда 47 кеше гомер итә. Аларның, әлбәттә, йорттан чыгып китәселәре килми.

Шәехгаттар, гыйлемле юрист буларак, үзенең йорт-җире өчен көрәшеп карый. Аңа алмашка башка бер фатирда бүлмә дә биреп карыйлар. Тиз арада аннан барыбер чыгаралар. Үз өеннән бирелгән почмактан ул берничек тә канәгать кала алмый: мич белән стена арасында, карават та куярлык урыны булмаган почмакта яшәргә һәм идәндә бөкләнеп йокларга тиеш була. Туктаусыз мөрәҗәгатьләр, судлар, ызгышлар дәвам итә.

Сөргеннән кайткач, ул 13 нче мәктәпкә эшкә урнаша, алман һәм рус теле укыта. Монда да конфликтсыз булмый. Укучыларны почмакка бастыру кебек «борынгы» методлар кулланган өчен дигән сәбәп белән, аны эштән җибәрәләр. Бу хакта да Иманаев судларга мөрәҗәгать итми калмый.

Кыскасы, олы яшьтәге галимнең тынгысызлыгы күпләрнең теңкәсенә тия. Ахыр чиктә, «советка каршы» эшчәнлеге өчен 1938 ел башында Иманаев тагын кулга алына. Тикшерү эше башлана. Әмма аны хөкем итәргә дә, атып үтерергә дә өлгермиләр. 1939 елның 8 гыйнварында ул төрмә хастаханәсендә үлә.

Иманаев – каршылыклы шәхес. Аның искиткеч прогрессив белән консерватив карашлары ничектер бергә сыеша алган. Замандашлары моңа уңай караган дип әйтә алмыйбыз. Шәехгаттар Иманаев исеме либерал һәм демократ татар фикер ияләре өчен карагруһчылар белән бер дәрәҗәдә торган. Әмма хезмәтләре безнең өчен барыбер кадерле һәм кыйммәтле. Язмышын да өйрәнеп, томанлы урыннарын ачыклап бетерәсе бар. Бәлки, аңа карата фикеребез дә үзгәреп куяр иде.

حقوق وحيات

«Хокук вә хәят» журналының 1913 елгы 1 нче саны.

ХӘТЕР ДӘҖҖАЛЫ, ЯКИ БЕЗ ОНЫТСАК, НӘРСӘ ҮЗГӘРӘЧӘК?

Луиза Янсуар

22 июнь – Россиядә Бөек Ватан сугышы башлануын искә алу көне. Бу көнне без яуда башын салган геройларны искә алабыз, ветераннарны барлыйбыз, хәтер яңартабыз. Әмма ул сугышның яралары әле һаман җөйләнмәгән: чәрдәкле язмышларның әрнүе буыннарда кабатлана, кисәтү дә, гыйбрәт тә булып яңгырый.

Фотолар: labirint.ru, bookmate.ru, livelib.ru, goodfon.ru сайтларыннан

НАДЯ АЛЕКСЕЕВА 1988 елда Мәскәү янындагы бистәләрнең берсендә туа. Г.В. Плеханов исемендәге Россия дәүләт сәүдә-икътисад университетын тәмамлый, белгечлеге – «Персонал белән идарә итү».

Драматургия һәм проза буенча осталыкка CWS курсларында өйрәнә. «Юность», «Дружба народов», «Новый мир» журналларында басыла. «Любимовка» Бәйсез драматургия конкурсында кыска исемлеккә керә, «Лицей» премиясенең финалчысы була.

«Полунощница» – авторның дөнья күргән тәүге романы. Ул быелгы «Большая премия» лонг-листына керде, шулай ук – МХТ, Фазыл Искәндәр исемендәге Халыкара әдәби премия, «Ясная Поляна» премияләренә дә номинациядә.

Хәзерге вакытта авторның «Белград» дип аталган икенче романы басмага әзерләнә.



КАҺАРМАНЛЫК БӘҺАСЕ

Надя Алексеева. «Полунощница»
Елена Шубина нәшрияты

Надя Алексеева Россия иҗади җирлеге өчен азмы-күпме билгеле автор булса да, киң катлам укучы өчен – ул әле яңа һәм ачылып кына килә торган прозаик. Һәм, әйтергә кирәк, беренче романы белән үк үзен шактый җитди һәм киң полотно тудырырга әзер язучы буларак күрсәткән иҗатчы.

Күпчелек рецензентлар ассызыклавынча һәм авторның үзе әйтүе буенча да, «Полунощница»ның төп каһарманы – Валаам. Әмма һәммәбезгә дә билгеле утрауның үзе түгел, аның белән бәйле язмышлар һәм Россиянең иң әрнеткеч тә, аяныч та тарихи сәхифәләренең берсе. Ә инде исеменә килгәндә, монда да ачыклык кертү зарур: бу әсәрдәге хатын-кыз геройларның берсенә ишарә түгел, «Полунощница» – таң беленер алдыннан тәмамлана торган чиркәү келәүе. «Минем каһарманнарым да караңгылыктан яктылыкка таба капшанып баралар, ә Яктылыкка әле ирешергә, лаек булырга кирәк», – ди автор үзе.

Надя Алексеевага «Ни өчен яшь язучы мондый темага алынды?» дигән сорауны һәр очрашу саен бирми калмыйлар, мөгаен. Ул гадәттә елмая һәм романның язылу тарихы турында кабат-кабат сөйли – гадәттә үзирония һәм ярымшаярулы тон белән. Бу аңлашыла да, чөнки тема – чыннан да җитди, алай гына да түгел, драматик һәм катлаулы. Якты көнгә ачылып җитмәгән архив катламнары, «ябык битләре» белән. Дөресен генә әйткәндә, әле кәгазь китапка һәм кулга каләм тотып язуга ияләшеп үскән безнең буыннан соң килгән яңаларга бу сәхифәләр – бөтенләй сәердер. Һәрхәлдә, алар Бөек Ватан сугышының мондый «ак таплары» да барлыгы турында уйланмый, хәтта башына да китереп карамый. Безнең буын да хәзер инде Гугл йә Алиса аша гына мәгълүмат табуга күнегеп бара. Ә монда – Ладога сулары астында күмелеп калган язмышлар архипелагы, микротәкъдирләр чылбыры...

Зәгыйфь чыршыларны узып, суның зәңгәрләнеп торган көзгесенә әсәренеп, Павел урманга юл тотты. Юлы – утрауның изге карты хозурына. Кошлар язны тантана итеп гөр килеп сайрый. Ул, тагын да дәртләнеп, тизрәк атлады.

Тәрәзәсе аркылыга такта белән кадаклап ябып куелган ызба каршында егермеләп кеше көтеп тора. Кемдер эскәмиягә төртелгән, кайсылары – аягүрә. Әбиләр авыз эченнән генә сузып дога укый. «Карт янына кайсыгыз иң соңгы?» – ди сорады Павел. Әбиләр аңа шелтәле караш ташлады да догасын дәвам итте. Шулай да берсе, башкалардан аерылып, Павел янына килде һәм пышылдады: ул кемне кабул итәсен үзе әйтә һәм үзе чакырып та ала.

Кинәт чират кузгалып, дулкынланып куйды – карт ызбасыннан чиркәү башлыгы чыкты. Әбиләр шунда ук аңа ташланды, фатихасын кабул итәргә ашыкты. Чиркәү башлыгы чиратта утырган Машага күз сирпеде: бар, янәсе, синең чират. Павелга карады да кистереп:

– Власий атакай сезне бүген кабул итмәячәк, – диде.

– Нишләп? Мин күпме кушсалар, шулкадәр көтәргә әзер.

– Барыбер кабул итмәячәк.

– Туктагыз әле! Нишләп?! Мин нәрсә эшләдем кабул итмәслек?!

Чиркәү башлыгы Павелга борылып карады. Күзлеге яшереп торган күзләре арыган һәм моңсу иде аның.

– Җаныгызга күз салыгыз.

Һәм менә шул «җаныгызга күз салыгыз» әсәрнең буеннан-буена төп лейтмотив булып сузылып бара. Монда гасырлар, вакытлар бутала, үткәндәге кылганнар бүгенге язмышларны хәл итә, гөнаһлар да, алар өчен түләү дә җирдә үк үз көчен күрсәтә. Һәр кечкенә генә кешенең кечкенә генә бер гамәле дә тулы бер ил, дәүләт, империяләр тарихын үзгәртергә сәләтле икәнлеге ваемлана.

Әбисенең васыятен истә тотып, аның Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган энекәше эзләреннән килгән Павелга кат-кат кабатлыйлар – «Валаамга очраклы килмиләр, монда нидер дәшеп китерә». Һәм ул чынлап та үзенең җитеш Мәскәү тормышын, абруйлы һәм яхшы акчалар китерә торган эшен, дусты белән бергәләп ачарга торган яңа бизнесын ташлап чыгып китүенең төп сәбәбе инде айлар буе колагына төштә дә, өндә дә кереп йөдәткән чаң авазы булуын абайлап ала. Һәм менә волонтёрлар белән килеп эләккән утрауда ул әле үз җанына туры караганчы, аның аша кешеләр һәм аларның үзәк өзгеч тарихлары уза башлый. Әсәрнең каһарманнары арасында бер өлеше – Валаамдагы Инвалидлар йорты кешеләре. Карел-Фин ССРның Югары советы указы буенча 1950 елда утрауда Инвалидлар йорты ачыла. Анда китерелгән 904 кешенең күбесенең, сугыштан аяксыз-кулсыз кайтканнарның, йөрерлек мөмкинлекләре булмый. Эшли алганнарны эшкә билгелиләр. Әмма биредә сугышта катнашканнардан тыш, бөтен Советлар Союзыннан җыеп китерелгән ялгыз инвалидлар, хәер сорашып йөрүчеләр, криминал элементлар да җитәрлек була.

Бүгенге көндә әлеге инвалид-ветераннарның исемнәрен барлау һәм кайтару әле һаман да дәвам итә, чөнки алар турындагы документларның күпчелеге юкка чыккан. Инвалидлар йортының коточкыч язмышын яктырткан чыганакларның берсе – Петербург тарихчысы, сәнгать фәннәре кандидаты Евгений Кузнецовның «Валаам дәфтәре». Ул биредә 40 ел дәвамында экскурсовод булып эшләгән.

«Валаам материаллары» дигән папкамда өч романлык материал бар», – ди Надя Алексеева. XX йөз Россия тарихының фаҗигале яшерен битләре. Без бу хакта кычкырып сөйләмибез. Чөнки бу – каһарманлык кына түгел, ә урыны-урыны белән сискәнерлек, урыны-урыны белән чирканырлык, һичшиксез, тәүбәгә китерергә тиешле сагышлы үткәнебез дә. Әмма без онытуны, кайбер сәхифәләрне томалап куюны яки югалтуны кулайрак күрәбез шул. Хәер, онытмасак, нәрсә булыр иде?



ИШАЙ САРИД 1965 елда Тель-Авивта күренекле журналист һәм сәясәтче Йосси Сарид гаиләсендә туа. Белгечлеге буенча – юрист. Тель-Авив прокуроры ярдәмчесе булып эшли, адвокат буларак хосусый практика алып бара, хәзерге көндә үз адвокатлык бюросында хезмәт итә.

ЦАХАЛ офицерлар мәктәбен тәмамлый һәм разведка офицеры буларак хезмәт уза. Гарвардның Кеннеди университетында Дәүләт белән идарә итү Югары мәктәбендә белем ала, магистр дәрәҗәсенә ия.

Юрисипруденциядән тыш, актив рәвештә язучылык белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта 7 роман авторы. Икенче китабы «Лимассол» – дөньякүләм танылган бестселлер, «Третий» әсәре Израильдә шактый зур резонанс тудыра, Бернштейн әдәби премиясенә лаек дип табыла. «Монстр памяти» – аның бишенче әсәре, ул New York Times ның «Иң яхшы 100 китап» исемлегенә кергән роман.

ТАРИХ ТАРИХ КЫНАМЫ?

Ишай Сарид. «Монстр памяти»
«Синдбад» нәшрияты

Холокост – кешелек тарихындагы иң олы фаҗигаләрнең берсе, шулай ук соңгы дистә елларда күпсанлы әсәрләр өчен сюжет та.

Бу китапны Ишай Саридның язучылык карьерасындагы иң провокацион роман, дип табучылар да бар. Чөнки биредә – Холокостка карата башка төрле караш. Язучы, асылда, үз тарихына, милләтенә бик тә куркыныч хакыйкатьне ачып бирергә, күрсәтергә омтыла – әйе, ди ул, фаҗига турында белергә кирәк, аны сөйләргә, күрсәтергә кирәк, ул безне тагын да ныграк берләштерә... Әмма, шул ук вакытта, «дөньяга һәм башка халыкларга карата нәфрәткә дә өйрәтмиме?» Әгәр шулай икән,

«ҮТЕРҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ҮТЕРЕЛГӘННӘР АРАСЫНДА ЧИК БУЛЫРГА ТИЕШ»

Ишай Сарид

нәфрәт чикләрне җимереп чыкса, аны кем контрольгә алыр?

Һәр елны Израиль мәктәпләрендәге укучылар үлем лагерьларын күрер өчен Польшага тур белән бара – бу инде күп елларга сузылган практика. Аларны билгеле бер маршрут буенча йөртәләр: Освенцим, Майданек, Треблинка, Собибор. Аклы-зәңгәрле Израиль әләменә төренеп, үсмер кызлар белән малайлар лагерь капкалары фонында фотога төшә, Израиль гимнын җырлый, ул фотолар белән видеоларны үзләренең социаль челтәрләренә урнаштыра. Югыйсә, нәрсәсе куркыныч моның ? Менә бу урында үзе мондый төр экскурсияләрнең катнашучысы да, экскурсоводы да булып караган Ишай Сарид, тәҗрибәсенә нигезләнеп, чаң кага: ә сез беләсезме ул балаларның үзаңында нәрсә формалашканын? Нинди сүзләр һәм эндәшләр белән элә алар үз аккаунтларында фото белән видеоларын? Кайберләре ачыктан-ачык: «Көчне көч кенә җиңә ала», «Көчкә каршы көч кулланырга кирәк, туганнар» дигән өндәүләр сырлый. Асылда, ул Хәтер белән өлкәннәр уйнаган уеннарның тискәре нәтиҗәгә китерергә мөмкин булуына басым ясый һәм безне дә сискәндерергә тели.

Кичен без балалар белән йомгаклау әңгәмәсенә җыелдык.

– Бу сәяхәттән һәркем үзенә нинди дә булса тәэсир, сабак алгандыр, йә, кем –ниндине?

Дөресен генә әйткәндә, мин үзем бу сорауны куралмыйм. Әмма, аларны ничә көн буена үлем лагерьлары буйлап йөрткәннән соң, аны бирү – минем бурычым.

– Көчле булырга кирәк, – дип куйды берсе.

–...көчле яһүдләр, диген,

–...намуслы, әмма көчле,

– ...берләшкән.

– Онытырга ярамый.

– Кеше булып калырга кирәк.

Шулчак читтә генә утырган бер яшүсмер күтәрелә. Озын буйлы, күзлектән. Мускуллы, күренеп тора – шөгыльләнә.

– Безгә исән калыр өчен үзебезгә дә күпмедер күләмдә нацист булырга кирәк – мин шулай уйлыйм.

Бу аларны алып килгән укытучы белән директорны шок халәтенә китерә.

– Ни әйтергә телисең бу сүзләр белән? – дип сорарга мәҗбүрмен мин.

– Кызганмыйча үтерергә кирәк. Әгәр без артык йомшак булсак һәм нечкәреп торсак, шансларыбыз юк.

– Әмма син бит гаепсезләрне үтерергә өндәмисеңдер? – дип сүзгә кушылырга ашыга директор.

Малай берара уйланып тора. Аннары җавап бирә:

– Кайчак сайларга чара булмый, гражданнарга да зыян килергә мөмкин. Бу – яшәү өчен көрәш: йә без, йә алар. Без үзебезне харап итүләренә бүтән юл куймаячакбыз.

– Нигә нәкъ менә нацистлар кебек булырга кирәк, дисең? Нигә американнар, руслар, инглизләр түгел? Ахыр чиктә, сугышта нәкъ менә соңгылары җиңә бит.

Малай тагын уйланып тора. Аннан җавап бирә:

– Чөнки нацистлар соңгы чиккә кадәр барган һәм аны да узганнар.

Залда тынлык урнаша. Мин башымны иям дә шулай басып торам – безнең барыбызны да тәүбәгә китерер һәм коткарыр өчен кирәк бу бер минут тынлык.



1983 елда Ишай Сарид үзе дә нәкъ шундый мәктәп укучыларының берсе була. 2016 елда ул Освенцимга «Монстр памяти» китабын язарга материал туплар өчен әйләнеп кайта. Әсәр өчен аңа үзенә бик күп әр-битәр күтәрергә туры килә. Әмма Сарид бу әсәрен безнең гамәлләребезгә анализ ясарга чакыру дип исәпли. Нәрсә эшлибез без Хәтер белән? Әлбәттә, Холокост турында белү һәм аны күреп кайту кирәк, ди ул. Әмма тарихны үтә фрагментар белгән үсмерләргә бары тик экскурсовод сөйләгәннәр белән генә япа-ялгыз калу ярамый, дигән кискен карашта тора язучы.

Мин Освенцимга әлеккәндә 18 яшьлек артыгын уйланмыйча торган идиот идем, сәяхәттән тулаем тетрәнеп кайттым. Балалар бу экскурсияләр вакытында өлкәннәрнең манипуляция объектына әверелә. Алар тирән травма ала, әмма бу травма белән нәрсә эшләргә белми. Без аларны чын явызлык булган урынга китереп, җәрәхәтләп, явызлыкка, үч кайтарырга өндибез түгелме?

Ишай Сарид

Әмма иң әһәмиятлесе бу түгел, ә тарихны чалыш көзгеләр аша күрсәтү, дип уйлый Сарид. Нацизмның төп чыганагы һәм тамырлары бит Польшада түгел, ә Германиядә. Польша һәм башка дәүләтләр – шундый ук корбаннар, җитмәсә, фашизмга хезмәт итәргә мәҗбүр булган кешеләр белән тулы, аларның җимерелгән язмышлары белән бәйле урын. Без яулап алынган һәм тез чүктерелгән илләрнең, халыкларның хокуксызлыгы һәм аяныч тәкъдире турында да сөйләргә тиешбез. Бүген нәрсә үзгәрде, бу сорауга да җавап табарга, ди ул. Цивилизацияле һәм югары культуралы Германиягә ялга йөрүче ватандашларының күзаллавы буенча, барлык бәлаләр һәм явызлыкның чыганагы – Польша, башка кече дәүләтләр. Кече генә дә түгел, ә фәкыйрьрәк, зәгыйфьрәк, хокуксызрак...

«Кем көчлерәк, шул хаклы – әнә шул девизга өйрәтәбез түгелме без бүгенге XXI гасыр балаларын, ә алар көннәрдән бер көнне тагын көчсезрәкләргә кизәнсә?» – ди Ишай Сарид.



ОЛЫ САЛТЫК: ХАЛЫК МАЛ АСРАП КӨН КҮРӘ

ОЛЫ САЛТЫК

Май кояшы Казаннан ук безгә иярде. Юл буе уйнаклап, әле бер яктан, әле икенче яктан иркәләп барды ул. Табигатьнең уянган мәле: Җир-анабыз яшькелт күлмәген инде кигән, тиздән, бик тиздән аллы-гөлле төсләргә дә күмеләчәк. Җиһанда яз, без зарыгып көткән ямьле яз...

Кама Тамагы районының Олы Салтык авылына барып кергәч, табигатькә генә түгел, кешеләр тормышына да яз килүен күрдек. Бар халык бакчада, ә кайбер йорт каршына мендәр-юрганнар чыгарып тезгәннәр, тәрәзәдә челтәрләр дә күренми. Әйе, өй юалар. Бу да яз көне татар авылларында башкарыла торган төп эшләрнең берсе.

Руфия Фазылова



Фото: Лилиана Вәлитова

«КАПКАНЫ БИКЛӘП НАМАЗ УКЫЙЛАР ИДЕ»

Исеменнән аңлашылганча, Олы Салтык – зур авыл. XX йөз башында 500 гә якын хуҗалык булган, 1500 кеше яшәгән. Ачлык еллары, Бөек Ватан сугышы – барысы да халык саны кимүгә китергән. Бүген исә 90 хуҗалык бар, 262 кеше яши.

Иң беренче авылның имамы, алай гына да түгел, Кама Тамагы районының имам-мөхтәсибе Галимулла хәзрәт Яруллин янына туктадык. Хәзрәтне күптән беләм, дин белән

1
Галимулла хәзрәт Яруллинның авылда да, районда да абруе зур.

2
Кайчандыр гөрләп торган бинада бүген нибары биш бала тавышы ишетелә.

3
– Балалар башлаган эш бу, – диде Рәшит Талипов.

бергә дөньялыкны алып бара торган, тормышчан вәгазьләр сөйли торган акыллы кеше ул. 2000 нче еллар башында «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсәне тәмамлаган. Авылда да, районда да абруе зур.

– Әле тракторым янында мәш килә идем, – дип елмаеп сәламләде хәзрәт. – 2020 елда үзебезнең пай җирләрен алдым. 12 гектар ул, анда печән чәчелгән. Шунда ашлама кертәсе була. Кыр эшләре башланды, техникасыз булмый хәзер.

Галимулла хәзрәткә дини тәрбияне әбибабасы сеңдергән. Һәм ул бүгенгәчә аларга рәхмәтле.

– Әти миңа сигез яшь чагында мәрхүм булган, – диде Галимулла абый. – Шуның өчен дә күбрәк әнинең әти-әнисе янына – күрше урамга йөри идем. Алар миңа бер шакмак шикәр бирә, аның белән тәмләп чәй эчәбез. Шуннан бабай догалар өйрәтә... Совет чорында әдәү эти белән дәү әни капка бикләп намаз укыды. Аны инде кешегә сөйләп йөрмим, чөнки өлкәннәр әйтмәскә куша иде.

Галимулла хәзрәт хәләл җефете белән бер ул, бер кыз тәрбияләп үстергән. Балалары шәһәрдә яши. Ир белән хатын күп итеп мал асрый: хуҗалыкта ун башка якын мөгезле эре терлек, утыз баштан артык сарык бар.

Аптырыйсы юк: Олы Салтыкта һәр йортта диярлек берничә сыер. Өч көтү чыга. Дүрт йөздән артык савым сыеры бар. Әле баш санын һаман арттыралар икән.

– Бүген дә бер гаилә нәселле сыерлар алырга китте, – диде Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы Рамил Вафин. – ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан булдырылган программа эшли бит. Дәүләт сигез баш сыер алу өчен 400 мең сум акча бирә. Аның бер шарты бар: биш ел эчендә сыер саны кимемәскә тиеш. Инде бу программада өч кеше катнашты. Тагын теләк белдерүчеләр бар. Бездә халык мал асрап көн күрә.

– Авылда яшьләр күпме әллә? – дим авыл җирлеге башлыгына.

– Алай димәс идем, урта яшьтәгеләр, пенсионерлар – барысы да терлек асрый.

– Игенне, печәнне сатып алалармы?

– Әйе. Арада берничә гаилә үзләренең пай җирләрен эшкәртә. Тагын бер фермер бар, аның мөгезле эре терлек саны йөздән артык.

БАЛАЛАР БАКЧАСЫ – АВЫЛ КҮРКЕ

Олы Салтыкның тарихы белән танышабыз: биредә беренче агач мәчет 1856 елда төзелгән. XX йөз башында авылда мәктәп, 6 җил тегермәне, тимерче алачыгы, йонтукыма ману бинасы, 4 кибет эшләгән. Олы Салтык 1920 елга кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостена кергән. 1920 елдан – Тәтеш, 1927 елдан Буа кантонына караган. 1930 елның 10 августыннан – Кама Тамагы, 1963 елның 1 февраленнән – Тәтеш, 1965 елның 12 гыйнварыннан яңадан Кама Тамагына әйләнеп кайткан.

Ни кызганыч, шундый чал тарихлы авылда мәктәп ябылган. 2006 елда төзелгән ике катлы белем үзәген бүген авыл җирлеге идарәсе, китапханә, ФАП иткәннәр. Ә бер ягында балалар бакчасы. Дөрес, әле төп белем бирү мәктәбе чагында да аның бер ягы балалар бакчасы булган. Кайчандыр гөрләп торган бинада бүген нибары биш бала тавышы ишетелә.

– Шулай булса да бик тырышып эшлибез, катнашмаган конкурсыбыз юк, җиңүләребез дә күп, – диде Олы Салтык балалар бакчасы мөдире Эльмира Гыйзетдинова. – Ата-аналар белән бик актив эшлибез. Әле менә бакча эшләрен башлап җибәрдек. Җәен монда бөтен җир шау чәчәктә утыра.

2

Балалар бакчасы гына түгел, Олы Салтыкта барлык йорт-җирләр дә чәчәктә утыра. Талиповлар бәрәңге бакчасында хәтта туя, артышлар (!) үстерә. Өч-дүрт ел элек кечкенә үсентеләрне утыртканнар, бүген инде алар агач-куак булып җитешкән.

– Балалар башлаган эш бу, – диде Рәшит Талипов. – Бакча башында гына инеш ага, шуннан су сиптерәбез. Әлбәттә, моның кадәр агач, куакны матурлык өчен утыртмадык, сату өчен үстерәбез. Инде күпләп алып китүчеләр бар.

– Безнең яклар өчен ят үсемлекләр, тәрбияли беләсезме? – дим Рәшит абыйга.

3

4
Олы Салтыкта шуңа игътибар иттек: авылда урам саен диярлек кое бар, чишмәләр дә шактый икән.

– Тәрбия дип, агачлар арасындагы чүпне утыйбыз, су сиптерәбез. Әйтмәгәнем булсын, яхшы үсәләр, безнең туфрак килеште, ахры.

Рәшит абый җәмәгате Рәхилә апа белән бүген икәү генә яши, балалары шәһәрдә. Икесе дә лаеклы ялда, әмма һич тә картаерга теләмиләр. Күп итеп мал, кош-корт асрыйлар.

Олы Салтыкта шуңа игътибар иттек: авылда урам саен диярлек кое бар, чишмәләр дә шактый икән. Иң кызыгы – халык элеккечә чиләкләп су ташый. Юк, юк, һәр йортка су кергән, тик ул эчәргә каты, кайнаткач күп юшкын калдыра, диләр. Шуның өчен дә халык тәмле суга чишмә йә коега йөри.

ҖИТМЕШ ТӨРЛЕ ҺӨНӘР ДӘ АЗ...

Балалар бакчасында апалы-сеңелле Әминә, Әдилә исемле кызлар белән танышкан идек, шундый тәртиплеләр. Мондый балаларның әти-әнисен дә күрәсе килде. Гөлсирин һәм Айнур Сафиннар җиде ел элек гаилә корган. Айнур райондагы янгын сүндерү бүлегендә – машина йөртүче, ә Гөлсирин авылдагы «Август» оешмасында лаборант булып эшли икән. Әйткәнемчә, курчак кебек ике кызлары бар. Чын авыл кешеләре: күп итеп мал-туар асрыйлар, яңа каралты салып куйганнар.

– Үзебезнең пай җирләрен алып, шуны эшкәртәбез, – диде Айнур. – Тракторым бар, фермерлык эшендә техникасыз булмый. Әле умарталар да тотабыз, бабай безнең умартачы иде. Хәзер аның шөгылен мин дәвам итәм.

– Кортларыгыз ничә оя? – дим.

– Кайчандыр утыздан артык иде, быелгы язга уннан артык оя гына калды. Безнең якта кортлар бик үлә. Узган ел күрше авыл егетенең 70 оя корты үлде. Кырларны агулыйлар, ашлыйлар бит. Менә нәтиҗәсе...

Айнур әле күрше Яңа Сала авылы мәчетендә имам булып та тора. Дөрес, анда көн саен бармый, шулай да Аллаһ йортындагы бөтен эшләрне барлап, тиешенчә үтәргә тырыша.

5
Гөлсирин һәм Айнур Сафиннар җиде ел элек гаилә корган. Ике кыз үстерәләр.

– Минем Сафа бабам тирә-якка атаклы мулла булган, – дип дәвам итте Айнур. – Дингә тартылуым шуннан киләдер. Апас аграр көллиятендә укыганда иптәш егет белән намаз укый башладык, мәчеткә йөрдек. Әлегә дини белемем юк, ләкин андый ният, теләк бар. Районыбызның имам-мөхтәсибе Галимулла хәзрәт белән якыннан аралашабыз, җир эшләрен дә бергә башкарабыз. Сөйләшүебез гел дин тирәсендә була, аңардан күп нәрсәгә өйрәнәм.

Гөлсирин исә Кукмара кызы, югары белеме бар. Елмаеп кына сөйләшә. Айнур кебек үк намазда. Ир белән хатынның бер-берсенә булган җылы мөнәсәбәтен күреп чын күңелдән сокландык.

– Кукмара кызы Кама Тамагына ничек килеп чыкты, кайда таныштыгыз? – дидем Гөлсирингә.

– Казанда бер дини кибеттә сатучы булып эшли идем, Айнур шунда кәләпүш алырга керде. Сөйләшеп киттек, телефонымны сорады. Бер ел шулай аралашып торганнан соң өйләнештек. Айнурның Олы Салтыкта яшәгәнен белә идем, авыл тормышы куркытмады. Үзем дә авыл баласы бит.

Сафиннарның хыялы – зур фермер булу. Бер карасаң, моның өчен киртә дә юк кебек: бүгеннән үк тугыз сыерлары бар. Тик дәүләттән грант алып эшне киңәйтү

өчен мөмкинлекләр юк икән. Эш шунда ки, Сафиннар йортыннан ерак түгел иске парк җире бар. Айнурның теләге – шул җирне арендага алу.

– Аның өчен башта аны межаларга кирәк. Ике елдан бирле документларның очы-кырыена чыга торган түгел, – диде Айнур.

КИЛЕН-КАЕНАНАЛЫ ЙОРТ

Авылның тагын бер күркәм гаиләсе белән таныштык. Гайнетдиновлар бер йортта дүрт буын, җиде кеше гомер итә. Иң өлкәне – 91 яшендәге Мәһирә апа, аның лаеклы ялдагы улы Рамил абый, килене Дания апа, аларның уллары Равил, җәмәгате Алсинә һәм кечкенә Раяз белән Кәрим. Бер гаиләдә өч хезмәт ветераны! Бу нигездә гомергә күп итеп мал асраганнар, хәзер дә шулай.

Кызганыч, Мәһирә апа белән танышып булмады, Казанга, кызына киткән чагы булды. Каенанасы турында Дания апа сөйләде:

– Безнең нигездә гомергә килен-каенана бергә яшәгән. Әнкәй килен булып килгәндә, аның ике каенанасы, бер каенатасы булган. Мин дә ике каенана, каената белән яшәдем. Иң кызыгы: Алсинәгә дә шулай туры килде. Әйтәм бит, нигезе шундый...

– Болай бергә тату яшәүнең сере нидә? – дим Дания апага.

– Үпкәләмәскә, ачу сакламаска кирәк. Әгәр сүз күтәрмәсәң, әллә ничә буын бергә яши алмас идек. Хатын-кыз сабыр булырга тиеш.

Дания апа үзе дә Олы Салтыкта туып-үскән, Алсинә дә шушы авыл кызы. Заманында хәтта бергә сыер да сауганнар. Икесе дә алдынгы сыер савучы исеменә лаек булган уңган ханымнар.

– Шәһәргә китүдән ничек тыелып калдыгыз? – дидем яшьләргә.

– Ә мине шәһәр беркайчан кызыктырмады, – дип сүзгә кушылды Равил. – Югыйсә Казанда белем алдым. Авылда да, шәһәрдә дә эшләргә кирәк. Мин беренчесен сайладым, гомер буе ипотека түләп ятканчы...

Равилнең кулыннан килмәгән эше юк – техника белән дус, балта эшен белә, авылдашлары аны мал табибы буларак та чакыра. Кыскасы, авыл тормышына бәйле барлык эш-шөгыльне дә белә. Әле бүтәннәргә дә ярдәм итә. Үзләренең пай җирләрен алган, тракторы бар, гел эштә ул. Алсинә исә, авылда ферма бетерелгәннән соң, Олы Салтык балалар бакчасына идән юарга кергән.

– Мин хәтта декрет ялын да тутырмыйча эшкә чыктым, – диде Алсинә. – Эшемне яратудан гына да түгел, кеше сүзен аяк астына салып таптый алмыйм. Ул чакта сыер саварга

7 Гайнетдиновлар бер йортта дүрт буын, җиде кеше гомер итә.

кеше калмагач чакырдылар да, ризалаштым. Рәхмәт яусын әти белән әнигә, әбигә, балалар күбрәк алар тәрбиясендә булды. Хәзер дә шулай. Без Равил белән эшкә чыгып китәбез, балалар өйдә кала.

Гайнетдиновлар күп итеп терлек-туар, әллә ничә дистә баш кош-корт асрый. Монда кечкенә малайларга да эш бүленгән: бозаулар ашату, кош-кортларны карау...

Бервакыт Дания апа, кан басымы күтәрелеп, хастаханәдә яткан. Ун көн тик яту аның өчен сынауга әйләнгән. Әле һаман шуны искә алып сөйли:

– Хастаханәдә эшсез ятып интектем. Мин әйтәм, әллә торып идән юыйммы икән? Шәфкать туташларын да аптыратып бетердем. «Маллар арасында йөрсәм, әллә кайчан терелә идем», – дидем. «Апа, дәва курсын алып бетер инде. Тыныч кына ят, яшең бара, үзеңне карарга кирәк», – диделәр. Шуңа гына түзеп яттым. Гаҗәп менә – маллар янына чыккач бөтен авыруларым, авыруларым бетә. Гомер буе терлекләр янында булгангадыр инде. Мин генә түгел, бабай да шулай дип әйтә.

Чынлап та, нинди генә темага сөйләшә башласаң да, сүзебез эш, малларга барып тоташа. Үз эшенә бирелгән кешеләрне фанат диләр, бу очракта Гайнетдиновларга бик туры килә ул.

...Олы Салтыкта халык бик тырыш. Моны чамалау өчен ерак барырга кирәкми – уздырыштан мал асрыйлар. Алтмыш биштә дүрт-биш сыер асрау биредә гадәти хәл. Моның өчен сөендек. Тик менә яшь Сафиннар гаиләсе өчен күңелдә төер калды. Һич беркемгә зарланмыйча, хәләл көчләре белән тормыш итәргә, фермер булырга хыялланалар. Ә мөмкинлек юк. Югыйсә иң беренче булып шундый яшь гаиләләрне кайгыртырга кирәк бит! Бу мәсьәлә буенча Кама Тамагы районының авыл хуҗалыгы идарәсенә чыктык. Хәл уңай якка хәл ителер дип ышандырдылар. Көтеп карыйк. Безгә дә тагын бер кат Олы Салтыкка барып, Сафиннарның фермер булып эшләүләрен күрергә язсын.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

–Чукындырылудан качып, безнең бабайлар XVII йөз азагында Атабай (хәзерге Лаеш районы) ягыннан монда күченеп килгән дигән фараз бар. Алар ике туган булган. Башта Кече Салтыкка килеп урнашканнар. Тик соңрак олырагы әлеге урынга төпләнгән. Монда урманнар була, аны кисеп, өй салып, җирне эшкәрткәннәр.

Бу дөреслеккә дә туры килә дип уйлыйм, чөнки иске каберлекләрне карап йөргәнем бар, борынгы язулар күренми. Ә менә ерак булмаган Казиле авылында Болгар чорына караган кабер ташлары таптылар. Монда Тәтеш районының Әтрәч авылы да ерак түгел, анда да Әтрәч шәһәрлеге булган. Ә безнең җирлектә ул чорда кеше яшәмәгән дип уйлыйбыз.

Авылның исеме бирегә беренче килгән кеше хөрмәтенә кушылган дип карала.

Галимулла Яруллин, Олы Салтык авылы имамы.

МАКСАТ БЕР – ИЛНЕҢ ТЕХНОЛОГИК СУВЕРЕНИТЕТЫ

Рәүзил Хаҗиевне һич арттырусыз иң югары дәрәҗәдәге топ-менеджер дип атап була. Әлеге абруйлы шәхеснең хезмәт биографиясендә лаеклы сәхифәләр байтак, алар аның һөнәрмәндлегенә, колачлы фикерләү сәләтенә, идарә итә белү талантына, актив тормыш позициясенә ышанычлы дәлил булып тора. Рәүзил Мәгъсүмҗан улы үзенә ышанып тапшырылган барлык бик җаваплы вазыйфаларда – дәүләт хезмәтендә булсынмы ул, Татарстан парламентында, энергетика тармагында яки башка өлкәдә хезмәт куйгандамы – үзенең иң яхшы сыйфатларын тулысынча эшкә җигә.

Эдвард Абдуллаҗанов,
КДЭУ ректоры, ТР Дәүләт Советы депутаты

Рәүзил Хаҗиев инде ун елдан артык Татарстан Республикасының иң алдынгы компаниясен җитәкли. «Татэнерго» АҖ аның җитәкчелегендә актив үсә һәм лаеклы рәвештә Россиядәге энергия җитештерә торган иң зур предприятиеләрдән берсе статусын йөртә.

Күп еллар дәвамында тупланган тәҗрибәсе, идарә итә белү таланты, аналитик акылы һәм стратегик фикерләү осталыгы Рәүзил Мәгъсүмҗан улына энергетика тармагындагы актуаль проблемаларны нәтиҗәле хәл итү мөмкинлеген бирә. Казан дәүләт энергетика университеты исә һәрвакыт «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең ышанычлы партнеры булган һәм хәзер дә шундый булып кала.

Моннан тыш, Рәүзил Хаҗиев белән мине эшлекле генә түгел, дустанә мөнәсәбәтләр дә бәйли, һәм бу безнең университет белән «Татэнерго» компаниясенә тагын да нәтиҗәлерәк хезмәттәшлек итәргә булыша. Без компания өчен югары квалификацияле белгечләр әзерлибез, илебездә эшләнгән инновацияләрне җитештерүгә кертергә ярдәм итә торган уртак фәнни-белем бирү проектларында һәм федераль программаларда катнашабыз. Илебез алдында торган глобаль каршылыкларга без шулай бергәләп кенә лаеклы җавап бирә алабыз.

Рәүзил Мәгъсүмҗан улы белән безнең максатыбыз уртак – Россия Федерациясенең технологик суверенитеты ул.

– Хөрмәтле Рәүзил Мәгъсүмҗан улы!

Сезне юбилеегыз белән ихластан тәбрик итәм! Бу аеруча сөенечле көндә барлык проектларыгызда уңышлар телим! Гаиләгездә һәрвакыт мәхәббәт, муллык, үзара аңлашу хөкем сөрсен, компаниягез исә гөрләп үссен! Бетмәс-төкәнмәс энергия телим! Киләчәктә дә уңышлы хезмәттәшлек итәргә насыйп булсын!

Фотолар КДЭУ матбугат үзәгеннән алынды. РЕКЛАМА

ROSE

ТИРӘН ДЫМЛАНДЫРУ ӨЧЕН ЯСАЛГАН

- МИЗГЕЛ ЭЧЕНДӘ ДЫМЛАНДЫРУ ҺӘМ ТУКЛАНДЫРУ
- ТИРЕНЕҢ ЯШӘРҮЕ ҺӘМ САФЛАНУЫ
- ҖЫЕРЧЫКЛАРНЫ КИМЕТҮ
- ТИРЕНЕҢ ШОМАРУЫ ҺӘМ ТЫГЫЗЛАНУЫ

ДОКАЗАНО КЛИНИЧЕСКИМИ ИСПЫТАНИЯМИ

СЫВОРОТКАНЫҢ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КЛИНИК ЯКТАН РАСЛАНГАН

master-om.com

wildberries.ru
арт. 221376649

Реклама. Шәхси эшкуар Мустаева Олеся Николаевна ОГРНИП 311168919600013 420030. Казан ш., Набережная ур., 11, 2 нче корылма

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан»журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9172-740-352

Реклама 16+